PRESSA.RU

1926–1991 елларда **АЗАТ ХАТЫН**



2018 **ГЫЙНВАР № 1**

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ТОРМЫШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

яңа проект

ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАСЫ

гомерне икегә бүлгән көн

МАСТЕР-КЛАСС

бишмармак әзерлибез

Эльмира ФӘХРЕТДИНОВА:

БАРЫСЫ ДА ЯРАТУДАН БАШЛАНА...

PRESSA.RU

2018 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР
(һиҗри исәп буенча 1439–1440 еллар)

19 март – мөселман календарендә изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка изге көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ – гомрә хаҗы кылына.

22 март – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәр Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына могҗизалы сәяхәт кылган кичә. Биш вакыт намаз уку шушы кичәдә фарыз кылынган.

30 апрель – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә һәркемнең язмышы турында карар кабул итә.

16 май – изге Рамазан ае. Сабырлык вә рәхмәт ае. Ярлыкау һәм гыйбадәтне аеруча күп кылу, ураза тоту ае. Коръән иңгән ай. Бу шәрәфле айның һәр көне, һәр киче мөбарәк һәм кадерле.

21 май – Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

10 июнь – Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе. Аның кайсы көндә булуы ачык билгеле булмаса да, риваятьләр буенча, Рамазанның 27 нче кичәсенә туры килүе ихтимал диелә. Изге гамәлләрнең савабы башка кичәләргә караганда күпкә артыграк.

15 июнь – Гайдел-фитыр көннәре. Ураза гаете. Бу көнне гает намазын уку һәр мөселманга ваҗиб.

20 август – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне. Хаҗда булмаганнар ураза тота.

21 август – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган корбан чалу бәйрәме, ул өч көн дәвам итә. Бу көндә дә гает намазын уку ваҗиб.

22–24 август – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус догалар укыйлар.

11 сентябрь – 1440 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Хәерләр (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына торган ай. Бу көнне Аллаһы Тәгалә игелек кылганнарның гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

20 сентябрь – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – ун пәйгамбәргә күндерелгән изгеләр хөрмәтенә, бу көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота, гыйбадәтләрен арттыра.

10 октябрь – Сәфәр ае башланган көн.

19 ноябрь – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Ул көнне мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, сәдака (зәкят) өләшенә.

Төзүчесе: хаҗи Абдулла ДУБИН



«Казандагы Зәңгәр мәчет». Ильяс Айдаров эше.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова

Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина

Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Эльмира Фәхретдинова
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Фәнзилә Мостафина
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Равил Газизов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 29.12.2017 ел.
Заказ А-3281.
Тираж 5297.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.


Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU



«Лилия». М. Хаҗиев эше.

Баш мөхәррир сүзе



Куен дәфтәремне актарам.

Мин – хатын-кыз.
Минем белән авыр,
Миннән башка кыенрак мең кат... –

дип язганмын бер шигыремдә. Галәм ачуым түгел, әлбәттә, меңләгән кешенең – бигрәк тә: «Аңламассың бу хатын-кызны!» – дияргә яратучы ир-атларның – фикерләрен генә шигырь юлларына күчергәнмендер. Дөресе шул бит: без җиңел затлардан түгел, меңгә төрләнәбез. Үзебез дә төрле: кайсыбыз ирләр дә күтәрә алмаслык йөкне тартып барырлык дәрәҗәдә көчле; кайсыбыз чәчәк таҗында чык тамчысын күреп тә яшь сыгарлык дәрәҗәдә нечкә күңелле; кайсыбыз, аһ, нәфислеге, чын хатын-кыз инде бу, дип сокланырлык көчсез... (Көчсез була белгәннәргә сокланам мин. Ни өчен була белгәннәргә дим? Шуны күрсәтерлек, шулай яши белерлек көч тә кирәк бит!) Нинди генә булсак та, барыбызның да күңелендә бер теләк дип уйлыйм: безне аңлауларын теләү! Хыял канатларында очканда – безне җиргә тартып төшермичә, безнең белән бергә очуларын, җиргә басып барганда – адымнарыбыз тагын да ышанычлырак булсын өчен безнең белән янәшә атлауларын теләү...

Без, «Сөембикә»ләр, сезнең һәрберегезнең күңеленә кереп, якын сердәшчегез, аңлаучыгыз булырга телибез. Безнең журнал битләрендә һәрберегез үзен таба алса иде. Аңлашып, аралашып яшәргә язсын! Һәм иң мөһиме – сезнең бердәнбер булуыгызны аңларлык, кадерләрлек, бергә сөенерлек һәм күз яшьләрегезне сөртерлек, кыскасы, яратучы кешеләрегез янда булсын! Нәкъ шигырьдәгечә:

...Мин – хатын-кыз,
Йөз кат төрләнсәм дә,
Бүген нинди булсам, шулай ярат!

Гөлнара САБИРОВА

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

20
УЛ НИ ДИСӘ, ШУЛ БУЛА
Мәдинә Авзалова






ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

8
«ҖИМЕРЕК. ЯШӘРГӘ ЯРАКСЫЗ...»
Мәдинә Авзалова

ЕЛМАЮ ЕЛМАЮНЫ ТУДЫРА
Илсөяр Иксанова
16





12
ОСТЕОПАТ
Гөлнур Хәсәншина





ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

24
АККОШЛАРНЫ АК КИЛЕШ САКЛАГЫЗ
Ландыш Әбүдәрова

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34

БӘХЕТСЕЗ ИТӘСЕҢ БИТ...
Ләлә Сабирова

ЯШӘЕШ 

44



ҖЫР БҮЛӘК ИТӘМ
Зөһрә Сәхәбиева



ШУЛАЙ УК: 

40 **«...МӘХӘББӘТ – УЛ ҮЗЕ ИСКЕ НӘРСӘ...»**
Асия Юнысова

46 **«ЯРАТЫП ТУЯЛМАГАН...»**
Гөлнур Сафиуллина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

58



ФЛОРАРИУМ – БҮЛМӘДӘГЕ БАКЧА

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

ИНТЕРНЕТ ХАТЫН-КЫЗНЫ ҮЗГӘРТТЕМЕ? ФИКЕР.

СӘХНӘДӘ – ЛИЛИЯ МӘХМҮТОВА. АРАБЫЗДАН БЕРЕБЕЗ.

ТОРМЫШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ. РАИЛ САДРИЕВ. ЯҢА ПРОЕКТ.

«ЯРАТУДАН АЛДАШУ». ФИРҮЗӘ ҖАМАЛЕТДИНОВА. ХИКӘЯ.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

«Сөембикә»нең һәр санын көтеп алып, яратып укыйм. Без аны «Азат хатын» чагыннан бирле алдырабыз. Узган елның ноябрь санын кулыма алдым да, «Сөембикә»нең бик тә кирәкле, файдалы журнал булуына тагын бер кат инандым.

Әйтик, Рөстәм Сүлти язмалары үзе генә ни торырлык! Шигырьләре дә бик матур. Аның «Бердәнбер» дигән язмасын укып, күзгә яшьләр килде хәтта. Шундый ихлас итеп, яратып язган ул әнисе турында.

Алмаз Хәмзинның «Кил син, үзең кил...» дигән язмасын да рәхәтләнеп укыдым. И-и, үзебезнең Алмаз ла ул, туганыбыз кебек якын...

Табиблар турындагы язма да, әтиләрнең «әни» булып эшләүләре турында язылганы да уйга салды. Бу хакта үз фикеремне дә белдерми кала алмыйм. Әлбәттә, ирләр хатыннарына булышырга тиешләр. Гаиләдә ир-ат ярдәменнән генә башка булмый. Әмма алар «әни» ролен алырга тиеш түгел. Хөкүмәт тә гаиләсен кайгыртучы ир-егеткә тормыш итәргә җитәрлек хезмәт хакы түләргә тиеш. Эшләгән, тырышкан кеше лаеклы яшәргә хокуклы лабаса. Элеккедән калган халык сүзен дә онытырга ярамый: «Ирләр таба, хатыннар бага». Дөнья яралганнан бирле шулай булган, моннан соң да шулай калсын инде ул.

Тормыш булгач, аш-сусыз да булмый. Журналда мондый осталык дәресләре булмаса, күңелсез булыр иде кебек. Әнә Мәрьям Миңнеголова кабак бәлеше пешергән. Аны бик кызыксынып укыдым. Татар халык ашлары китабында да бардыр инде бу рецептлар, ләкин ул китап һәркемдә дә юк. Ә журнал һәр авылга килеп җитә, һәр китапханәдә укыла, хәтта чит илләргә дә тарала. Димәк, аны күбрәк кеше укый ала. Халкыбызның милли ашларына йөз белән борылуыгыз бигрәк тә куанычлы. Киләчәктә уңышлар телим сезгә, эшләрегез гел алга барсын.

Кайчандыр азатлык яулаган
«Азат хатын» идең син,
Ә хәзер халкыбызның
Сөекле «Сөембикә»се син.

Һәркем сине хөрмәт итә, –
Синдә яхшы язмалар.
Укырга атлыгып торып,
Сагынып, көтеп алалар.

Рузалия ШӘЙДУЛЛИНА.
Казан.



Әле IX гасырда ук имам әш-Шәфи: «Арабызда алардан башка тормыш бармый торган ике төркем кешеләр бар. Галимнәр һәм табиблар. Галимнәр дин өчен кирәк булса, табиблар тән өчен кирәк», – дип әйтеп калдырган.

Бүген – күп кенә авылларда табиб түгел, шәфкать туташы да булмаган заманда, бу яктан без бик бәхетле. Әллә нинди дәрәҗәле табибларга алыштыргысыз фельдшерыбыз – Айтуганова Альбина Таһир кызы эшли авылыбызда.

Авыл халкының үзен кайгыртырга беркайчан да вакыты җитми аның. Чирләсә – чирли, сызланса – сызлана, әмма эшен ташлап, малтуарын, бала-чагасын калдырып, табибка бармый да, тикшеренми дә. Ял йортлары, санаторийларда дәвалану авыл халкының күпчелеге өчен бөтенләй дә ят нәрсә. Аяктан егарлык чир булмаса, без аны аяк өсте генә йөреп уткәреп җибәрергә күнеккән. Бу җәһәттән Альбинабыз бик игътибарлы безнең. Кемнең ни белән чирләгәнен дә, кемгә кайчан тикшеренергә барырга кирәклеген дә белеп тора. Сәламәтлеге какшаган кешегә беренче ярдәмне күрсәтүче дә, дәвалаучы да – ул үзе. Табибка күрсәтергә кирәк дип, җитәкләп, район хастаханәсенә дә алып бара, синең ай-ваеңа, «үтәр иде әле»ләреңә карап тормый да. Авыл фельдшеры нәкъ менә шундый булырга тиештер дә әле ул.

Кайгы-хәсрәткә тарысаң да, иң беренче булып Альбина килеп җитә. Үтемле сүзен табып юата, кирәксә, тынычландыра торган уколын кадый. Шуңа да авыл халкы аны үзенең дәвалаучысы итеп кенә түгел, сердәшчесе итеп тә күрә.

Альбина безнең авылга 2007 елдан килеп эшли башлады. Үзе ул бездән сигез чакрымдагы Келәнче авылында яши, безгә дә көн саен шуннан килеп эшли. Өч бала анасы булган бу ханымга көн дә уналты чакрым йөреп эшләү бер дә җиңел түгелдер. Яңгырына, карына, пычрагына карамый, көн дә эштә ул. Кай көнне ире машина белән китерсә, кайбер көнне юлаучы машиналарга утырып та килеп җитә. Беркайчан зарланмас. Ачык йөзе, тәмле сүзе, йомшак куллары – үзе зур шифа. Рәхмәт сиңа, Альбина!

Дания ВӘЛИЕВА.
Кама Тамагы районы,
Олы Бортас авылы.

1942 елда хәзерге Яшел Үзән районы Муллаиле авылында туып-үскәнмен. Мин тугач, әти белән әни аерылышкан. Әни мине әтигә калдырып киткән.

Соңрак: «Әниләр усал иде. Бала белән кайтармадылар», – дип акланган булды. 6 яшемнән үги әни белән үстем. Әти белән аларның тагын өч балалары булды. Бераздан әти безне Пермь шәһәренә алып китте. Анда башка авылдашларыбыз да бар иде. Үги әнинең әнисе дә шунда яшәде.

Үз әнием Козловкага – дүрт балалы кешегә кияүгә чыккан. Кечкенә кызларына нибары 3 яшь кенә булган әле. Үзләренең дә уртак уллары туган. Әни янына сирәк кенә баргалый идем. Аның ире яхшы кеше иде. Безнең әти усалрак булды.

Үземә дә тормышымны балалы кеше белән корырга туры килде. Иремнең әти-әнисе белән яшәдек. Әмма Аллаһы Тәгалә уртак бала бирмәде, 11 ел яшәгәч, аерылыштык. Ирем начар кеше түгел, ләкин кеше сүзенә карый иде. Бала тапмый торган хатын белән яшисе килмәгәндер. Яшел Үзәнгә бер чемодан белән кайтып киттем. Ирем, юлга дип, 25 сум акча бирде. Барып сыеныр урыным да, бер танышым да юк. Шул чемоданымны тотып, анда бәрелеп, монда сугылып йөри торгач, базарда бер татар әбисе белән сөйләшеп китеп, ул мине үзенең барактагы бүлмәсенә сыендырды. Эшкә урнашып, 35 ел типографиядә эшләдем. Әмма кара сакалың артыңнан калмый, диләр. Мин эштә булганда, баракта янгын чыгып, бөтен нәрсәм көлгә әйләнгән. Ул вакытта кичергәннәремне язып аңлата торган түгел. Ике янгын кичердем үз гомеремдә. Мин күргәнне дошманыңа да күрсәтмәсен. Аннары эшләгән урынымнан ярым җимерек йорттан бер бүлмә бирделәр. Бүген дә шул иске йортта яшәп ятам әле. 9 мең сум пенсия алам.

Үги әниемнең апасы бар иде. Ун бала табып үстергән ул. «Син минем унберенче балам», – ди торган иде. Янына кайтсам, шатланып каршы ала, ашата-эчертә, мунча ягып кертә, кунак итә иде. Бераз кайтмый торсам, балаларыннан: «Кәүсәрия ник кайтмый икән? Хәлен беләсезме?» – дип сорый торган булган.

Тилмереп, чит-ят кешеләрдән җылы-наз өмет иткәндә, үз әнием җиде ятның балаларын үстерде. Берсенең дә: «Синең әниең безне үстерде», – дип әйткәне булмады.

Яраткан журналым «Сөембикә»не 1992 елдан бирле укыйм. Бер ел да язылмыйча калмадым. Әле кешеләргә дә укырга биреп торам. Үлгәнче язылырмын, Алла боерса.

Кәүсәрия ЯРУЛЛИНА.
Яшел Үзән шәһәре.



Без – сугыш чоры балалары. Эш белән чыныгып, илгә тугры булып үстек. Сугыш хәрабәләрен торгызу да безнең өскә төште.

Яшь вакытта телевизор карарга туры килмәде, вакыты да булмады, эшләдек, балалар үстердек. Хәзер инде балалар үсеп таралышты, ялгызым гына яшим. Пенсиядә булгач, вакыт күп, телевизорны көне буе карасаң да була.

«Татарстан–Яңа гасыр» каналын бик яратып карыйм. «Туган җир», «Әдәби хәзинә», «Без тарихта эзлебез», «Татарлар», «Таяну ноктасы», «Ком сәгате» – кызыксынып караган кешегә барысы да менә дигән тапшырулар. Үзем дә бик яратам аларны, көтеп алып карыйм. Геройлары да үрнәк алырдай кешеләр була.

Телевизор гына түгел, радио да тыңларга яратам мин. Иртән торуга радиоалгычымны кабызып куям. «Лира» дип аталган бу радиоалгычны миңа «Россия» банкының 150 еллыгы уңаеннан бүләк иткән иделәр. Телевидение кебек үк, радио да тормышка ямь өсти торган нәрсә, көн дәвамына җитәрлек энергия бирә. Иртән иртүк республикабызда, илебездә, дөньяда барган яңалыклар белән таныштыралар. Көн дәвамында матур җырлар тапшыралар. Туры эфирда барган кайбер тапшыруларда үзем дә катнашкалыйм. Ирем спортчы иде, спорт тапшыруларын яратып карады. 1954 елда – армиядә хезмәт иткән вакытта 50 чакрымлы чаңгы ярышында беренчелекне алган булган.

Авыл турындагы тапшыруларны да көтеп алып, яратып карыйм. Татарстанның матур авылларына сокланып туярлык түгел. Биек, заманча матур итеп салынган яңа йортларга ничек инде сокланмыйсың?! Авыл халкының тырышлыгына таң калырлык. Татар халкына никадәр бөек язучылар, композиторлар, рәссамнар үстереп биргән безнең татар авыллары. Мөгаен, табигать кешене шулай илһамландырадыр. Киләчәктә авылларга күбрәк игътибар булсын иде дип телим. Авылларның бетүенә юл куярга ярамый.

Беркөнне «Татарстан–Яңа гасыр» каналыннан Аксубай агрофирмасын күрсәттеләр. Көр, чиста сыерлар, уңайлы фермалар! Авылдан киткән яшьләрне уйлап үзәгем өзелде. Авылда да эшне әнә ничек яхшы итеп оештырып була икән – бу агроферма зур бер завод кебек. Әле шуның янында кечкенә генә май заводлары корып куйсаңмы! Элек һәр районның үз май заводы була торган иде. Эш урыннары булса, яшьләр дә авылдан китмәс иде. Саф һава, үзең җитештергән чиста, файдалы ризык, киң күңелле, җанга якын авылдашларың белән туган җиреңдә яшәү – үзе бәхет. Элек Бөек Ватан сугышы ветераннарына төзелеш өчен процентсыз ссуда бирәләр иде. Шундый ук ссуданы яшьләргә дә бирергә була бит. Авылда яшәп калуга бер стимул булыр иде.

Римма ЯППАРОВА.
Әгерҗе шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

«ҖИМЕРЕК. ЯШӘРГӘ ЯРАКСЫЗ...»

КОМИССИЯНЕҢ ШУНДЫЙ КАРАРГА КИЛҮЕНӘ КАРАМАСТАН, ЯТИМГӘ ФАТИР БИРҮ ТУРЫНДА БӘХӘСЛӘР ДӘВАМ ИТӘ.



Мәдинә
АВЗАЛОВА

Сүземне нидән, нәрсәдән башларга да белми озак уйланып йөрдем. Күз алдымда гел искереп, таушалып беткән көндәлек... Җанны айкап, күктән җиргә төшергән, тетрәндереп, чынбарлыкка кайтырга мәҗбүр иткән сүзләр... Йөрәктән әрнеп чыккан соңгы сүзләр, соңгы васыять. Хатын инде тиздән, бик тиздән якты дөньядан китәсен белгән. Куенына алып сөяргә дә, хәтта күз төшереп алырга да хәле булмаган ана нарасыеның ятим каласын аңлаган. Хәлсез бармаклары белән кәгазь битенә тетрәндергеч җөмләләр тезгән.

40 яше генә тулып килгән яшь хатынның газаплы, авыр тормышы аяныч тәмамланган. Моны аңлау өчен көндәлектән берничә генә җөмлә китерү дә җитә: «...Үтереп башым сызлый. Аның миңа акыруын исемә төшерсәм, күзләремә яшь килеп тыгыла. Нинди рәхимсез, җансыз кеше ул...» «...Аның (ире, – *авт.*) котыруын оныта алмыйм. Мин сындым. Ул мине тәмам сындырды. Яшәүгә теләгем дә, өметем дә калмады. Миңа каян көч табарга? Алга таба ничек яшәргә?» «...Аны исемә төшерсәм, тәнем кызыша, йөрәгем сикерә башлый. Гафу итә алмыйм. Мине – корсагы борынына җиткән хатынын – фахишә дип мәсхәрәли...» «...Хәлем начар, башыма будильник белән бәрде...»

Миңа бу юлларны уку түгел, хәтта язуы да авыр. Ни өчен, нәрсә хакына түзә икән хатыннар? Фатирсыз калу куркытамы аларны? Балаларны әтисез калдырмыйм дип, тәмугка керәләрме? Түзүнең

Фото: Газинур Хафизов. Иллюстрация буларак бирелә

дә бер чиге була. Сабыр канатлары да көннәрдән бер көнне сына. Ахыр чиктә алар барыбер кризис үзәкләренә килеп сыенырга мәҗбүр.

«Сеңлем, бала тапканнан соң ай да үтмәде, баш миендә яман шеш авыруыннан якты дөнья белән хушлашып китеп тә барды, – дип яза Чаллы шәһәреннән Кадрия Шәйдуллина. – Тугыз көнлек Булатны бала тудыру йортыннан туп-туры үземә алып кайттым. Үзем үстерәм, дидем. Чөнки аның иренә өмет-ышаныч калмаган иде инде. Сеңлемнең беренче баласы әтисе белән калды. Бала 7 яшькә җиткәнчегә кадәр опека һәм иганәчелек бүлегеннән бернинди ярдәм күрмәдем. Акчаны әтисе алып барды. Авыр булды, түздем: ул арада ирем дә вакытсыз үлеп китте. Шулай итеп, дүрт бала (үземнең өчәү) белән утырып калдым. Булатымның хокукларын даулап кайларга гына бармадым, кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем. Ятим бала (әтисен исәпкә кертмим, ул инде ата хокукыннан мәхрүм ителгән) буларак, аңа фатир бирергә тиешләр. Башта исәпкә бастырып, фатирга мохтаҗлар исемлегенә дә керткәннәр иде аны. Берара Түбән Кама шәһәреннән бер бүлмәле фатир да биргәннәр иде, әмма аны кире алдылар, баланы реестрдан төшереп калдырдылар. Имеш, аның авылда әнисеннән калган йорты бар. Ул өйне барып карасагыз, адәм мәсхәрәсе... Хан заманыннан калган җимерелеп беткән бер корылма. Ятимгә анысы да ярый диюләреме икән инде. Хәзер инде балага ничек ярдәм итәргә дә белмим...»

Бу хәлләргә карата мөнәсәбәтебезне белдерми кала алмадык. Залим ир аркасында таркалган гаиләләр, ятим калган нәни кыз һәм малайлар, балалар йортларында тәрәзәгә капланып, әнисен көткән сабыйлар язмышы безне беркайчан да битараф калдырмады. Хәер, ул тотрыклы гражданлык позициясе булган кеше өчен гайре табигый хәл түгел. Ул шулай булырга тиеш.

Күрәсен күрми...

Чаллы һәм Тукай районнары хакимиятенең опека һәм иганәчелек бүлекләрен, Башкарма комитет инстанцияләрен йөреп чыккан, дистәләгән имзалар һәм мөһерләр сугылган бер кочак кәгазь, шыплап тутырылган папка... Әйе, кәгазь... Чөнки дистәләгән карарларның берсе дә мәсьәләне хәл итә алмаган. Әлегә хәл итә алмаган. Ятимне фатирлы итәм дип, еллар дәвамында бер кабинеттан икенчесенә йөргән Кадрия ханымның, бикле ишекләрне ачтыру өчен үҗәтлеге дә, тәвәккәллеге дә җитәрлек аныс. Ул, әтисенә карап, балачактан печәнен дә чапкан, ирләр белән янәшә торып бура бурарга да өйрәнгән Сабирҗан карт кызы! «Авыр миңа», – дип зарланып та куя ул. Авырдыр. Кеше хәлен кеше белми торган бу заманда борчуларыңны йөрәкләргә барып җитәрлек, җаннарга үтеп керерлек итеп ишеттерү өчен башта үзеңнең йөрәгеңне ачып салырга кирәк шул әле!

Югалту-сагышлары белән еракта калган ул еллар аны әледән-әле артына борылып карарга мәҗбүр итә. Бу тормышта Күктәк-Мирсәет кызы төрлесен күрә: шатлыгын да, кайгысын да, михнәтне дә язмыш аңа кочак-кочак итеп бирә. Нишлисең?! Язмыштан узмыш юк, диләр... Тик нинди генә хәлдә дә ул югалып калмаган, кулын салындырмаган. Күрәсең, холкы белән дә ул – көрәшче! Шулай булмаса, бүген әнә минем каршымда утырыр идеме?! Ике сүзнең берсендә: «Минем Булатым!» – дип өзгәләнеп, әтисе була торып та ятимгә әйләнгән егетнең язмышы өчен ут йотып утырыр идеме?! Ә бит аның үз тормышында да кайгы-хәсрәт җитәрлек булган. Ут уйнатып торган, үз гомерендә тәмәке тартмаган, аракы эчмәгән, спорт белән шөгыльләнгән сөекле ире Нәкыйп 42 яшендә дөнья куйган. Кадрия дүрт бала белән япа-ялгыз калган. Хуҗалыкта ике сыер, ике бозау, ишегалды тулы кош-корты белән... Әйе, аның тагын биш сеңлесе бар, әмма һәркемнең үз тормышы, үз гаме. Берәүгә дә сөялеп булмый. Мең дә бер мәшәкате белән өстеңә ауган ул дөнья – синеке, бары синеке...

– Сеңлемнең вафатын бик авыр кичергән идем, – дип сөйли Кадрия ханым Шәйдуллина. – Ирем үлгәч, бигрәкләр өзгәләндем. Җитмәсә, кияү дигәнебез гел үзәккә үтеп, җанга тиеп торды. Баладан үз теләге белән баш тарткан ата: «Миннән баланы яшерәләр», – дип, кат-кат судка бирде. Үзе судка килмәде. Гомер буе әле баланың пособиесенә, әле туган авылдагы сеңлемнең җимерек өенә дәгъва белдереп җәфалады. Ничә еллар инде менә шулай газапланам. Хәзер әнә Булатыма фатир артыннан йөрим.

> *Бу язма кыйналып яшәгән хатыннарны уйга салса иде: кемгә кирәк икән мондый корбаннар?*

«...Яшәрлек түгел»

Әле 2004 елның 27 октябрендә үк уздырылган комиссия нәтиҗәсе буенча төзелгән актта: «Райпоның элеккеге кибет бинасы булган йорт, аның санитария нормаларына һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килмәве сәбәпле, яшәүгә яраксыз», – дип күрсәтелә. Шуннан соң да 13 ел вакыт узып киткән. Шул вакыттан бирле өйнең ишеген ачып керүче дә булмаган. Чөнки ул, чыннан да, яшәү өчен яраксыз. Аңарчы да иске булган кибет бинасын Кадриянең сеңлесе, яшәп торырга дип, 1994 елда сатып алган була. Бу акт нигезендә, ятимне «фатирга мохтаҗлар» исемлегенә дә кертәләр. Тик ни өчендер мәсьәлә яңадан күтәрелә. Чаллы шәһәренең опека һәм иганәчелек бүлеге җитәкчесе Роза Гернер бу үзгәрешне Кадрия ханымның Булатны шушы йортка милекче итеп яздыруы, ә ул йортның Чаллыга түгел, Тукай районына каравы белән аңлатты. «Безгә

PRESSA.RU



■ Булат солдат шушы йортка кайтырмы? Ятимне фатирлы итүдә кем җаваплы соң?

Ятимгә фатир бирдерү өчен Россия Президентына кадәр барып җитәргә кирәкме?! Ул бит законда каралган.

карамый», – диде. Булатны инде 2017 елда алачак фатир ияләре реестрына керткән дә булганнар югыйсә. Һаман да шул җимерек йорт – артыңнан өстерәлеп килгән кара шәл, кем әйтмешли.

Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе имзасы куелган хатта да Булат Миннеәхмәтовның торак мәйданы нормада каралганча булу сәбәпле, ул «торак исемлегеннән төшерелде» дип күрсәтелә.

Сөйләшүне инде хәзер Тукай районының опека һәм иганәчелек секторы мөдире Лариса Николаевна Андреева белән дәвам итәбез. «Йортның яшәргә яраксызлыгы хакында комиссия акты булса, исемлеккә яңадан кертербез», – диде ул. Ә комиссия килергә ашыкмый.

Без Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы белән элемтәгә кердек. «Торак комиссиясе оештырсыннар дип, безгә яңадан хат язсыннар», – дип киңәш бирде министрлыкның опека һәм иганәчелек бүлеге җитәкчесе Зөлфия Мөсабирова. Кыскасы, яңабаштан башларга.

Тукай районының Роспотребнадзор җитәкчесе Марат Гыйрфанов белән дә сөйләштек. Ул: «Бу мәсьәлә белән Тукай районы Башкарма комитеты шөгыльләнә», – дип, шундук кырт кисте. «Документлар инде күптән Тукай районы Башкарма комитетында», – дип тынычландыра безне хокук бүлеге җитәкчесе Нәзирә Бузина.

...Ниһаять, Кадрия ханым безгә: «Комиссия киләчәк», – дигән шатлыклы хәбәр җиткерде. Без комиссиянең гадел карарга киләчәгенә ышанабыз. Мәсьәләгә җаваплы караш булганда, Россия Президенты да кирәкми бирелә. Кадрия ханымның Илбашына язган хаты да көннәрдән бер көнне шул ук җитәкчеләр адресына кире әйләнеп кайтачак. Моны гына беләбез инде. Тәҗрибә шуны исбатлый.

Бүген Булат Фәрит улы Миннеәхмәтов Рязаньда – һава-десант гаскәрләрендә хезмәт итә. Кадрия ханымның төпчеге ул, аның горурлыгы. Армиягә алынганчы Чаллы шәһәрендә «Кама» төзелеш колледжын, музыка мәктәбен тәмамлаган. Төрле фестивальләрдә, җыр бәйгеләрендә катнашып, гран-при яулаган. Аны курайда да бик оста уйный, диделәр. Кадрия ханымның: «Булатымны телевизордан күрсәтсеннәр иде», – дигән теләкхыялы да тормышка ашкан. Кадрия апасының кызы Диләрәне Булат – «әни» дип, ә киявен «әти» дип йөртә. Ә үз әтисе... Үз әтисе баласын, туганнан соң беренче тапкыр, 18 яшенә җиткәч кенә күрә. Бер шәһәрдә яшәп, баласының кемдә тәрбияләнүен белә торып шулай итә. Ничек йөрәге түзә диген? Баласын ташлаган әниләрне ана күке, дибез. Чынында, баласын ата күке ташлый икән. Бу – нәкъ шундый очрак менә.

Бер-береңне чиксез ярату белән өртелгән дус-тату гаиләдә үскән Булатның кече күңелле, игелекле, кайгыртучан ир һәм әти булачагына шигебез юк. Бәхете, ул бит шундый гаиләдә тәрбияләнгән.

Соңгы сәгатьтә

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Чаллы шәһәре муниципаль белем Башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Абдуллинга бүгенге көндә армия сафларында хезмәт итүче Булат Миннеәхмәтовка фатир бирү-бирмәү мәсьәләсенә ачыклык кертүне сорап язган хатында: «Булат Миннеәхмәтов, караучысыз калган бала буларак, Чаллы шәһәре Башкарма комитеты карары белән, инде 2008 елның май аеннан ук торак йортка мохтаҗлар исемлегенә кертелгән булган. Тукай районы Башкарма комитетының опека һәм иганәчелек бүлегенә Күктәк-Мирсәет авылындагы йортның яшәү өчен яраклымы, яраксызмы булуы турында ведомствоара комиссиянең актын һәм йомгаклауны әзерләүне тапшырсагыз икән. Комиссия актын безнең адреска җибәрүегезне сорыйбыз», – диелгән.

P. S. Бу «сакаллы» мәсьәлә Татарстан Республикасының Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурскаяның шәхси контролендә тора.

Менә без шундый инде... Күтәрәлгәнчә күтәреп, иңсәгә сумкалар асып, тәмам хәлдән таеп... Үзебез һаман каядыр ашыгабыз-кабаланабыз... юк, йөгерәбез, очабыз – бөтен нәрсәне колачларга!.. Эштә дә, өйдә дә барысына җитешергә кирәк. Баланы бакчадан аласы, кибеткә чабасы, ашарга пешерәсе, юасы-җыясы, фитнеска өлгерәсе... Шул ук вакытта яшь тә, заманча да, креатив та булып каласы килә! Тиктормас, кыбырсык та инде үзебез! Күңел һаман матурлык, хыял, нәфислек дөньясына омтыла! Асынган, төянгән килеш, безнең аяклар гына китап кибете йә күргәзмәләр залы ягына борыла аладыр. Ә анда – картиналар, җанга якын төсләр, рәхәт халәт... Бертөрле гадәти көннәребезне бизәр өчен һава, су кебек кирәк шул алар. ...Ә пакет, сумкалар... «Юк ла, авыр түгел», – диган булабыз. Түзәбез. Нигә шулай? Нигә түзәргә? Тормыш нигә хатын-кыз җилкәсендә генә булырга тиеш? Нигә үз кадеребезне үзебез белмибез?!

Газинур ХАФИЗОВ фотосы



PRESSA.RU

ОСТЕОПАТ



– БАШЫГЫЗ АВЫРТАМЫ? ДИМӘК, КАЙЧАНДЫР СУЛ АЯГЫГЫЗНЫҢ ҮКЧӘСЕН БӘРГӘН БУЛГАНСЫЗ... УҢ ЯК ИҢБАШЫГЫЗ БОРЧЫЙМЫ? ТӨП СӘБӘП – УҢ ЯКТАГЫ БЕРЕНЧЕ КАБЫРГАГЫЗДА...

Фото: Ксения Богданова



Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Остеопатка беренче тапкыр килгән кеше, үзенә куйган бу диагнозларга шикләнеп, ышанмыйча да карарга мөмкин: «Баш кайда да, үкчә кайда?» яки «Иңбашым кабыргама бәйләнмәгән ләбаса!» – дип. Бигрәк сәер табиб бу: анализ бирергә дә кушмый, УЗИга да җибәрми... Массаж ясый дисәң, аңа да охшамаган: кулын, тәндәге үзе генә белгән ниндидер нокталарга куеп тора – каты итеп тә басмый, авырттырмый да. Бөтен гәүдәдә ниндидер бер рәхәтлек сизелә үзе... Табиб бүлмәсеннән чыккач: «Бу ни булды соң? Файдасы тиярме икән моның? Әллә башка килеп тә тормаска гынамы?» – дип икеләнеп каласыз икән, ашыкмаска киңәш итәм. Бер уч дару эчәргә кушмаган өчен генә бу табибтан баш тартырга кирәкмәс. Кайсы төшебез генә авыртса да, иң элек остеопатка мөрәҗәгать итәчәк көннәребез алда әле. (Кабул иткәндә, берни эшләмәгән кебек тоелса да, остеопатка барганнан соң, сездә үзгәрешләр булачак! Өч көннән соң, әйтик, муен яхшырак борыла, кул әйбәтрәк күтәрелә башлаячак. Организм өчен, гомумән, каты-каты басып, авырттырып нидер эшләүгә караганда, остеопатның сезгә сизелер-сизелмәс кенә кагылуы күпкә файдалырак.)

Без генә ул «остеопатия» дигән сүзне яңа ишетә башладык. Чынлыкта, аңа инде Америкада XIX гасырның ахырында ук нигез салынган. Көненә, хәтта сәгатенә кадәр билгеле! Эндрю Тейлор Стилл дигән галимнең эчәк менингитыннан бер-бер артлы өч баласы үлеп китә. Коточкыч хәсрәттән тетрәнеп калган ата кеше: «Нишләп медицина булыша алмады соң аларга?» – дип уйлана башлый. Үзе дә табиб булгач, бу югалтулар бигрәк ачы, үкенечле тоелгандыр... «Кеше организмы – бербөтен, аны дәвалаганда тулаем алып карарга кирәк. Тән төзелеше шулкадәр камил, үз-үзен сәламәтләндерү өчен бер функциясе, ниндидер ноктасы булмыйча калмас», – дигән фикер галимнең башына 1890 елның 22 июнендә, иртәнге сәгать унда килә. Кояшлы матур көн була ул. Эндрю Тейлор Стилл дәфтәренә шулай дип теркәп калдыра.

Остеопат берьюлы терапевт, невролог, мануаль терапевт һәм ортопедны алыштыра ала. Кеше организмы кайсы җирен һәм ничек дәваларга икәнен үзе сиздерә – бары тик ул җибәргән «хәбәр»не тоеп, тотып алырга гына кирәк, диләр алар. Тәҗрибәле, белемле (үзеңнең сәламәтлегеңне исә бары тик югары махсус белемле остеопатка гына тапшырырга ярый!) табиб, авыру кеше организмыннан агылган «дулкын»нарны учларына «җыя» һәм «укый» ала. Ә аннан организмга үз-үзен савыктыру юлларын «әйтеп, күрсәтеп җибәрә». Һәм бары тик куллары белән генә! Иң кызыгы тагын шунда: остеопат куйган диагноз ниндидер кыйммәтле аппаратуралар ярдәмендә куелган диагнозга караганда, төгәлрәк тә булырга мөмкин. Табибның сизгер куллары диагностик приборлар «күрмәгән» бик кечкенә тайпылышларны да тоя, «тотып ала». «Менә шушы төшем авырта», – дигән зарыгызга, чирнең билгеләрен санавыгызга остеопат игътибар итмәгән кебек тоелса, аптырамагыз: чирнең төп сәбәбе, гадәттә, симптомнар белән бәйле түгел, аны башка җирдән эзләргә кирәк дигән фикердә алар (әйтик, бил белән бәйле проблемаларга теш казнасы гаепле булырга мөмкин). Традицион медицина авыртуның сәбәбен тапмаган, дәвалану бернинди нәтиҗә бирмәгән очракларда остеопатия ярдәмгә килә ала. Дөресрәге, авырулар бу хакта белсәләр, мөрәҗәгать итсәләр, ул аларга ярдәмгә килә, булыша алыр иде.

Минем әңгәмәдәшем Наилә ЛАТЫЙПОВА – Европа остеопатия мәктәбен (Мейдстоун, Кент графлыгы, Англия) тәмамлаган белгеч. Бу мәктәпне Эндрю Тейлор Стиллның шәкерте – Джон Мартин Литтлджон ачкан (заманында ул үзе дә галимгә авыртуына дәва эзләп мөрәҗәгать иткән була!). Аның Польшада, Германиядә, Испаниядә һәм Россиядә (Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләрендә) филиаллары бар.

Остеопатлар безгә кайчан, ничек ярдәм итә ала – шул хакта сөйләшәбез.

Балалар

– Мин – педиатр. Остеопатия олыларныкына, кечкенәләрнекенә бүленмәсә дә, сабыйлар белән эшләү үзем өчен кызыграк. Бала туганда, аның муенында, җилкәсендә аз гына үзгәрешләр булырга, мускуллары «кысылып» калырга мөмкин. Педиатрлар, гадәттә, моңа игътибар итми, болай да узар, җайланыр дип уйлый. Бала, туура табиб кулына эләккән икән, аңарда, димәк, патология күп, болары шуңа күрә әһәмиятле тоелмый. Тик бернәрсә дә эзсез узмый шул... Сәбәпсез елау, начар йоклау, муен кәкрәю, эч авыртулар башлана. Аннан бала башын дөрес тотмый, ул – гиперактив. Йөри башлагач, аяклары чалыш икәне яки аңарда «аю табаны» булуы күренә. Болардан үз вакытында котылмыйсыз икән (ә моның өчен дару белән дәваларга да кирәкми: остеопатның кулы белән кайбер «ялгышлар»ны аз гына төзәтеп җибәрүе дә җитә! Күп вакыт 4-5 сеанс та булыша. Менә шуның өчен дә, бер яше тулганчы, баланы, һичшиксез, остеопатка күрсәтергә кирәк. Аннан, бала тәпи атлап киткәч – икенче тапкыр), йомгак зурая гына бара, һәм бала 2-3 яшькә җиткәндә, бөтенләй башка төрле чирләр килеп чыгарга мөмкин. Шуларның берсе – сөйләм кимчелекләре.

Остеопат авыруның ишектән ничек атлап керүенә, гәүдәсен ничек тотуына, ничек утыруына – барысына да игътибар итә.

Баланың теле соң ачылуы, күп авазларны әйтә алмавы кебек проблемалар адым саен очрый хәзер. Без аларны «өркегән, курыккан балалар» дип атыйбыз: бу сабыйлар дөньяга килгәндә шок, стресс кичергән, читтән караганда алар бик агрессив күренә. (Остеопатлар табигать кануннарына якын тора. Шуңа күрә бу проблеманың бер сәбәбе – ясалма тулгаклар дип саныйбыз.) Тән тукымасының «кысылу»ын дарулар белән вакытлыча «томалап» торырга мөмкин, әмма сәбәбен бөтенләй алып ташлый алмыйсың. Ә остеопатка моның өчен зур көч салырга да кирәкми... Икенче тапкыр килгәндә үк әти-әниләр, шаккатып: «Бала иҗекләр әйтә башлады! Ул безне ишетә!» – дип, куанычлары белән уртаклашалар.

Балалар хакында сүз кузгаткач, тагын бер нәрсәне әйтеп китәсем килә. Остеопатлар прививкаларны рәттән бөтен балага да ясауга каршы. Дөресрәге, ул сәламәт нәниләргә генә ясалырга тиеш дип саный алар.

Остеопатиянең өстенлекләре

- авыруның хәле җиңеләю беренче сеанстан соң ук башлана;
- бишектәге бәбидән алып өлкәннәргә кадәр – барлык яшьтәге кешеләргә дә ярый;
- сеанс вакытында пациент бернинди авырту сизми: тәнгә рәхәт кенә;
- бернинди зыяны юк: дару кабарга кирәкми;
- сеанс атнага бер тапкыр гына була – процедураның файдасы җыелып килә;
- бер курс 7-8 процедурадан артмый: вакыт та янга кала, кыйммәткә дә төшми.

PRESSA.RU



■ Наилә Латыйпова дипломны Англия королевасы Елизаветаның оныгы – принцесса Евгения Йоркская кулыннан алган. Европа остеопатия мәктәбе корольлек патронажында.

Кызганыч, андыйлар исә сирәк. Мин үзем менә, остеопат буларак, бары тик бер балага гына «сәламәт» дигән диагноз куйдым.

Көнбатышта бу ысул 100 елдан артык кулланылса да, бездә ул әле артык киң таралмаган.

Бигрәк тә В гепатитына каршы вакцина турында әйтүем. Баланың әти-әнисендә гепатит булган очракта, прививканы, әлбәттә, ясарга кирәк. Ә болай, бала тудыру йортында ук йоктырмаган булса, бала бу инфекция белән тиз генә очрашмаячак. Гепатит кешегә кан аша һәм җенси юл белән иярә: шуңа күрә, операциягә керәсе булмаса, прививканы кичектерсәң дә куркыныч түгел. Комлыкта уйнаганда, бала наркоманнар калдырган шприцка кадалырга – шулай гепатит чире йоктырырга мөмкин дип әйтәләр. Әйе, мондый куркыныч бар. Әмма бу – миллионга бер очрак кына. Прививка исә баланың иммунитетын билгеле бер инфекциягә каршы гына юнәлтә, аның организмының көн саен очрый торган инфекцияләр белән көрәшергә көче аз кала. Менә монысына нигәдер күз йомалар...

Могҗиза түгел

Табигатьнең барлык законнары да билгеле бер ритмга корылган: иртәне – кич, төнне – көн, җәйне кыш алыштыра. Кеше дә табигать баласы, аның да бөтен органнары хәрәкәттә – һәрберсенең үз ритмы: эчәклекнең, тукымаларның, сеңерләрнең... Һәм боларны кул белән тояргa мөмкин: тәнгә кагылуга, ул барысын да үзе сөйли – нәрсә әйтергә тели, шуны ишеттерә. Моңа тиз генә ирешеп булмый, билгеле. Пациентка, әйтик: «Умырткагызның муен өлешендә өч ай (алты ай, бер ел) элек шундый-шундый хәл булмаган идеме?» – дигән сорауны бирү өчен берничә чакрым (!) муен капшарга кирәк. Аннары гына үзгәрешләрне тоя, «монысы – менә бу хакта, тегесе шуның турында сөйли» дип әйтә аласың. Ә пациент: «Бернәрсә булганын да хәтерләмим», – дияргә, икенче килгәндә исә: «Исемә төште!» – дип килергә мөмкин. Ул онытса да, тән тукымасының «хәтер»ендә барысы да саклана: «кысылу» да, бәрелүсугылу да, тартылу да... Кеше көнә буе эштә ничек утыра, ишек яки тәрәзә аның кайсы ягында, телефонга ул ничек үрелә – тән тукымасы боларның барысын да «хәтер»ендә саклый.

Бала да күп вакыт кайчандыр егылганын, бәрелгәнен оныта бит. Ә тән тукымасы «хәтерле». Организмның бу участогы (буыннар, мускуллар), үзе ничек эшләргә тиеш – шулай эшләвен дәвам итә алмый. Аның тирәюнендә барысы да үзгәрә. Әйтик, бер мисал. Пациент аягы авыртудан зарлана. «Имгәткәнем дә юк, әмма нигәдер сызлый», – ди. Аның аягы исә умыртка сөякләре бер-берсенә карата дөрес тормаганга авыртырга мөмкин: чөнки шул сөякләр аркасында аяк үзенә тиеш булмаган функцияне башкара.

Умыртка баганасында – бүсер

Соңгы вакытта бик күп кешегә «умыртка баганасында бүсер» дигән диагноз куела. Замана чирләренең берсе инде бу... Хәер, алай дисәң, элек тә бил, арка дип җәфаланганнар. Авыр эш аркасында, бәлки, авыручылар күбрәк тә булгандыр. Әмма ул чакта диагнозны ачыкларга МРТ-диагностика уйлап табылмаган бит әле. Бүген әлеге чирне китереп чыгаручы төп сәбәпләрнең берсе – утырып эшләү, аз хәрәкәтләнү. Элегрәк: «Бухгалтер эше авыр», – диючеләргә, гел: «Көне буе ручка тотып утыруның ни авырлыгы бар?» – дияргә яраталар иде. Ничек кенә авыр әле?! Чыгып китеп, берәр физик эш башкарсаң, бу организм өчен күпкә файдалырак булыр иде. Иртәдән кичкә кадәр компьютер алдында утырган офис хезмәткәрләренең кул чуклары, терсәкләре авырта, баш миендә кан әйләнеше бозыла, остеохондроздан җәфаланалар...

Киңәш

■ Баш авырткан очракта, берничек тә кул белән чигәне кысарга ярамый. Уч төбе белән кашлардан маңгайга, аннан чәчләрдән баш артына кадәр каты итеп сыпырыгыз.

■ Компьютер янында озак утырганнан муен авырта башласа, кулларны баш артына куегыз һәм башыгыз белән кулларны артка этә башлагыз (куллар үз урынында калсын, артка китмәсен!). Ашыкмыйча 3-4 кә кадәр санагыз да, шулай ук ашыкмыйча, әкрен генә кулларны йомшартыгыз. Көнегүне 2-3 тапкыр кабатлагыз: моңарчы эшләмәгән мускуллар эшли башлар, ә эшләп «катканнарына» җиңелрәк булыр. Сеңерләрдәге киеренкелек кими төшәр, сыгылмалыклары артыр – авырту бетәр.

Киңәш

Нинди авыртулар белән остеопатка мөрәҗәгать итәргә:

- Балалар: туганда алган имгәнүләр, бәвел тотмау, кылый күзлелек, энцефалопатия, игътибарсызлык, үсеш дәрәҗәсе тоткарлану, неврология белән бәйле проблемалар, баш сызлау, колак-борын-тамак авырулары, ашказаны-эчәк авырулары, хәрәкәтләнү, гәүдә тотрыклылыгы белән бәйле проблемалары һәм башкалар.
- Өлкәннәр: төрле имгәнүләр, баш авырту, баш әйләнү, баш миендә кан әйләнеше бозылу, радикулит, буын авырулары, остеохондроз, гинекология белән бәйле чирләр (күрем циклы бозылу, балага уза алмау, гормональ тайпылышлар, ялкынсынулар), бронхит, ринит, начар ишетү, импотенция, хроник ару һәм башкалар.

Мондый очракларда, остеопатлар пациентларга... дүрт аякта мүкәләргә тәкъдим итә. Болай йөрү, гомумән, бөтен кешегә дә файдалы: умыртка баганасы кырыендагы гел хәрәкәтләнми торган мускуллар да хәрәкәткә килә. Ул өлкән кешеләрнең хәтерен яхшырта: бу вакытта баш миенең ике ярымшары арасында бәйләнеш туа. Балалардагы яссытабанлылыкны, сколиозны, аякларның чалышлыгын шулай дәваларга мөмкин. Фитнес белән шөгыльләнергә, спортзалга йөрергә гел вакыт җитми безнең, ә бу күнегү исә аны да алыштыра ала: иртән торгач, һичьюгы ваннага кадәр мүкәләп барырга кирәк. Читтән караганда көлке күренсә дә, мүкәли бирегез. Иң яхшысы: иртән һәм кичен 4-5 минут шулай йөреп алу.

Кеше күп вакыт үзенә үзе дә ярдәм итә ала. Башка табиблар кебек үк, остеопатлар да шулай дип саный. Дүрт аякта йөрү кебек гади генә күнегүләр тагын бар.

Шуларның берсе. Мин үзем аны татарча биюнең киресе дип атыйм. Иртән уянгач, урыннан да тормаган килеш, эчегезгә әйләнеп ятыгыз. Башны сул якка борып, сул кулның баш бармагын борынга таба каратып куегыз, уң аякны тезгә кадәр бөгегез. Аннан тиз генә уң кул һәм сул аякка алыштырыгыз, башыгызны уң якка борыгыз. Күнегүне ун тапкыр ясагач, азрак ял итеп алып, тагын кабатларга була. Бу көнне хәтерегез 5 процентка яхшырак эшләячәк.

Бу күнегүне һәркемгә дә ясарга кушабыз. Әмма барысы да кешенең үзеннән тора. 12 яшьлек бер кызны алып килделәр. Аның әтисе элеккеге хоккейчы. Кызын кечкенәдән спортка биргән. Бу бала җиңел атлетика белән шөгыльләнгән, чаңгыда йөргән – беренче урыннар яулаган. Буйга бик тиз үсеп киткән дә, физик күнегүләр аның организмы өчен авыр йөккә әйләнгән: 3 нче дәрәҗә сколиоз дип куйганнар иде аңа. Массажны шунда ук туктаттык – дөрес эшләнмәсә, бу очракта ул тагын да күбрәк зыян гына салырга мөмкин. Иртән мин аңа мүкәләп йөрергә, шушы күнегүне ясарга кушып җибәрдем. Спорт белән шөгыльләнгән кеше зарядка ясарга әзер бит ул. Икенче килүендә үк алга китеш сизелде, өченчесендә инде үзгәрешләр күзгә күренерлек булды.

Тән тукымасы бернәрсәне дә «онытмый».

Ә хәзер туры бер сызыкны күз алдына китерегез: аның бер ягында – сәламәтлек, икенче ягында – патология (нормадан тайпылыш, гариплек). Кеше уртада басып тора. Әгәр нинди дә булса бер фаҗигагә тарымаса, имгәнмәсә, гариплә нмәсә, ул шунда ук патология ягына күчми. Бу сызыкның кайсы ягына таба атлап китә – барысы да кешенең үзеннән тора. Элегрәк: «70-80 процент очракта үзенә бәйле», – диләр иде, хәзер исә: «90 процентка кадәр», – диләр. Туры сызыкның «авыртулар» дигән ягына барганда, синең юлыңны кирегә борырлык әллә никадәр сәбәпләр, мөмкинлекләр очрый. Әгәр синең сукмагың бу вакытта «остеопат» дигән белгечнеке белән кисешсә, ул сине, һичшиксез, башка якка – сәламәтлеккә таба борып җибәрәчәк.

РЕМОНТ ОФИСНЫХ КРЕСЕЛ И СТУЛЬЕВ
Комплектующие. Гарантия. Качество. Выгодные цены.
Газлифт (от 300 руб.)
Устройство отклонения (от 410 руб)
Механизм качания «топ-ган» (от 600 руб.))
Крестовина большая пластиковая (от 300 руб.)
Крестовина большая металлическая (от 2000 руб.)
Ролики для операторских кресел (от 150 руб. 5 шт.)
г. Казань, ул. Чистопольская, д. 5
+7 953 999 26 88, +7 987 290 75 60, +7 843 518 32 61
www.kybmebel.ru kybmebel@mail.ru
16+
РЕКЛАМА

PRESSA.RU

ЕЛМАЮ – ЕЛМАЮ ТУДЫРА

Илсөяр ИКСАНОВАның тормыш кагыйдәләре



Фото: Ксения Богданова

Минем Казан ханлыгының чәчәк аткан чорын күрәсем килә. **МИЛЛӘТЕМНЕҢ ДӘҮЛӘТЛЕ, ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ДӘРӘҖӘЛЕ – МИЛЛӘТАРА АРАЛАШУ-ДИПЛОМАТИЯ ТЕЛЕ БУЛГАН ДӘВЕРЕНДӘ ЯШӘП КАРАСАҢ ИДЕ!** Ул чорның, әлбәттә, үз чатаклыклары җитәрлек булгандыр. Анысы икенче мәсьәлә.

МИН ФЕМИНИСТКА ТҮГЕЛ. Хатын-кыз гына булып каласы килгән чаклар да була. Тик аның өчен янәшәңдә чын ир-ат булу зарур. Кызганыч, андый көчле затлар сирәгәеп бара, дисәм, үпкәләрләр шәт... Монда, бәлки, хатын-кызларның үзләренең дә гаебе бардыр, ирләр вазыйфасының бик күбен үз җилкәбезгә алдык бит. Шулай да әле гаиләдә дә, җәмгыятьтә дә үз вазыйфаларын җиренә җиткереп үтәгән, шул ук вакытта нәфис тә, йомшак-ягымлы да булып кала алган гүзәл затларыбыз күбрәк.

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА ТАБИГАТЬТӘН БИК ЗУР МӨМКИНЛЕКЛӘР САЛЫНГАН. Иң беренчесе, әлбәттә, сизгерлек (интуиция). Төп вазыйфасы ана булу, баланы саклау, нәселне дәвам итү булган хатын-кызда табигый инстинкт ул. Шуның өстенә хатын-кызга хас (бәлки, хас булырга тиеш) сыйфат – зирәклек.

Без илебез коммунизм төзегән чорда үстек, әниләрнең бала карап кына утырырга хаклары юк иде. Әбиләрчә итеп әйтсәк, алар хөкүмәт эшендә булды. Ә менә элек заманнарда – хатын-кыз учак сакчысы булып өйдә генә торганда, ул йорт мәшәкатьләреннән арына алмаса да, баласы янәшәсендә булган. **БАЛА АНАСЫНЫҢ БӨТЕН ХӘРӘКӘТЕН КҮРЕП, КҮЗӘТЕП, КҮЧЕРЕП ҮСКӘН.** Рухи якынлык булсын өчен ана белән баланың бергә булуы, тыгыз аралашуы бик мөһим. Шуны аңлап, кызыма өч яшь тулганчы өйдә утырдым. Ә аннан соң балама минем янәшә булуым җитеп бетмәде дип уйлыйм; эш, командировкалар күп вакытны алды.

ҮЗЕМНЕҢ БАЛАЧАК – ДӘҮ ӘНИЛЕ БАЛАЧАК. Дәү әниле, димәк, әкиятле, бәетле, кабартмалы балачак.

ШУК ИДЕМ, ИРКӘ ИДЕМ. Тулы гаиләдә төпчек бала, шуның өстенә дәү әниле, дәү апалы бала буларак, кадердә үстем. Без – өч баланың иреген чикләүләр булмады.

Казанда безнең тутыебыз Гөлфия апа (без аны Тәти апа дип йөри идек) яши иде. Без апам белән аңа кунакка килергә ярата идек. Ул эшкә китә, без аны көтеп тулай торакта калабыз. Тәти апабыз бик матур киенә иде безнең. Ул эшкә киткәч, чемоданын актарып, матур күлмәкләрен карыйбыз. Апам тегү эшенә әвәсләнеп китте берчак, курчакка күлмәк тегәсе килә бит моның. Озак уйлап тормадык, **ТӘТИ АПАНЫҢ ИҢ МАТУР КҮЛМӘГЕН АЛЫП, ҖӘЕП САЛДЫК ТА, КУРЧАКНЫ КҮЛМӘК ИТӘГЕНӘ ЯТКЫЗЫП КЫНА, ИКЕ КАТЛАП КИСЕП ТӘ АЛДЫК.** Җайлы бит, тоташтырып тегеп куясы гына калды...

ЯЗМЫШ ДИГӘН НӘРСӘ БАР УЛ. Илдарым соңгы тапкыр тауларга җыенганда, мин аны җибәрмәскә ничекләр генә тырышмадым! Ниндидер фаҗига булырын сизеп, җан калтырап тордым... Үзе дә күңел каршылыклары белән китте. Тик бармыйча кала алмады. Менә шул вакытта язмыштан узмыш юклыгына инандым.

Университетны тәмамлаганда, Мөхәммәт абый Мәһдиев Мәскәүгә Әдәбият институтына укырга керергә «кодалады». Мин ике дә уйламый, «юк!» дидем. Ул: «Беркайчан да, уйламыйча, өздереп җавап бирмә, уйларга ара калдыр», – дигән иде. Бер-ике көн уйлагач та, җавабым үзгәрмәде. Шунда ул: «Үкенерсең әле бу кирелегең өчен, мине исеңә төшерерсең, – диде. – Сине анда, билгеле, берәү дә язарга өйрәтмәс, ләкин дөньяң киңәер иде». **МӨХӘММӘТ АБЫЙНЫҢ СҮЗЛӘРЕН ЕШ ИСКӘ ТӨШЕРӘМ.**

Хәзер инде үзем яшьләргә шундый киңәш бирәм. **«МӨМКИНЛЕКНЕ КУЛДАН ЫЧКЫНДЫРМАСКА КИРӘК, БИГРӘК ТӘ УКУ МӨМКИНЛЕГЕН»,** – дим. Кызым Айсылу киңәшләремә колак сала дип әйтә алам.

ВАКЫТ ТИЗ ҮТӘ. Гомер — күз йомып алган ара кебек кенә. Без бала вакытта әбиләр бар иде, алар китте; алар урынына әниләр калды – алар да китте. Инде безнең буын әбиләр урынын ала бара... Еш кына шул узган гомерләрне тизләтелгән кинокадрлар кебек күз алдымнан үткәрәм...

Кешенең дуслары күп була ала дип уйламыйм. **ТАНЫШЛАР, ФИКЕРДӘШЛӘР, ХЕЗМӘТТӘШЛӘР... КҮП БУЛА, Ә** менә **ЧЫН ДУС БЕР-ИКЕ ГЕНӘ.** Һәм син аңа үзеңә ышанган кебек ышана аласың. Ахирәтем Гөлсинә белән инде 35 ел дуслар без.

Ахирәт дус дигән төшенчә бар безнең халыкта. Хәзер ул югалып бара инде. Фани дөньяда гына түгел, бакыйлыкка күчкәч, ягъни **АХИРӘТТӘ ДӘ ДУС БУЛЫРГА СҮЗ КУЕШКАН КЕШЕЛӘР БУЛА УЛ.** Дәү әниемнең фанилыкта бер генә күрешкән ахирәт дусты бар иде. Буага barганда поездда танышканнар. «Юл буе сөйләшеп бардык, якын туганым кебек, бөтен уй-фикерләр уртак булып чыкты. Шулкадәр күңелгә якын кеше булды ул, башка күрешә алмаячагыбызны аңлап, ахирәттә дус булырга сүз куештык», – дип сөйләгән иде дәү әнием.

ШАГЫЙРЬЛЕК – АЛЛАҺНЫҢ МИҢА БЕР РӘХМӘТЕ, БӘЛКИ ЙӨКЛӘМӘСЕДЕР. Мин шагыйрь булыйм әле, дип кенә шигырь язып булмый, күңелеңә тулганны дөньяга чыгаралмый кала алмаганга язасың бит. «Нәкъ мин уйлаганны шигырьгә салгансың», — дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Кеше җанындагы хисләрне сүзгә күчерә алу сәләте миңа бирелгән икән, мин аны үтәргә тиештер.

PRESSA.RU

ҖАВАПЛЫЛЫК ХИСЕН ШИГЫРЬ ЯЗУЫМНАН, ШАГЫЙРЬ БУЛУЫМНАН ГЫНА, ДИП ӘЙТӘ АЛМЫЙМ. Бу хис бездә кечкенәдән үк бар иде. Әти-әни җитәкче урыннарда эшләгәч, безнең начар укырга, тәртип бозарга хакыбыз юк иде кебек. Кемнеңдер бездән моны таләп иткәнен хәтерләмим, ул ничектер күңелгә салынган инде. Начар билге алсам, моның өчен миңа эләгә, дигән курку түгел, әти-әнинең йөзенә кызыллык киләчәк, дигән уңайсызлану бар иде.

БЕЗНЕҢ ХАЛЫКТА БАСМА СҮЗГӘ, АБРУЙЛЫ ШӘХЕСНЕҢ ФИКЕРЕНӘ ИХТИРАМ ӘЛЕ ДӘ ЗУР, шуңа күрә язучы кеше кәгазьгә төшергән һәр сүзенә зур җаваплылык белән карасын, танылган шәхесләр сүзләрен, бигрәк тә сәхнәдән, мөнбәрдән җиткергән сүзләрен үлчәп сөйләсен иде!

Яшьлек максимализмы белән вакыйгаларга, кешеләргә җиңел генә бәя биргән, дөньяны ак һәм карага гына бүлеп караган вакытлар миндә дә булды, әлбәттә. Әмма яши-яши күп нәрсәне үлчәп-тикшереп кабул итә башлыйсың. Кешеләрнең көчсезлеген кичерергә өйрәнәсең. **ШУЛАЙ ДА МИН БЕРНИНДИ ШАРТЛАРДА ДА КАБУЛ ИТӘ АЛМАСЛЫК НӘРСӘЛӘР БАР:** яла, кемгәдер зыян эшләү максатыннан булган ялган; ялагайлык, сатлыкҗанлык, икейөзлелек.

ТАТАРНЫҢ ИҢ БӨЕК ӘДИБЕ – ТУКАЙ. Менә бүген дә, янә туган телебезнең язмышына куркыныч янаган вакытта, телебез, милләтебез сагына иң алдан Тукай чыгып басты. «Туган тел»е белән яшьләрне күтәрде. «Туган тел» шигыре күптән инде шигырь генә түгел, татарның гимнына, милләтебезнең символына әйләнде ул.

ЯЗУЧЫ – СҮЗ КӨЧЕ БЕЛӘН КЕШЕ ҖАНЫНА КАГЫЛА БЕЛГӘН, АНЫ ХИСЛӘНДЕРӘ, УЙЛАНДЫРА, ГАМЬЛӘНДЕРӘ АЛГАН КАЛӘМ ИЯСЕ. Аның осталыгы, зурлыгы нинди темага язуына карап билгеләнми, ничек язуына карап бәяләнә. Ни турында гына язса да, фикер камиллеге, каләм төгәллеге мөһим.

Язучының милли темага керү-кермәве – ул шәхеснең күңелендәге милләтпәрвәрлек хисеннән килә. Әгәр ул тойгы күңел түрендә утыра икән, язучы аны кәгазьгә төшерми кала алмый; андый хис җанын талкымый икән, көчәнеп язып кына тулы канлы әсәр тудыру мөмкин түгел. **ЧЫН ИҖАТ БИТ УЛ СУЛАГАН СУЛЫШ КЕБЕК,** ул табигый генә була ала.

ТУГАН ТЕЛЕН БЕЛМӘГӘНЛЕКТӘН, ИКЕНЧЕ ТЕЛДӘ ИҖАТ ИТӘРГӘ МӘҖБҮР ЯЗУЧЫЛАРНЫ КЫЗГАНАМ МИН. Алар барыбер ул халыкныкы булып китә алмый...

Мөселман кешесе байлыкка омтылырга, әмма ул байлык хәләл булырга тиеш, диләр бит инде. Дөрес тә, байлыгы булса, ул зәкят бирә, сәдака бирә ала, башкаларга да булыша ала дигән сүз. **МИН ДӘ БАЙЛЫККА НӘКЪ ШУНДЫЙ, МӨСЕЛМАННАРЧА МӨНӘСӘБӘТТӘ.** Байлык минем өчен үзмаксат түгел, шулай да аскетизмны да хупламыйм.

МАТУР ИТЕП ЯШӘҮ МАТДИ БАЙЛЫККА ГЫНА БӘЙЛЕ ТҮГЕЛ. Ул күңел байлыгыннан тора. Бу очракта мин һәрвакыт укытучыларым — Разит абый белән Резеда апа Сибатовларны искә алам. Матди байлык артыннан кумыйча, тормышның гади шатлыкларыннан ямь табып, матур, мәгънәле итеп яши белә алар: кышларын чаңгыда йөрү, җәйләрен велосипедка утырып кына су буендагы дачаларына җилдерү, күзгә урманның матурлыгына хозурлану, балык тоту, бакча үстерү...

ЯШӘҮ ӨЧЕН КЕШЕГӘ АРТЫК ЗУР МАТДИ БАЙЛЫК ТА КИРӘК ТҮГЕЛ БИТ. Никадәр генә байлыкка ия булмасын, ул берьюлы ике урындыкта утыра алмый: бер урындыкка утырып ашый, бер караватка ятып йоклый... Әйе, дөнья күрергә, сәяхәт итәргә, матур киенергә, тәмле ашарга, кыскасы, тормыш хаҗәтләренә акча кирәк.

МИН ЯЛГАНЧЫЛАРНЫ ҺӘМ ЯЛАГАЙЛАРНЫ ЯРАТМЫЙМ. Андыйлардан ерак торырга тырышам.

ЯЛГАН БЕЛӘН ЯШӘҮ АВЫР ЙӨКТЕР УЛ. Ялганчы булыр өчен кеше бик зиһенле, хәтерле булырга тиеш бит.

Кеше артында бернәрсә дә сөйләмим, дисәм, бу чеп-чи ялган булачак, чөнки без бөтенебез дә сөйлибез. Ләкин **МИН КЕШЕ АРТЫНДА ҮЗЕ АЛДЫНДА ДА ӘЙТӘ АЛГАН СҮЗНЕ ГЕНӘ СӨЙЛИМ**.

ДӨРЕСЛЕКНЕ КЕШЕНЕҢ ЙӨЗЕНӘ БӘРЕП ӘЙТҮ АВЫР. Үзенә әйтә алмасаң, артыннан да сөйләмәскә кирәк. Бер хәдистә бугай, берәр кешенең кимчелеген күреп тә, башкаларга белдерми кала алу, зур савап, дигән.

Гадәттә, **ИКЕЙӨЗЛЕ КЕШЕЛӘРНЕҢ** дошманнары булмый... Ләкин андый кешеләрнең **ЧЫН ДУСЛАРЫ ДА БУЛМЫЙ.**

Безнең илебездә халык шулкадәр басынкы, без елмая белмибез; барыбыз да үзалдына карап, тормыш артыннан йөгерәбез. Чит илләргә чыксаң, иң элек кешеләрнең елмаюлары күзгә ташлана, шуңадыр ул мохит күңелдә якты тәэсир калдыра. Казанда Универсиада узган вакытта шәһәребез, халык шулай бер үзгәреп алды бит, сиздегезме? **КЕШЕЛӘР ЕЛМАЯ БАШЛАДЫ.** Чөнки читтән килгәннәр елмая иде. Елмаю — елмаю тудыра.

Батыр булу – авыр. **МӘЙДАНДА БАТЫР БУЛУ ӨЧЕН ЭЧКЕ БАТЫРЛЫК КИРӘК.**

Фикерләр тупланмасын Ландыш ӘБҮДӘРОВА теркәде.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

БӘХЕТЛЕ БУЛЫРГА ОЯЛМАГЫЗ!



Айсылу
НӘГЫЙМОВА,
психология фәннәре
кандидаты,
социология фәннәре
докторы, профессор.

Белгеч киңәше

Иске елны озату, яңа елны каршылау һәрвакыт хыяллар белән бәйләнгән. Ел ахыры якынлашуга, узган елга нәтиҗәләр ясап, ирешелгән уңышларга сөенеп яки булдыра алмаганнарга көенеп кенә калмыйбыз, ә үзенә күрә киләсе ел өчен планнар корып, максатларны билгеләргә дә тырышабыз.

Тик тагын бер ел үткәннән соң, төзегән планнарның шул килеш калганлыгы ачыклана, ә шуның аркасында кешенең үз-үзенә куйган бәясе төшә, үз көченә, булдыклылыгына ышанычы кими. Ничек шулай килеп чыга соң? Гомумән, дөрес хыялланып буламы?

Психологик яктан караганда, хыялның үзенә күрә бер нигезе дә бар. Хыял – безнең фикерләүдә туган образ, һәм ул, образ хәлендә булса да, матди дөнья белән тыгыз бәйләнештә тора. Шуңа күрә дә хыялда образ тудырганда аны реаль җирлектә күзаллыйбыз, ягъни хыялга чынбарлык төсмерләре бирәбез. Хыялның позитив формада булуы шарт, чөнки безнең аңыбыз образның тышкы сүрәен кабул итә һәм шуның белән «эшли» башлый. Әйтик, сез үзегезгә сәламәтлек телисез икән, нәкъ менә «сәламәт булырга язсын» дигәнрәк теләкләр теләгез. Шуны ук аңлатучы «авырып китәргә язмасын» дигән гыйбарә аңыбыз тарафыннан нәкъ менә киресенчә кабул ителә: беренче очракта төп образ булып «сәламәт» сүзе торса, икенчесендә «авыру» сүзе тора, һәм аңыбыз да икенче очракта нәкъ капма-каршы юнәлештә эшләячәк.

Кайберәүләр «нигә инде хыялланып торырга, алар барыбер тормышка ашмый минем» шикеллерәк позициядә тора. Мондый укучыларыбызга шуны әйтәсе килә – суга керми генә йөзәргә өйрәнеп булмый. Хыялланмый, ният итми генә үрләр дә яулап булмый.

Нәкъ менә шундыйлар өчен берничә киңәш:

Иң беренче адым. Нинди хыялыгыз бар? Чын-чынлап нәрсәгә ирешергә телисез? Шул турыда ныклап уйлагыз. Билгеле, һәркемнең күңелендә йөрткән нинди дә булса яшерен хыялы, уе бар. Тик берәүләр ул хыялны максатка әйләндерә, ә аннан соң инде тормышка да ашырып куя. Ә икенчеләре исә, төрле нәрсәләрдән шүрләп, хыялын тормышка ашыруны башына да кертеп карамый. Үзегезгә сорау бирегез: «Әгәр дә мин бернидән дә курыкмасам (хыялның буй җитмәслегеннән, каршылыклардан, үз көчемә ышанмаудан...) нәрсәгә ирешергә теләр идем?» Һәм... менә шул үзегезне куркыткан нәрсәләргә күзне йомып, көрәшкә ташланыгыз!

Икенче адым максатны дөрес билгеләү белән бәйле. Максат билгеле бер вакытка куела: хыялыгызга күпме вакытта ирешергә телисез? («Кайчан да булса инглиз телен өйрәнергә теләр идем!» дигән максат – максат түгел.) Максатның күләмен билгеләү дә мөһим («бер елда 730 инглиз сүзе өйрәнәм»). Гомумән, ул мөмкин кадәр тормышчан булырга тиеш. Дөрес билгеләнгән максатны тормышка ашыру планын төзү дә җиңел. Вакыт һәм күләмнән чыгып, көчегезне дөрес бүлү, даими рәвештә эшләү мөмкинлеге туа (һәр көн саен нибары ике инглиз сүзе өйрәнергә тиеш буласыз). Димәк, хыял да эфемер формадагы образдан чынбарлыкка әверелә. Тагын бер әһәмиятле нәрсә – көчегезне дөрес чамалагыз! Берьюлы күп нәрсә планлаштырып, берсенә дә ирешә алмый калу куркынычы бар.

Өченче адым. Хыялыгызның позитив образын күз алдына китерегез. Ул образның төрле нечкәлекләренә кадәр күзалларга тырышыгыз. Кайберәүләр хыялларын тагын да анығрак күзаллау өчен, аны визуальләштерә: әйтик, хыялның рәсемен ясап яки панно рәвешендә чигеп, диварга элеп куя, аны чагылдырган плакатлар, аппликацияләр ясый һәм башкалар.

Фикернең матди булуын истә тотыгыз. Тагын шуны да онытмагыз, хыялны күзаллаганда детальләр мөһим роль уйный. Әйтик, яңа елда эшкә урнашуыгызны телисез икән, нинди эшкә, никадәр хезмәт хакына һәм башка үзенчәлекләрен күзаллагыз. Югары белемле булуыгызга да карамастан, бары фәкать идән юучы эшен генә тәкъдим итеп куюлары да бар бит! Иң әһәмиятлесе – хыялны бары тик позитив сүрәткә «урарга» онытмагыз!

Хыял тормышка ашсын өчен, өч төп шарт бар: дөрес максат (аны ничек куярга кирәклеге хакында сөйләштек инде), үз көчеңә ышану һәм даимилек. Хыялны чынга ашыру бездән билгеле бер ресурслар таләп итә. Үз көченә ышану – ул кешенең ресурсларын дөрес бәяли һәм куллана белүе. Бары тик ресурсларыннан дөрес файдалана белгән кеше генә максатына ирешә ала. Кешенең ресурслары – ул аның белеме, сәламәтлеге, вакыты, чыдамлыгы һәм башкалар. Шулай ук ресурслар булып якыннарыбызның, дусларыбызның, гаиләбезнең безгә күрсәткән ярдәме, һәрдаим аңлап, терәк булулары да тора ала.

Даимилеккә килгәндә, бу гади генә принцип чыннан да могҗизаи көчкә ия. Эшне даими эшләүнең берничә өстенлеге бар: беренчедән, тормышыгызны билгеле бер режимда оештыруны организм күпкә җиңел кабул итә, бу нәрсә физик арудан, күңел төшенкелегеннән дә саклый. Икенчедән, эш даими рәвештә башкарылса, планлаштыру гадиләшә, димәк, эшегезне оештыру өчен күп көч сарыф ителмәячәк.

Гомумән, безнең тормышыбыз – күпчелек очракта нәкъ менә кайчандыр безнең күңелдә туган, бәлки, дөрес формада чагылдырылмаган теләкләр һәм фикерләр нәтиҗәсе ул. Теләкне дөрес итеп теләү генә түгел, ә инде ул тормышка ашкан очракта аңа дөрес мөнәсәбәт күрсәтү дә зарур. Тормышка ашкан хыялларны сөенеп һәм сөенечегезне яшерми каршы алыгыз. Аның өчен язмышка, якыннарыгызга рәхмәтле булуыгызны сиздерегез. Бәхетле булырга оялмагыз!

PRESSA.RU

УЛ НИ ДИСӘ, ШУЛ БУЛА...

ИРЕН ЯРАТКАН, ИРЕНӘ ЫШАНГАН ХАТЫН ГЫНА ӘЙТЕР МОНДЫЙ СҮЗЛӘРНЕ.

Мәдинә АВЗАЛОВА



Бу авылда булганым бар инде минем. Бер килүемдә йортларының төзеклегенә, урамнарының чиста-матурлыгына, юлларының шомалыгына сокланып йөргәнем дә бар. Аягында нык басып торган Вахит крестьян хуҗалыгының яңа гына төзелгән фермаларына һәм дә төзелергә тиешле ферма корылмаларына сәяхәт кылганымны да яхшы хәтерлим. Каты куллы хуҗаның эшне беркем дә булдыра алмаганча оештыра белүенә хәйран калган идем шул чагында. Җитәкче Нәфыйк Хөсәенов турында: «Сорасаң, өеңдәге әйберен ике дә уйламый бирә, ә менә хуҗалыктан бушлай бер бөртек бодай да бирмәс», – дип әйткәннәре дә истә калган.

Гомумән, соңгы елларда Кукмара безне уңышлары белән әледән-әле куандырып кына тора. Туган ягым булганга гына мактанып әйтмим мин моны. Районда әле яңа мәктәп, әле заманча итеп эшләнгән балалар бакчасы сафка баса. Әнә тагын искиткеч бер яңалык: чаңгычылар өчен чаңгы базасы ачылган! Бусы инде республика күләмендәге мөһим чара, чөнки ул чаңгычылар, спортчылар тәрбияләүгә йөз тота. Белмим, кешеләре бик уңганмы, җитәкчеләре халык өчен шулай тырышамы... Эшләре һәрчак уң килә дә тора аларның. Кукмара район башлыгы урынбасары Равия Абдулла кызы Кәримуллина да Фәхретдиновлар белән таныштыруны шундый сүзләрдән башлады. Әйткәнебезчә, эшләр һәрчак уң килеп торсын өчен, башта икәвең бергәләп, кем әйтмешли, җиде пот тоз ашарга кирәк икән әле. Бер-береңә булган хисләреңне тормыш сынаулары аша югалтмыйча, түкми-чәчми шушы көннәргә китереп җиткерергә кирәк икән әле.

...Алдыбызда диванга җәеп салган кочак-кочак хатлар... Моннан 30 ел элек язылган хатлар. Кайберләрен инде танырлык та түгел. Шулай да берсен алып укый башлыйм да уңайсызланып куям. Сөйгәненә бөтен җанын ачып салган ул хат бары аның өчен, аның колагына гына бит. «Мин сине гомер буе яратырмын, гүзәлем!»

– Һаман да саклыйсызмы? – дим, гаҗәпкә калып.

– Яшьлек бит ул, кайчак алгалап укыйбыз без аларны... Ул шундый инде... хисле кеше. Кияүгә чыкканда, әллә ниләр вәгъдә итмәсә дә, «бәхетле булырбыз» дигән сүзләрне әйтте шикелле.

Аның белән «рәхәттә яшим» дигән көннәргә китереп җиткергән юллар буйлап тагын бер кат үткәннәргә сәяхәт кылып алабыз. Бәхеткә илтә торган юллар текә ул. Авыл читендә балкып торган ике катлы йорт та, җылытылган сарай-гаражы, теплицасы да, күз иңләмәс бакчасындагы балыклы күле дә, хәрабәдән, көлдән күтәрелгән искитәрлек сәүдә үзәге дә... берсе дә, берсе дә күктән яумаган аларга. Моның өчен Эльмира белән Рифкать Фәхретдиновларга Себер ачысын да аз татырга туры килмәгән. Әңгәмәдәшемнең сүзне бик ерактан, уратып башлавының сәбәбен аңлыйм мин. Адәм баласындагы сыйфатларның яхшысы да, яманы да нәселдән бит...

Нәсел җепләре

Үзәктән ике-өч чакрымда гына урнашкан Татар Кукмарасы халкы өчен Эльмираның әтисе Нургали абзый белән әнисе Саймә апа соңгы көннәренә кадәр серле бер пар булып – «интеллигентлар гаиләсе» булып калганнар. Клубка чыксалар да, кибеткә барсалар да – икәүләшеп, кулга-кул җитәкләшеп... Бары шулай. Нургали абзый тумышы белән Мәскәүдән. Каян барып чыгасы иткән аларның әтиләре илебез башкаласына?! Ничек шулай булган?!

– Бабам Муллахмәт шунда урнашып калган, – дип аңлата башлый Эльмира ханым. – Аннары әбием белән танышкан. Бик тәвәккәл булган дип сөйлиләр аны. «Бабаң миңа тәкъдимне күпердән чыгып барганда ясады. Юк дисәң, тотып атам хәзер күпердән, дип әйтте ул миңа», – дип көлдерә иде әбием.

...Аннан сугыш чыга. Бабасы әбисен төп нигезе булган Чишмәбаш авылына алып кайта. Һәм әйтә: «Үлде дигән хәбәремнән соң биш ел үткәч, кияүгә чыгарсың», – ди. Әйтерсең ул яу кырында ятып калачагын алдан ук белгән, сизенгән. Ә Мәгърүфә әби озын-озак яшәп, 99 яшендә дөнья куя.

«Яшел эшләпә»дән башланды

Урта мәктәпне ул Кукмараның 1 нче номерлы мәктәбенә йөреп тәмамлый. Спорт белән шөгыльләнә. Ярышта 1 нче урыннар да алгалый. Мәктәпне тәмамлагач, физкультура институтына барам дигән хыялы да була кызның. Әтисе рөхсәт итми. «Кыз бала эше түгел», – дип, кызны бу уеннан кире кайтара. Һәм кыз парикмахерлыкка укырга керә.

– Унберенчене тәмамлап килгән чак. Без Вахит авылына «Яшел эшләпә» спектакле белән бардык, – дип искә ала Эльмира. – Рифкать белән беренче мәртәбә шунда таныштым. Дөресрәге, беренче күрүем шунда булды. Аның ялга кайткан чагы. Машиналы, бай егет... Утыра бу урындыкта ике яктан ике кызны кочаклап. Алай икән, дим. Тик ул спектакльдән соң миннән калмады инде. Танышуыбызга ай ярым дигәндә, Чукоткасына китеп барды. Хат язышып торырга, аралар ерак булса да, аерылышмаска, бергә булырга сүз куештык.

– Хат язарга бик ялкау иде ул, – ди Рифкать, вакыйгаларга үзенчә аңлатма биреп. – Минем биш хатыма бер җавап хаты яза торган иде. Күз алдына китерегез әле: өзгәләнеп, сагынып язган мәхәббәт хатларын башта әнисе ачып укый, аннары үзе... (*Ул көлеп куя.*)

«Гүзәл»еннән башка яши алмавын тәмам аңлаган Рифкать, ел да ике ай дигәндә, янә туган авылына кайтып төшә. Вакытны озакка сузмыйча гына туй ясыйлар да икәүләшеп Себергә китеп баралар.

Чукоткадагы тормыш

Дөнья чите булса да, ачы бураннар, үзәккә үтәрдәй салкыннар җанны кыйса да, Эльмира андагы тормышны куркыныч бер әкият итеп сөйләми. Янәшәсендә сөекле ире булгангамы, бирегә килгән төрле милләт халкының бер гаилә булып яшәвен оныта алмагангамы, тоташ кышлардан торган ул вакытларны бик сагынып, юксынып искә ала. Хәер, аңлашыла бу. Ни дисәң дә, шунда аларның кызлары Гүзәл белән Гөлназ туган. Ни дисәң дә, иң матур яшьлек еллары, бернигә карамый, шунда узган!

Ул – декабристлар хатыны шикелле. Ире артыннан дөнья читенә – Чукоткага кадәр барып җиткән.

– Ерак дип тә, ничекләр яшәрбез дип тә...

– Юк-юк, – дип туктата ул мине, – Таныш булмаган кешеләр арасына бармадык ич без. Рифкатьнең өч абыйсы да шунда иде. Туганнар арасына барып кердек. Приисктан фатир бирделәр. Рифкать инде ул чагында ук – бригадир. Институтта инженер-механик булырга укып йөргән чагы. Икенче төрле анда, – ди ханым, һаман бер сүзгә әйләнеп кайтып. – Һәркайсыбызга – аерым фатир. Ишекләрдә йозак юк. Балалар рәхәтләнеп бер-берсенә кереп-чыгып йөриләр. «Ник кердең?» – дип сүз әйтүче юк. Милләтең белән берәү дә кызыксынмый: хохолы, молдаваны, урысы, татары, бер-берсе өчен борчылып, бер гаилә булып яшиләр. Йөкле, кечкенә балалы хатыннарга да хөрмәт зур анда. Аларны бездәгечә чиратларда тотмыйлар, шундук алга үткәрәләр. Шул арада үзләре белән булган күңелсез вакыйганы да сөйләп ала.

– Кызым кайнар суга пешеп, хастаханәгә элэктек. Без яшәгән бистә белән хастаханә арасы шактый ерак. Хәлне белергә барып йөрүләр үзе бер проблема иде. Шәфкать туташлары, «килүчең юк» дип, ашарга кертәләр, безнең бистәдән килгән бер белмәгән шоферлар күчтәнәч кертеп чыгалар иде.

Килгәч тә, ире аңа: «Өйдә генә утырырсың, эшләмәссең инде», – ди. Кул кушырып утыра торган кешеме инде ул?! Килүгә үк эш белешә башлый. Таба да. Алтын да

PRESSA.RU



юа, бензовозда шофер да, каравылчы булып та эшли. Үзе әйтмешли, эшләмәгән эше калмый.

Яшәү рәвешләренә карaганда, аны авыл дип тә әйтмәссең Бөтен кирәкярагы – үзләрендә!

Унбиш ел гомер шунда уза. Ялга кайткан арада авыл кырыендагы буш урында Фәхретдиновларның ике катлы зур йортлары күтәрелә. Бөтен шартына туры китереп, бөтен уңайлыклары белән... Аннары гына алар туган якларына – туган авылларына кайтып урнаша. Шул көннән авылга яңа сулыш кабынгандай була. Тиктормас Фәхретдиновлар авылга зур үзгәрешләр алып килә.

Авылның үз «Леруа Мерлен»ы

Кайтуын кайталар, тик алга таба ничек яшәргә? Ни белән шөгыльләнергә? Авылда эш юк, акча юк. Бөтен авыл халкы ду китереп мал асрый. Ашарга түгел, сатарга.

– Рифкатьнең бабасы сәүдәгәр булган бит, – дип сөйли Эльмира. – Аны бер кисәк ит өчен сөргенгә сөргәннәр. Ул шунда харап булган. Шул сәүдәгәрлек каны уйнаганмы инде, ирем энесе Мәсгут белән авыл халкыннан мал җыеп, Мәскәүгә ташый башлады. Бераздан Себердән кайткан акчага икәүләшеп бензоколонка сатып алдылар.

Ә тагын бераздан абыйлы-энеле Фәхретдиновлар Кукмарага бара торган юл кырыенда «Туган як» кафесы төзи башлыйлар. Төзелешне алар алып барса, төзүчеләрне көненә биш мәртәбә ашату – килендәшләр Эльмира белән Минзилә өстендә.

– Әйтүе генә җиңел, биш мәртәбә... Ул вакытта якын-тирәдә бер ашханә, бер кафе юк. Барын да үзебезгә пешерәсе. – Шул чакларны исенә төшерепме, ханым авыр сулап куя. – Әйбәт ашасыннар дип, сыерга кадәр сатып алдык. «Нәрсәгә инде ул сыер сиңа?» – ди торган иде Рифкать. «Кирәк, мин әйтәм. Туйганчы, тиешенчә ашасыннар...» Шулай итеп, ел дигәндә, салып бетерделәр.

Бүген ул кафе тулысы белән кече энекәше карамагында. Ә Эльмира белән Рифкатьнең – үз бизнесы. Алар хәзер иске клуб – җимерелеп беткән бер бина урынына авылны үзенә каратып торган менә дигән сәүдә үзәге төзеп куйганнар. Зур ул, аның ишегалдында хәтта фонтанына кадәр бар! Рифкать сәүдә эшләрен тулаем хатынына тапшырган. Хатынының бу йөкне тарта алачагына, булдырачагына ышана ул.

Бизнесвумен Эльмира Нургали кызы Фәхретдинова белән сәүдә үзәгендә йөрибез. «Леруа Мерлен» ич бу», – дим, күргәнемнән хәйран булып. Ул канәгать елмая. «Алай ук булмаса да, халык өчен кирәкле бөтен нәрсә бар биредә, – ди эшмәкәр. – Сатып алучының ихтыяҗын өйрәнеп кенә торабыз. Бездә кеше әйбәт яши, мул яши. Кирәксенгән әйберләрен көне-сәгате белән алып бетерәләр. Берсеннән-берсе күреп тә алалар. Соңгы вакытта чәчәк савытлары ала башладылар. Тышка утырырга дип... Җәй көннәрендә капка төпләре, ишегаллары шау чәчәктә була безнең. Авыл әкренләп ямьләнә, шәһәрчә төсмер ала бара. Азык-төлек сатудан гына башлаган идек, – ди ул, канәгать елмаеп. – Тырыша торгач, барып чыкты бит».

Шулай икән. Төрле түгәрәкләре булган мәктәбе, яңа гына салынган Мәдәният сарае, мәчете... Без килгәндә Мәдәният сарае янында кызу эш кайный иде. Тирәсен рәтләп ятулары икән. Мәчетенә дә кереп чыктык. Эльмира ханым мәчеткә ремонт ясаганда ничә мәртәбә генә Казанга кирәк-яракка баруы турында сөйләп ала. «Хәрамына керә күрмә, мәчет өчен эшләнә торган эш», – дип, әллә ничә тапкыр кисәткән аны ире. Хәзер Аллаһы Тәгаләйорты авыл уртасында кояш булып балкып тора. «Бик зирәк,

акыллы кеше булып чыкты», – дип, мулланы да мактап куя юлдашым.

Мәчет янында гына түгәрәк күл. «Җəен килегез. Аның матурлыгы!»

Матурдыр, күз алдыма китерәм. Авылда мондый күлләр тагын дүртәү икән әле. Фәхретдиновларның бакчаларында да бар андый күл. Балыклы күл. Җәен шунда балык тоталар, су керәләр. Гәрчә янәшәсендә генә бассейн эшләнеп ятса да, күлгә җитәме инде?! «Рифкать башлап йөри, ул күрсәтеп бирә», – ди, үзалдына соклангандай итеп хатын.

Гаилә хәйрия эшләре белән дә шөгыльләнә. Аның ире менә инде ун ел укучы балаларның волейбол ярышларына спонсорлык итә.

«Акча санаганым юк»

– Алайса, сез бик бәхетле кеше инде, – дим, ишеткәнемә аптырап китеп. – Сәүдәгәр акча санамыймы?

– Анысын мин иремә тапшырам. Товар алып кайту, поставщиклар, кадрлар белән эшләү – үземә.

– Эльмира ул идәнгә төшкән акчаны да иелеп ала торган кеше түгел, – дип көлә Рифкать.

Акчага исе китми, акча кадерен белми дию түгел ул аның. Идәнгә төшкән акчаның беркая китмәвенә, бер-берсенә ышаныч булуына ишарә генә.

Фәхретдиновлар өендә һәрчак өй тулы кунак, өстәл тулы ризык булыр. Йорт хуҗалары бусагадан үткән кешене чәй янына утыртмыйча җибәрми дә. «Мәрьям әни безне шулай өйрәтте. Бер кешене дә борып чыгармагыз. Бәлкем, аның тамагы ачтыр, ди торган иде», – дип дәвам итә сүзен Эльмира. Аның 83 яшенә җитеп вафат булган кайнанасы, дәртдәрманы бар чагында, тире җыярга чыгып китеп, өчәр көн шулай йөреп кайта торган булган. Шунда аңлагандыр ул юлчыга карата кадер-хөрмәтнең ни икәнлеген. Авырлык килгәндә түзем, сабыр булырга өйрәткән ул балаларын.

– Йөрәккә авыр операция кичердем. Бу – 2004 елның 27 декабрь көне, – дип сөйли Рифкать, кайгыда да, шатлыкта да бергә, дигәнебезгә аңлатма бирәсе итеп. – Унике көн беркая чыкмыйча янымда утырды. Без бер-беребездән башка яши алмыйбыз. Кайчак: «Санаторийга, диңгезгә барып ял итеп кайт», – дип әйтәм дә: «Синнән башка нишлим анда...» – ди. Һаман бер сүз аның...

– Рифкать шактый вакыт: «Җаным авырта», – дип йөрде. Алайса, белгечләргә күреник дип, Казанга алып киттем. Казан шәһәренең 6 нчы хастаханәсендә операция ясадылар, – дип дәвам итә иренең сүзен хатыны. – Иртән 9 да керешкәннәр иде, кичке 5 тә тәмамладылар. Үпкә-йөрәгә өч сәгать эшләми торды. Операциядән соң төнге 11 дә: «Үзе сулый башлады», – дип чыгып әйттеләр. Шуңарчы ни үле, ни тере утырдым. Ул бит минем шикелле, тик тора белми. Кайтуга ук атылып эшкә чыкты. Ә мин – аның артыннан... Контора ишеген ачып кертәм. Өйгә кайткач, аяк киемнәрен салдырам, өстен чишендерәм. Руль артына да үзем утырдым. Саклыйм, янәсе. Йөрәк бит, уен эшмени? Хәзер дә әледән-әле табибларга күренеп торабыз. Минем аны югалтасым килми. Минем өчен дөньяда иң кадерле кеше ул.

Без аның белән бик бәхетле. Әлегәчә бер-беребезне яратабыз. Әгәр дә рәхәттә яшим, дип әйтәм икән, бу – шулай, чөнки ярату кешене шулай итә. Безгә карап балаларым да бәхетле. Гаиләдә беркайчан да тавыш чыкканын хәтерләмим. Рифкать белән безнең фикерләр беркайчан да кисешми. Ни өчен дип сорыйсызмы? Чөнки мин гел ул дигәнчә яшим. Ул ничек әйтә, нәрсә дип әйтә, шулай була. Әйтик, ирем караны ак дип әйтә икән, ак була. Акны кара ди икән, кара була. Ир кеше белән сүз көрәштерергә ярамый. Мин кызларыма да, танышларыма да әйтәм: ирегезгә каршы сүз әйтмәгез. Тавыштан котылырсыз, дим.

Соңга калып кына тапкан уллары Айрат та аларның зур шатлыгы, юанычы. Эльмира төпчеген 40 яшендә таба. Туасы җанның малай буласын белгәч: «Йә Хода, дөм ташламагансың икән әле», – дип, чиксез куана ир. Айратка хәзер – 12 яшь. Без килгәндә ул Кукмарада көрәшчеләр ярышында иде. Кызлары Гүзәл белән Гөлназ Казанда яшиләр – икесе дә икътисадчы, икесе дә кияүдә. Гүзәл үзе ике бала әнисе. Рифкать белән Эльмира дәү әти белән дәү әни дә икән әле. «Шимбә-якшәмбе алар гел шушында инде», – ди әниләре.

Ял көннәре бу гаилә өчен үзе бер бәйрәм. Кунаклар килер, балалар кайтыр. Алар кайсы кая таралгач, Эльмира, «Буран»ына атланып, якында гына ымсындырып торган тауларга менеп төшәр. Рифкате белән чаңгы шуып керер. Ни дисәң дә, спортчы да бит әле ул! Кышын – шулай, ә җәй көннәрендә алар икәүләп – урманга җиләккә, агач яфракларына сары йөгергәч, гөмбәгә йөрерләр. Ярату яшәгән җирдә башкача була да алмый...

«Беркайчан да кешене каргама, начарлык теләмә. Үзеңә әйләнеп кайтыр», – дип әйтә иде әнисе.

Болай дигәннән... Ишегалдында озын сакаллы өч карт утыра икән. Узып баручы хатын аларны чәй эчәргә чакыра. «Ирең өйдәме соң?» – дип кызыксына картлар. «Юк», – ди хатын. «Алайса, керә алмыйбыз». Берзаман теге хатынның ире кайта. Хатын хәлне сөйләп биргәч, ир картларны өйгә чакырырга куша. Хатын чыга да өчесен дә кыстый башлый. «Өчебез дә керә алмыйбыз. Беребез генә, – ди картларның берсе. – Мин Мәхәббәт булам. Ул – Уңыш, ә монысы – Байлык. Ирең кайсыбызны чакыра, шул керер». Хатын, кереп, иренә әйтә. «Әйдә, Байлык керсен», – ди ир. «Уңыш керсен», – дип каршы төшә хатын. «Мәхәббәтне чакырыйк», – ди кызлары. Килешәләр. Хатын, чыгып, Мәхәббәткә дәшә. Мәхәббәт артыннан Уңыш белән Байлык та кузгала. «Мин бит Мәхәббәтне генә чакырдым», – ди хатын. «Уңыш белән Байлык Мәхәббәт артыннан калмый. Алар – гел бергә», – дип җавап кайтара карт. Фәхретдиновлар турында бугай ич бу кыйсса...

Фото: Эльвира Мөбарәкшина

PRESSA.RU

АККОШЛАРНЫ АК КИЛЕШ САКЛАГЫЗ!

Фото: Ирина Кривощекова. Компания Студия-38. http://www.38-studio.com

38 38-studio.ru

Ландыш ӘБҮДӘРОВА

Фигуралы шуу – безнең өчен һәрвакыт могҗиза, матурлык дөньясы ул. Ә менә боз шаһинәләре арасында татар кызын күрү бөтенләй яңа хисләр белән баета: монда да булдыралар бит!

Алинә исеме килешә безнекеләргә. Заһитова туганда, Кабаева нәфис гимнастика буенча берничә тапкыр Дөнья һәм Европа чемпионы булып танылa инде. 2002 елда Испаниядә узган Европа чемпионатында иң югары баскычта торганда, Кабаева үзенең исемен икенче бер татар кызына – фигуралы шуу буенча булачак спорт йолдызы Алинә Заһитовага кушарлар дип уйламагандыр да. Нәкъ менә шул вакытта бишектә шактый озак вакыт исемсез яткан сабыйга исем табыла Заһитовлар гаиләсендә. Кабаеваның әнисе дә кызының фигуралы шуу белән шөгыльләнүен теләгән бит. Тик кызу Ташкентта нәфис гимнастика белән чикләнергә туры килгән...

Ә менә Удмуртиянең башкаласы – кар-буранлы, суык кышлы Ижевскида шугалакларга кытлык юк. Боларга өстәп, хоккейчы, «Ижсталь» хоккей клубы тренеры Илназ Заһитов һәм хатыны Ләйсәннең фигуралы шуу турындагы хыялы да туры килеп тора тагын.

Җиде кат үлчәнгән юл

7 яшьлек Алинәне беренче тренеры Наталья Антипинага да әнисе җитәкләп килә. Курчак кебек матур, тал чыбыгы кебек нәзек кызчыкның

физик яктан чыдамлылыгы да сокланырлык шул. Фигуралы шуу спортына нәкъ шундыйлар кирәк. Беренче тапкыр тимераякта бозга басуга «Мин Олимпиада алтынына тырышачакмын!» диган бөек максатлар куймый әле кыз. Хәтта берничә тапкыр тимераякларын элгечкә элеп кайтып китә. Төгәлрәге, җиде тапкыр. «Спортка бер мавыгу итеп карый идем: ошаса – шуам, ошамый икән – туктыйм...» – ди ул үзе. 10 яшенә кадәр урын алмыйча, ярышларда катнашып йөри. Ижевскида алар командасы риттбергерны сикерергә ярата. Беренче чиратта югары сыйфатка йөз тоту Алинәнең холкына ук салынган.

– Хәзер ул тагын да максатчанрак. Узган ел Россия чемпионатында икенче урынны алды, яшь булгач, Европа чемпионатларында катнаша алмый иде. Быел Россия чемпионатында беренчелекне алуы Олимпиадага бару хокукы бирде. Шуңа да быелгы чемпионатның җаваплылыгы икеләтә зуррак иде, – дип ачыклык кертә Алинәнең беренче тренеры Наталья Антипина.

Этери Тутберидзе мәктәбе

Фигуралы шуу спортында Этери Тутберидзе исеме төрле мифларга төрелгән. Биш балалы гади грузин гаиләсендә үскән кыз, фигуралы шуу белән «җенләнеп», Мәскәүгә килә. Кызганыч, тренерлардан уңмый... АКШка китә... Аннан тренер булып кайта.

Бүген инде Россиянең атказанган тренеры Этери Георгиевнага эләгү – фигуристкалар өчен ярты бәхет. Аның Юлия Липницкаяның тренеры икәнен искә төшерү дә җитә. 15 яшьлек Юлиянең Сочидагы чыгышын күпләр хәтерлидер әле. Алинә дә Ижевскида вакытта аңа тиңләшергә омтылган. Бүген исә Этери Тутберидзе төркемендә ике йолдыз: «алтыннар»дан гына торган Евгения Медведева белән Алинә Заһитова.

Ә бит әле кайчан гына Этери Георгиевна Алинәне төркеменнән куган булган. Куган дип... Бу турыда күп яздылар. Без, журналистлар, андый хәбәрләрне ассызыклап, хәтта ки күпертеп, драма ясап күрсәтергә яратабыз. Ничек инде куган? Алай куып йөртергә ул бит Андерсен әкиятендәге шөкәтсез үрдәк бәбкәсе түгел! Аккош кебек Алинәнеме? Хисләр шулайрак дәвам итә. Ә менә Алинәгә этәргеч була ул: кыенлыкларны җиңеп, алга бара.

Шулай бервакыт, Мәскәүдәге ярышлардан соң, Алинә әнисе белән Этери Тутберидзе янына килә. Вакыт тар... 40 минут эчендә Алинә булачак тренерына бөтен осталыгын күрсәтергә өлгерә.

– Яңа елдан соң килегез, – дип озатып кала аларны тренер.

Киләләр. Ләкин өч айдан соң. Тренер чыннан да Алинәне төркеменнән куа. «Миңа спорт белән шөгыльләнүче кешенең мөстәкыйль булуы кирәк. Алинә исә безнең тренировкалар системасын аңлап җиткерми иде. Беркем беркемне мәҗбүр итми, телисең икән – эшлә», – дип искә ала тренер бу турыда. Бәла үзе генә йөрми, диләр: ярыш вакытында Алинәнең үкчә сөяге сына. Кулы да гипслы. Газаплы ике атна уза. Уйлашалар да Мәскәүдән Ижауга кайтырга карар кылалар. Чәчәкләр тотып, Тутберидзе янына саубуллашырга керәләр. «Бәлки яңадан башлап карарбыз», – ди тренер, кинәт кенә фикерен үзгәртеп. Шушы мизгел тагын күпме ярышларның таблоларын үзгәртәчәк әле!

Бозда – яңа йолдыз!

Фигуралы шуу күгендәге яңа йолдызның исеме торган саен ешрак ишетелә. 2016 елда юниорлар арасындагы Дөнья чемпионатында алтын медаль алу, Гран-при финалында җиңү, 2017 елда зурлар чемпионатларында катнашып, Япониядә Гран-при отулар...

2017 елда Россия чемпионатында алтын медаль яулап, Алинә Көньяк Кореядә узачак Кышкы олимпиадада катнашу хокукы алды. Менә кайчан аккошка әйләнде ул!

«Черный лебедь» һәм «Дон Кихот» программалары, күз тимәсен, уңыш китерә аңа. Даниил Глейхенгауз куйган «Черный лебедь» шул исемдәге фильмнан булса да, Алинә аны үзгә интерпретациядә башкара. Бу дөньяга аклык белән килгән кош баласы кырыс чынбарлыкка ярашырга мәҗбүр була. Алинәнең әлеге чыгышы зур тормышка метафора булып яңгырый – шушы 15 яшьлек кыз бала бөтен дөнья карап торганда, боз өстенә чыгып, бар кешегә дә аңлаешлы телдә өлкәннәргә «дәшә»: аккошларны ак килеш саклагыз!

Әти-әни, әби фатихасы

«Ярышлар алдыннан якыннарым миңа шалтыратмаса ярар иде, дип телим», – ди Алинә бер әңгәмәсендә. Алар болай да төн буена йокламый бит инде: Алинәгә уңышлар телиләр, догада торалар. Шулай булгач, нигә шалтыратып йөдәтергә, тынгысызлыкны йоктырырга? Әнә бит, ярышларның берсендә әнисе янында утыручы бер ханым: «Сез Алинә Заһитованың әнисеме әллә?» – дип кызыксынган. «Каян беләсез?» – дип сорагач, «Кызыгыз белән бергә сикерәсез бит», – диган.

Бүген Алинә Дилә әбисе белән Мәскәүдә яши. Бозга чыккач, әбисенең күрсәтмәләрен дә төгәл үтәп бара. Әти-әнисе һәм сеңлесе Сабина Ижауда калганнар. Сабина да фигуралы шуу белән шөгыльләнә.

Туган шәһәрен сагына Алинә. Яшьтәшләренең күбесе, әнә, 19-20 яшькә кадәр әти-әни канаты астында иркәләнәчәк. Нишләмәк кирәк, җиңү тәмен татыйм дисәң... Сагынуларын басар өчендерме, бер мәче белән ике шиншилла асрый башлаган Алинәбез.

Туган яклардан сәлам!

Без Алинәнең тамырлары Актаныштан икәнен дә беләбез. Әтисе – Татар Әҗбие авылыннан. Безнең күрше авыл булган ул. 1970 елларда Кама су басу зонасында калып, зур-зур авыллар күчеп китәргә, таралырга, онытылырга мәҗбүр ителгән. Хәзер ул урыннарда иксезчиксез болыннар, күлләр җәйрәп ята. Алинә бозга чыккан саен әнә шул Кама тугайларындагы аккошлар төшә торган күлләр искә төшә... Күргән саен, бөтен Россиягә сибелеп яшәүче меңнәрчә якташларың уңышлар теләп, үзләренең йөрәк җылысын сиңа юллыйдыр, Алинә!


PRESSA.RU

Кем соң ул Шиһаб хәзрәт? Ошбу сорау киләчәк буыннар өчен дә гаять мөһим икәнен Тукай сизгән:

«Тулган ай күк балкып чыккан... / Мәгърифәткә әүвәл башлап адым салган, / Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт...» – дип, 1913 елда – нибары 27 ел яшәп, фани дөнья белән хушлашыр алдыннан! – аңа үз мөнәсәбәтен белдерергә ашыккан. «Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм, / Шәрәфәтләп, туган көнне бу мөхтәрәм; / Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне / Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм!» – дип, аңа мәңгелек дан җырлаган.

«Өе янды Гөлбикәнең, / Иле янды Гөлбикәнең, / Көл икәнен онытса да / Онытмады гөл икәнен». Шәриктәшем Рәшит Әхмәтҗановның дүртьюллыгы телемдә ничә көннәр ник тибрәнә, дисәм... XIX йөзнең мәшһүр галиме, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») исемле тарихы хезмәте илә тәэсирләнүдән туган уйлар икән. Үз халкының, ата-бабаларының тарихы белән кызыксынмаган, йола, гореф-гадәтләрен санламаган адәм маңкортка әйләнсә, гаҗәпме?! Ике йөз ел элек яшәгән галим-голәмә, әйтик, Шиһабетдин Мәрҗани тәгаен белгән моны.

Олуг галимебез хакында без ниләр беләбез соң? Татарның мәшһүр углы Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең тууына һиҗри ел хисабы белән 100 ел тулу уңаеннан, 1915 елда Казанда бай эчтәлекле «Мәрҗани» мәҗмугасы дөнья күрә. Дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог, репрессия корбаны Шәһәр Шәрәф (1877–1938) гасыр башында Казанда бастырган шул җыентыкны тарихчы галимнәр Раиф Мәрданов, Рамил Миңнуллин, Сөләйман Рәхимов гарәп имлясыннан хәзерге әдәби телгә күчереп, «Рухият» нәшриятында 1998 елда нәшер итә. «Шиһабетдин Мәрҗани» җыентыгы – затлы җәүһәрләрнең берсе.





Роза КАМАЛЕТДИНОВА

«МӘГЪРИФӘТКӘ АДЫМ САЛГАН»

«...Сукмый тәрбия итәргә тырышыгыз...»

Шиһаб хәзрәтнең ата-бабалары укымышлы, заманының бөек галимнәре булган. Котдус атлы бабалары Казаннан утыз чакрым ераклыктагы Мәрҗән авылы урынына килеп утырган һәм авылга нигез салган. «Мәрҗани»ләр булып танылган бу нәсел-нәсәптән чыккан имамнар, галимнәр егермеләп авылда имам булып торган. Шиһабетдиннең атасы имам һәм мөдәррис Баһаветдин Бохарада белем ала. Әүвәл Ябынчы, аннан Ташкичү авылларында кырык ел хезмәт итә. Күркәм холыклы Бибихөбәйбә – Сембер ягы имамнары кызы – улына бишенче яшь киткәч, бала тапканда үлә. «Бервакыт су янында мәче баласы белән уйнап йөри идем. Әнкәң чакыра диеп алып кайттылар. Моңсу күзләреннән яшьләрен агызып: «Әй балам! Миннән соң анаң кем булыр? Кемгә Әнкәй дип әйтерсең? Өс-башыңны кем карар? Кем тәрбия кылыр?» – диюен, бер шәкертнең анам җеназасы артыннан үземне күтәреп барганын хәтерлим», – дип, әнисеннән калган догалы бер кәгазьне саклавын яза. Хатыны вафат булгач, Баһаветдин хәзрәт балдызы Хәбибәне ала. Яшь әни күп бала таба. Шиһаб иң олы бала булганлыктан, йорттагы күп эшләр, сабыйларны карау аның өстенә төшә. Әле үзе дә бала гына Шиһаб белән үги ана арасында кайчак каршылык чыгып, атасы арага керә, олы малаен җәзага тарта. Еллар узгач, мәдрәсәсендә укучы шәкертләргә Мәрҗани: «Балаларыгыз булса, сукмый, кыйнамый, яхшы тәрбия итәргә тырышыгыз. Суккан вакытта да башка, җилкәгә сугудан сакланыгыз. Башка сугу мигә зарар бирә, хәтер көчен, зиһенне киметә. Безнең әткәмез яшь вакытында минем башка суккалый иде. Шуңа бераз зарарландым. Хәтерем кимеде», – дип сөйли торган булган.

Әүвәл атасыннан сабак алган малай мәдрәсәдә укытыла торган фәннәрдән генә канәгать калса, ихтимал, шул вакыт меллалары кебек, чикләнгән фикерле булып үсәр иде. Ул бабасы, атасы китапханәсендәге гарәпчә барча китапларны аңларга, укырга тырыша. Гыйлемгә хирыс булганга, ишеткән-күргәннәрен теркәп барырга да иренми. Балачактан ук уйланучан, белгәнен дикъкать белән фикерләп зиһен сандыгына сала торган гадәте 17 яшендә үк атасы Баһаветдин мәдрәсәсендә шәкертләрне укытырга юл ача. «Хәвефле эшләрдән дә куркып тормый. Сабан туйларына барып көрәшеп йөрүе дә үзен көчлерәк итеп күрсәтү өчен иде, ахрысы. Егылган, зәгыйфь бәндәләр белән ул беркайчан да көрәшми, ә бәлки егучы баһадирлар, таза ирләр белән көрәшүне, өстенлекне сөя. Аны «Көрәшче Шиһаби» дип таныйлар иде», – дип яза энесе Садретдин хәзрәт. Шуклык-шаянлык та ерак йөрмәгән аңардан. Бервакыт битенә кәгазь битлек куеп, кичкырын урамга чыккан бу. Бер карчык бәләк тотып елгага кер чайкарга төшеп бара икән. «Мине өрәк дип белеп, башыма шундый итеп кундырды, күземнән утлар чәчрәде. Башым ярылды дип уйлаган идем, әле дә ярылмаган икән», – дип, бу хәл исенә төшкән саен, көлеп сөйләгәне дә замандашлары хәтерендә сакланган булган.

«...Галим булуны теләгән идем...»

Әткәләре Бохарада укыган елларын сагынып искә төшергәндә, Шиһабетдин аның сөйләгәннәрен дәфтәренә язып бара. Бабасыннан борынгы заман хәлләхвәлләрен сораштыра. Үткәннәрне белергә, тикшерергә һәвәс малай иске кабер ташларындагы язуларны укып йөри. Әнкәсе каберенә таш язып куя.

Авылда үзен зур галимнәр кебек тота. Сүзен уйлап сөйли. Ата-бабасы берәр гыйльми мәсьәлә хакында сүз кузгатса, колагын торгызып тыңлый, мәгълүмат алырга тырыша. Әтисенең Бохара галимнәрен мактап сөйләве күңелен җилкендерә. Үзе дә гыйлем мәркәзенә ашкына. Бохара–Казан арасында кәрваннар йөреп тора. Әтисеннән укырга китәргә рөхсәт сорый торгач, 1838 елның маенда Мәңгәрнең Мөхтәр атлы сәүдәгәре белән ул да сәфәр чыга.

> *Замандашлары аны тәвәккәл, йөрәкле, максатчан һәм үҗәт итеп хәтерләгән.*

«Атабыз, пар ат җигеп, Мәңгәргә кадәр озатты. Пар атның яндагысы – яшь ат, куркып, холыксызланып, җәфалап бетерде. Мөхтәр агайның эшләре тәмам булмаганга, Мәңгәрдә берәр көн торырга туры килде. Атабыз, мине калдырып, Ташкичүгә кайтып китәргә уйлады. Читкә чыгып йөрмәгәнгә, атамнан аерылу, аны Ташкичүгә озатып җибәрү бик читен булды. Күңелем тулып, еларга теләсәм дә, тартындым. Елавымны атамнан яшерер өчен: «Бу яшь ат илә ничек кайтырсыз, юлда зарар ирештермәсә ярар иде», – дидем, – күңелем бик йомшады. Мәңгәр мәчетенә кереп, елый-елый ике рәкәгать намаз укып, дога кылдым».

Мәрҗанинең атасы урта хәлле мулла булганга, улына биргән акчасы Бохарада яшәү өчен бүлмә – хөҗрә сатып алып яшәргә җитәрлек булмый. Шунлыктан, юлда ук ул киләчәген уйларга мәҗбүр: Троицк каласына барып җиткәч, кулындагы акчасына кечкенә сандык, бизәкле савыт, тартмалар алып, кайсыларын – юлда, кайсын барып җиткәч сата. Бохарада үз акчасына хөҗрә алып яши башлый. Гыйлемгә чын ихласлы, гомернең кадерен белә торган галим юлда, хәтта дөяләр өстендә барганда да китапларын кулыннан төшерми, Коръән аятьләрен ятлый. Сәфәрдә очраган гыйлемле затларга тарихка кагылышлы сораулар бирә, җаваплар ала. Белем алу гына ләззәт, ә төрле кеше белән юк-бар сөйләшеп вакыт уздыру гомерне әрәм итү дип саный.

Юрауларга да колак салган, күрәсең... «Бохарада вакытымда һөдһөд кошы минем өстемнән очып үткәндә, янымдагы берәү: «Һөдһөд күләгәсе төшкән кеше падишаһ була дип әйтәләр, син нинди дәрәҗәгә ирешерсең икән?» – дип әйтте. Шул сүзгә шат булып, галим булуны теләгән идем», – дип яза ул истәлекләрендә.

Бохарада биш ел торганнан соң, Төркестандагы икенче гыйлем мәркәзе – Сәмәрканд каласына юл тота.

Шиһабетдин Мәрҗани. Канафи Нәфыйков эше.

PRESSA.RU

Атаклы «Ширдар» мәдрәсәсенә урнаша. Анда галим-казый Әбү Сәгыйд хәзрәтләренә юлыга. Казыйның угыл-кызларының балаларын укыта. Мәрҗанинең гыйлемгә ихласлыгын, сәләтен күреп, казый үзенең бай китапханәсеннән кыйммәтле китапларын аңа укырга бирә. «Миңа аң биргән, фикеремне төзәткән ул китаплар юл күрсәтүчеләрем булды. Гомеремнең иң рәхәт һәм ләззәтле сәгатьләре – тарих белән шөгыльләнүем, ә тарих китапларын укый башлавыма баш сәбәп – инсафлы-әдәпле, тугры фикерле, мәгълүматлы ошбу зат! Намаз укыганда һәрвакыт мине имам итә иде. Бервакыт Сәмәркәнд хакиме хозурында мине артык мактап: «Бу егет гыйлем тугрысында зур китаплар язган борынгы галимнәрдән дә өстен», – дип сөйләде».

Ике елдан ул кабат Бохарага кайта. Иң бай «Мир Гарәб – Әмир Гарәб» мәдрәсәсендә бүлмә сатып ала. Бер ел соңрак энесе Садретдин дә аның янына килеп, бергә яши башлыйлар. «Күрәшче Шиһаби»ның тырышлыгы, вакыт һәм гыйлем кадерен белүе, кич ятканда хәтеренә төшкән берәр хәл-вакыйганы язып кую өчен янына кәгазь-каләм, шәм куеп ятуы, авылда чакта ук бер-ике рисалә – китапчык язуы, ә төрек-татар тарихына Бохарада чакта игътибар бирә башлавы энесе истәлекләреннән дә мәгълүм.

Нигъмәтнең кадерен белә, икътисадка игътибары зур.

«...Киләчәккә бәя бирүчеләр булыр...»

Унбер елдан соң ул туган җиренә – Ташкичүгә кайта. Бу вакытта Казанның Беренче мәчетенең имамы хаҗ сәфәренә китеп, беренче мәхәллә имамсыз калган була. Атаклы татар бае Ибраһим Юнысов (Озын Ибрай) үз мәхәлләсенә галим затны имам итеп сайларга ниятләп, Бохарадан кайтучылар хакында сораштыра башлый. Ибраһим бай мәхәлләсенә зур галим бер мөдәррис кирәклеген белгәч, Мөхтәр бине Мөхәррәм, юлда кайтканда, үзләренә имам булып намаз укыткан Мәрҗанине мактап: «Ошбу дамелла Шиһабетдин... Казанның иң мәшһүр зур мөдәррисе булган хәзрәтне дә ун ел укытырлык куәте бар», – дип сөйләгән.

Казан имамнары алдында имтихан тотып, атасыннан рөхсәт алып, Мәрҗани 1849 елның ноябрендә имам булып беренче мәртәбә җомга намазын укыта. Дүрт айдан Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы, мөдәррис булырак, Указ алып, эшкә тотына.

Берничә елдан соң әлеге мәдрәсә нык кына тузып, шәкертләр торыр өчен яраксыз хәлгә килә. Мәрҗани мәхәлләсендәге байлар, дуслары, акча җыешып, зур таш мәдрәсә – хәзерге вакытта Мәрҗани мәдрәсәсе дип танылган Мәдрәсәи Галияне салырга керешә. 1881 елның 25 сентябрендә анда дәресләр башлана.

1880 елда Мәрҗани хәзрәтләре Казан губернаторына гариза биреп, хаҗ сәфәренә рөхсәт алган, васыятьнамә язган: «...кайчан мин фәкыйрьгә әҗәл ирешсә, үз хезмәтем илә тапкан милкем, акчаларымны... ике угълым, бер кызыма: Мөхәммәд, Мәхмүд вә Хаувага, җәмәгатем Бибифатыймага, тагын бер кызыма вакыф иттем... китапларым... беркайчан да сатылмасын...»

Мәрҗани тарихны ярата. Казан университетының «Археологик истәлекләр җәмгыяте» әгъзасы була. Татар халкын русча өйрәтеп, үз телләрендә фәнни мәгълүматны күбәйтү, мәгърифәт тарату, хәтта милли әдәбиятны арттыруны күздә тотып, немец Василий Радлов Казанда русча өйрәтүче мәктәп – школа ача, халык арасында абруйлы булсын өчен, мөгаллимнәрне дә татарлардан куя. Дәрәҗәле Шиһаб хәзрәткә дини мөгаллим вазыйфаларын йөкли. Казан мәдрәсәләренә русча укыту көчләп тагылганга, муллалар имза җыеп: «Безнең халык, аеруча укучы шәкертләр, болай да фәкыйрьләр. Без акча алмыйча, Алла ризалыгы өчен генә укытабыз. Шунлыктан, русча уку мәҗбүри булып, мөгаллимнәрнең вазыйфалары да безнең фәкыйрь халык өстенә йөкләнү хакындагы әмерләрне җиренә җиткерүдән без гаҗиз. Башлыкларның гозеребезне кабул итүләрен үтенәбез», – дип хат язалар. Зур низаглы вакыйгалардан соң озак тормый, Казанда русча укытучы мөгаллимнәр әзерләү өчен дарелмөгаллимин – учительская школа ачыла. Шул уку йортына дин мөгаллиме итеп Мәрҗани хәзрәтләре билгеләнә. «Бу мәктәпкә дин мөгаллиме булып керергә бер дә хәтеремә килмәгән иде. Фәкать Радлов кабат мөрәҗәгать иткәч, губернатор махсус үтенгәч, бу урынның бик әһәмиятле булуын, әгәр бу урын башта ук гыйлем ияләре кулында булмаса, соңыннан бөтенләй Ислам гыйлемнәреннән хәбәрсез, надан кешеләр кулында калуын, анда укучы шәкертләрнең Исламияттән бөтенләй хәбәрсез калу ихтималын уйладым. Шәригатьнең тормышка, гыйлем вә фәннәргә карашын, һәртөрле гыйлемнәргә мөселманнарның гаять зур хезмәт иткәннәрен күрсәтергә тиеш күреп, шул урынга риза булырга уйладым», – ди ул.

«Дөньядагы төрле телләрне белүгә, мәгърифәткә Ислам дине каршы килми. Исламны яхшы аңлап, инану урнашып җитсә, русча уку гына зыян итмәс. Мөселманча белмичә, русча укып калу гына ярый торган эш түгел», – дип шәкертләренә дә сөйли.

Мәрҗани хәзрәтләрен замандашлары горур, аз сүзле, җитди, гаять тырыш, ныклы белемле, Аллага таянуы бик куәтле, мәһабәт зат итеп хәтерли. Тотынган эшен, мең төрле киртәләр үтеп булса да, ахырына илтеп җиткерә. «Эшләгән эшләрем мөселманнар өчен файдалы вә чын хакыйкатьләрдер. Бүген бәяләүче булмаса, киләчәктә бәя бирүчеләр булыр», дип ышана. Гомерендә, барлыгы 8-9 мең бит чамасы, утызлап төрле китап һәм мәкаләләр яза. «Китапларда нигъмәт кадерен белгән кеше йортында бәрәкәт була, байлык арта дип язылган, мин каткан ипи кисәген дә әрәм итмәскә тырышам. Аш, чәй янында икмәк, күмәч сыныклары калса, миңа ашарга ярар әле, асраулар аны чыгарып кына ташлый, дип алып куям. Шуңа күрә әһәмиятле кәсеп вә һөнәрем булмаса да, тормышым яхшы», – ди. Аның юмарт, киң күңелле булуы, зәкятен шәкертләргә мул итеп бирүе, аз бирүне яратмавы да билгеле.

МАТУРЛЫК ӨЙДӘ КИРӘК



Иләһи ният кылдым

Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

Бүген хатын-кыз өйдә генә утыра алмый. Ул көне-төне эштә – карьера баскычыннан күтәрелә. Хезмәт урынында хатын-кыз матур күренергә тиеш: буянырга, маникюрдан йөрергә, хушбуй сибенергә...

Бу мәсьәләгә киңрәк карарга кирәктер. Дресс-код турында гына түгел, дөньяда, шушы җәмгыятьтә хатын-кызның урыны турында сүз бара монда. Совет чорында хатын-кызга ирләр белән бертигез хокук бирелде – алар укырга, эшкә керә башлады, эшендә үсте. Ир-ат белән бер дәрәҗәдә дип санасак та, элеккеге тормышта гүзәл затлар хатын-кыз өлешенә генә тигән авырлыкны күрсә, хәзер аларга ир-атлар күтәрергә тиеш булган авырлыклар да өстәлде. Менә шуңа күрә дә хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урынына бүген башкача карарга, аны үзенең асылына кайтарырга кирәк. Ә хатын-кызның асыл урыны – яхшы әни, әйбәт хатын булу. Шушыннан да мөһимрәк бурычы юк аның.

Игътибар итсәгез, дөньяның бозылуы да хатын-кыз өйне калдырып, эшкә чыккач башланды. Сәбәбе аңлашыла инде: әни эштә булгач, балага тәрбия юк – ул караусыз, көне буе урамда уйнап йөри яки телевизор яныннан китми. Иргә дә тәрбия юк. Аны елмаеп каршы алырга, озатып калырга, иң матур киемнәрен киеп, ирен хасиятләп торырга хатынның хәзер вакыты да, көче дә җитми. Эштән ул һәрвакыт арып кайта – башкаларны көйләр хәлдә булмый.

Эшли башлагач, хатын-кыз үзе дә шактый үзгәрде, бозылды. Ул да бит хәзер мал таба, шуңа күрә: «Мин дә бит тик утырмыйм, синең кебек үк акча алып кайтам», – дип, иренә тавыш күтәрергә дә тайчынмый башлады. Иргә буйсыну бетте. Ә пәйгамбәребез (с. г. в): «Ир кешегә иң охшаганы – аңа буйсынулары», – ди. Үзенә буйсынмаган хатын-кыздан аның күңеле суына, ул инде аңа кирәк түгел... Шуңа күрә дә карьера ясыйм дип йөргән хатын-кыздан ерак торырга киңәш итәм. Ул – гаилә өчен түгел. Мөхәммәд пәйгамбәребезнең бер хәдисендә әйтелгәнчә, Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне яралткач, аның кабыргасыннан парын – анабыз Хаваны да яралта. Адәм галәйһиссәлам уянып киткәч, каршында Хаваны – хатын-кызны күрә.

– Син кем? – ди ул аңа.

– Мин синең хатының, – ди Хава.

– Син нәрсә өчен кирәк соң? – ди.

– Мин сиңа тынычлык алып килер өчен кирәк, – дип җавап бирә анабыз Хава галәйһиссәлам.

Әйе, хатын-кыз тынычлык алып килергә тиеш: ир кешенең хәятенә, гаиләсенә, дөнья тормышына. Ә моның өчен ул гаиләдә булырга тиеш.

Ярый, хатын-кыз эшләргә дә мәҗбүр булсын, ди. Ислам дине буенча, әгәр ире моңа каршы булмаса, хатын-кыз эшләргә мөмкин. Әмма бу очракта да ул үзенең хатын-кыз сыйфатларын җуймый торган эшне табарга тиеш. Хатын-кыз кирәк булган өлкәләр тормышта болай да бик күп бит: бала табу йортлары хезмәткәрләре, хатын-кыз табиблары, тәрбиячеләр, укытучылар... Хатын-кызга авырлык китергән, аның сәламәтлегенә зыян салган вазыйфалардан да баш тарту хәерлерәк.

Инде эштәге дресс-код турында. Хатын-кыз күбрәк хатын-кызлар коллективында эшләргә тырышырга тиеш. Үз ишләре янында булса, монда дресс-кодка карата таләпләр кими. Инде ирләр арасында йөрергә туры килә икән, шәригать кануннары бу очракта да барыбер өстенрәк тора. Әйтик, ирләр янында хатын-кызга хушбуй кулланырга рөхсәт ителми: хушбуй исе ирләрнең нәфесен уятырга мөмкин. Табигый төсеңне, кыяфәтеңне үзгәртә торган ачык, җете тоннарда бизәнү шулай ук тыела. (Әмма саклану йөзеннән, әйтик, иреннәр ярылмасын дип, төссез иннек сөртергә ярый.) Тырнакны да буярга ярамый. Тәһарәт алганда, тырнакларга су тияргә тиеш, димәк, тими икән, тәһарәтең дә, намазың да дөрес булмый дигән сүз. Ә тырнак буяу, беләсезме, кайдан килеп чыккан? Хатын-кыз элек тырнагын кызыл төскә күрем килгән вакытта гына буяган. Бу аның – иренә: «Миңа кагылма», – дигән билгесе булган. Алар шулай сүзсез генә аңлашканнар. Тырнактан буяу сөртелгәнен күргән иргә артык сораулар биреп торырга кирәк тә булмаган...

Маникюр ясату – табигый матурлыгыңны бетерү инде ул (әлеге дә баягы, тырнакларда ниндидер чир булса, аларны дәвалау өчен буярга туры килсә – монысы башка мәсьәлә). Аллаһы Тәгалә безнең организм өчен нәрсә кирәген-кирәкмәсен барысын да уйлаган. Тырнак суларга тиеш. Буяп, без аңа зыян салабыз. Сәламәтлекнең бер билгесе булып тора бит тырнаклар. Табиблар, аларга карап, кешегә кайчак диагноз да куярга мөмкин. Шуңа күрә буямасаң, хәерлерәк. Хәтта намаз укымасаң да.

Түрәгез сездән матурлык таләп итә икән, сорау туа: аның өчен нәрсә мөһимрәк – тышкы кыяфәтме, әллә профессионализммы? Эшеңне беләсең, җиренә җиткереп башкарасың икән, бу эш синеке булачак. Матурлыгың белән кукыраеп йөреп, кулыңнан берни килмәсә, бер тапкыр гына игътибар итәчәкләр, икенче юлы әйләнеп узачаклар.

Әйе, шәригать кануннары буенча, хатын-кыз үзенең матурлыгын күрсәтергә тиеш түгел. Нәрсә генә әйтсәләр дә, ир кеше беренче чиратта аңа коллегага түгел, ә хатын-кызга караган кебек карый. Хатын-кыз да һәрвакыт ир-атка ошарга тырыша. Алар бер коллективта эшли икән, иртәме-соңмы, арада нәзакәтле мөнәсәбәтләр туарга мөмкин. Аннан инде хыянәткә бер генә адым... Яшерен-батырын түгел, коллегалар арасында мондый хәлләр еш күзәтелә.

PRESSA.RU

Башта шигырьләре белән таныштык Миләүшәнең. Хисле, ихлас алар. Шаянлык та, фәлсәфә дә бар үзләрендә. Туган як матурлыгы, яшьлек яме, якты моң, сагынулар... Кем соң бу Миләүшә? Кайдан? Аннары үзе белән элемтәгә кердек. Башкортстанның Нуриман районы Яңа Субай мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, инглиз теле укытучысы икән Миләүшә Гыйльманова. Халык мәгарифе отличнигы, «Мәгариф» милли проектында грантлар яулаган укытучы. Берничә шигырь җыентыгы авторы. «Сөембикә» укучылары үзләре өчен яңа исем ачар.



Миләүшә ГЫЙЛЬМАНОВА

КҮКЛӘРГӘ ОЧАР ЧАГЫМ...

Югалган моң

Эзләр югалганын күргәнем бар,
Дуслар ташлавына дучармын.
Тик бирешми, башым горур тотып,
Яннарыннан әле узармын.

Атлар югалганын ишеткәлим,
Ярлар ташлавына шаһитмын.
Сабырлыгым һәрчак тотып кала –
Үзем югалырга ашыкмыйм.

Карлар эрегәнен күргәнем бар,
Күңел язларына бирешеп.
Әнкәм теле – тылсым, шуңа яшим
Мәртәбәле моңга ирешеп.

Гөлләр сула, әй, кызганам ул чак –
Гөлләр гомеренә чик бармы?
Сагышларым тартып китерделәр
Югалган моң кайтыр чакларны.

Эзләр югалганын күргәнем бар –
Дуслар ташлавына түзәрмен.
Әнкәм теле, моңы ташлап китсә,
Яши алмам, ансыз үләрмен!

Кояш тулган чиләгемә

Иңнәремә көянтәләр салып,
Кайтып киләм чишмә юлыннан.
Кояш нуры тулган чиләгемә,
Йөрәгемә җәйге моң тулган.
Кояш нуры уйный чиләкләрдә,
Тараталар сагыш-уйларымны.
Назлы җилләр тарый чәчләремне,
Чайкалдыра минем суларымны.
Бер чиләктә – бәхет-шатлыкларым,
Бер чиләктә – минем сагышларым.
Тигез күтәреп мин пар чиләкне,
Гомер буйлап атлап барышларым.
Әле кояш уйный суларымда,
Әле төшә кара күләгә.
Ни булса да, атлыйм алга таба,
Әле иртә суны түгәргә.

Җилләр

Җилләргә каршы йөгерәм,
Җилләрне кочар чагым.
Шатлыкларым эчкә сыймый,
Күкләргә очар чагым.
Шатлыкларым күктән ашкан –
Миләрем томаланган,
Рәхмәт, җилләр, коткардыгыз
Кайгылы томаннардан.
Җилләр белән өерелеп,
Биергә әзер көнем.
Тик җил белән шатлыкларым
Очып китмәсен, димен.

Изге юл

Күпме юллар үттем гомеремдә,
Кая гына язмыш илтмәде.
Тик шулай да иң кадерле юлым –
Туган якка таба киткәне.

Күпме юллар күрдем гомеремдә,
Ятып эчтем чишмә суларын.
Тик шулай да авылым чишмәсенең
Суы диеп ямансуладым.
Җырлар моңы керә колагыма,
Кай тарафка барып чыксам да.
Тик шулай да әнием җырларыдай
Моңлы җырлар юк бу дөньяда.

Күпме еллар акты гомеремдә,
Сиздермичә сырлап маңгаем.
Җырларыма моңнар өстәргә дип,
Туган йортка кайтам ел саен.

Юксындыра

Тынны куырыр эссе сахраларда
Йөргән чакта җәйге бер көнне,
Ап-ак кышның карлы бураннары
Юксындыра иде күңелне.
Күзгә көндә яфрак бураннары
Сырып алса җирнең өсләрен,
Сизми калам: язгы каендагы
Яшь бөренең искә төшкәнен.
Бу нинди хәл: гомер узган саен,
Яшь чакларны ныграк сагыну?
Бүгенгедән хата-гаеп эзләп,
Үткәннәргә генә табыну?
Элеккечә дөнья һаман көләч,
Киңрәк җәя, күрәм, колачын.
Тик көн үткән саен
гел җылырак төсле
Үткәннәрдә калган кояшым.

Таныш булыгыз: Назлыгөл Мәсәлимова. Арчаның Сеҗесеннән. Исеме дә шигырь кебек, үзе дә шигърият дөньясында нәфис гөл сыман: беркемне кабатламый, беркемгә охшамаган... Яңа. Креатив. Динамикалы. КФУның Югары журналистика мәктәбендә икенче курста укый. Мәктәп елларында ук Арча районы укучылары арасында Г. Тукай, Г. Ахунов премияләре лауреаты исемен яулаган кыз университетта укыганда С. Сөләйманова исемендәге әдәби стипендиягә лаек була. Шигырь сөюче яшьләр Назлыгөлне аеруча яратып кабул итә.



Назлыгөл
МӘСӘЛИМОВА

КИТЕП БАРАМ. ХУШ!

* * *

Икәү генә калдык көннең азагында,
Инде тиздән җитә яңа көн.
Ышаналмый карыйм күзләреңә –
Ялганмы соң бу төн, әллә өн?
Күзләреңә карыйм,
Син каршымда гына.
Кулым сузсам әгәр кагылып,
Битләреңә, кулларыңа, иреннәргә,
Тигән булсам әгәр сарылып...
Алданам дип, хәер, әйтә алмам,
Мин ялгыштым, син дә ялгыштың.
Кичерергә өмет өзелдеме?
Яратуга, хискә карыштың.
Икәү генә калдык. Карадың син
Гүя соңгы тапкыр күзләргә.
Җылыңны да тоя алмый калдым,
Кочакладың, этеп китеп бардың...
Ышанмадым әйткән сүзләргә.
Икәү генә калдык,
Икәү генә...
Йотлыгыплар карый күзләрем,
Секунд, минут, еллар узса әгәр,
Хисләр дулкынына түзә алмый,
Мин, ахрысы, инде сизмәмен.
Икәү генә калдык, икәү генә...
Караңгылык. Өстәл. Ике шәм...
Тынлык боза бары сулышларың,
Иреннәрдә исә тозлы тәм.
Икәү генә калдык. Тәрәзәдән
Салкын җилләр исә, сизмим, нибары
Сиңа карап каткан күзләр,
Туңсам, өшеп бетсәм әгәр,
Тоймамын аны.
Икәү генә калдык, бары икәү генә...
Икәү генә калдык нибары...
Хисләремне тыймый үкси-үкси,
Кочагыңа атылып еладым мин.
Мөһим түгел чыны-ялганы.
Икәү бергә калдык нибары...

* * *

Бу дөньяда хәлдән талган чакта
Алга барыр өчен көчең калмый.
Син дус дигән кеше дошман була,
Яман сүзләр әйтә, бик күп алдый.
Ышанычың бетә бөтен кешелеккә,
Йөрәк тула, күңелең ярсына,
Тынычлана алмый,
ярканаттай булып
Җирдән күккә таба омтыла.
Кешелеккә бетте ышанычың,
Яраланды нечкә күңелең.
Хыялларың чәлпәрәмә килде,
Ярсуланып типте йөрәгең.
Башны аска идең, җиңелдеңме?
Тезең чүктең читләр каршында.
Әллә нишләдең бит! Күтәрел бер,
Әйт сүзеңне! Әйтче барсын да.
Тик... Җиңелдең, йөрәк моңсуланды,
Теләкләрең сулды, корыштың,
Сары төскә керде алсу йөзең.
Тормышыңда – хата. Ялгыштың.
Менә алырсыңмы югарыга?
Тормыш калкулыгы бик биек.
Әллә инде җиңелеп яшәр җаның,
һәр көн саен тилмереп, көеп?!
Күтәр башың, күтәр күзләреңне,
Тезең чүкмә читләр каршында.
Ялгышкансың? Төзәт ялгышыңны,
Җиңеп була җирдә барсын да.

* * *

Электричка. Метро. Салкын көндә
Мин еракка синнән китеп барам.
Салкын караш. Рәнҗетүләр.
Үпкәләүләр.
Хатирәләр хәзер
Тирән яра.
Сау бул диеп пышылдыйм да
Соңгы тапкыр,
Яшьләремне сөртеп,
Карап калам.
Мин еракка синнән китеп барам.
Электричка. Метро. Эшелоннар.
Тәрәзәдән карыйм: йортлар, басу-
кырлар кала,
Бертуктамый аккан күз яшьләре
Чынбарлыкны каплый, Тама-тама...
Мин еракка синнән китеп барам.
Соңгы тапкыр пышылдадым сиңа.
Сау бул...
Юк, хуш! Туры килмәс
башка очрашырга.
Тик нигәдер йөрәк үкси-үкси,
Кулларыңда синең изелеп
Кала...
Мин еракка синнән китеп барам.
Хуш мәңгегә!
Хуш!
Сау бул, мәхәббәтем...
Сау бул, Ярам...

PRESSA.RU

«ТАТАР ҖЫРЫ-2017»: КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Гадәттәгечә, кием элгеченнән башлыйк әле. Үземне балга эләккән кебек хис итәм. Макияжлы, прическалы ханымнар һәм туташлар... Ул күлмәкләр... ыспай егетләр... Мин түгел, күзге үзе соклана иде бугай. «Татар җыры» егетләрнең кызларга каш сикертеп кала торган мәйданына әйләнгән түгелме соң?

Җыр сәнгатендә саннан – сыйфатка, диләр иде. Җыр бәйгеләре күп булсын, дигәннәр иде. Халык шагыйре Разил Вәлиев әйткәнчә, җыр ул – байлык, ә байлык күп булмый.

Соңгы елларда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та татар җыр сәнгатенә аерым игътибар бирә. Аның фатихасы белән «Үзгәреш җиле» фестивале барлыкка килде. «Татар җыры»ның да концептуаль үзгәрешенә бу игътибар йогынты ясамый калмагандыр. Быелгы «Татар җыры»на Рөстәм Миңнеханов хатыны Гөлсинә ханым белән килгән иде. Кайбер мизгелләрне – күрәсең, күңеленә аеруча хуш килгәннәрен дә, Инстаграмдагы сәхифәсенә дә элеп барды.

Үзгәреш дигәннән. 18 нче тапкырына «Татар җыры» чыннан да сыйфат үзгәреше кичереп, татар эстрада сәнгатенең иң-иң дигән җырчыларын бер сәхнәгә җыеп күрсәтә алды. «Кабатланмас тавыш» иясе Филүс Каһиров, «Үзенчәлекле моң» иясе Ришат Төхвәтуллин фестивальне югары дәрәҗәгә күтәрде. Аларны тамашачы да башкача кабул итте: бар тирәсендә йөреп торучылар тынып калды хәтта. Фестиваль тамашадан эстетик зәвык бирә торган концертка әйләнде.

Быел «Татар җыры» лауреатларны 24 номинациядә бүләкләде. «Алтын барс»лы һәр җырчы тамашачы күңелендә үзенчәлекле бер ягы белән истә калды. Мәсәлән, «Яңа исем» номинациясендә «Алтын барс» алган Гүзәл Әхмәдиева тавышы белән дә, нәфислеге белән дә сокландырды. «Үзенчәлекле проект» номинациясе җиңүчесе Илсөя Бәдретдинова өчен бу – икенче «Алтын барс», беренчесен 2008 елда алган булган. Ул «Торып бас» (Илфак Шиһапов сүзләре һәм көе) җырын башкарганда, экранда спорт ярышларыннан күренешләр чыгып баруы мантыйкка ярашлы булса да, безнең халык бу җырны башкачарак эчтәлектә кабул итә иде. Режиссерның стереотипларны җимерүе булды, күрәсең.

«Иң яхшы дуэт» – Салават Миңнеханов белән Гүзәлем һәм «Иң яхшы танцеваль проект» җиңүчесе Ландыш Нигъмәтҗанова – костюмнары белән, «Елның иң популяр җыры»н башкаручы Илназ Баһ чәчәк урынына пакетка салып биргән күчтәнәч белән истә калды. Эстраданың йөзек кашы Зәйнәп Фәрхетдинова «ТатМузТв» телеканалының махсус бүләген алды. Аңа бүләкне «Барс Медиа» Татар Медиа Группасы рәисе Камил Гәрәев тапшырды. «TATAR RADIOSI»ның махсус бүләге»н алган Айдар Галимов өчен бу «Алтын барс» – унисигезенчесе. «Бүләк тапшыручылар рәтендә булмыйча, әле тагын җырлыйсы килә», – диде ул, Салават Фәтхетдиновның быел җырламыйча, сәхнәгә бүләк тапшырырга гына чыгуына ишарә итеп. Салават исә «Татар җыры»нда катнашучы яшь җырчыларны бер-ике генә җөмлә белән бәяләде. «Алар җырлый торган җырларны мин мәңге җырлый алмыйм. Катлаулырак алар. Халыкчанлык җитми», – диде ул.

Узган ел фестивальне Радик Юльякшин һәм Гүзәл Уразова «Гүзәлем-Матурым» җыры белән тәмамлаган иде, быел алар нәкъ шушы хит белән башлап җибәрде. Радик «Иң популяр җырчы», Гүзәл – хатын-кыз җырчылар арасында «Иң халыкчан җырчы» булып танылды. Фестивальне исә «Иң яхшы эстрада җыр театры» номинациясе җиңүчесе Фирдүс Тямаев тәгәлләде.

Быел «Татар җыры»н Гөлназ Сәфәрова, Айваз Садыйров, Искәндәр Хәйруллиннар алып барды.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА



















Фото: Марат Хафизов, Эльмир Габидуллин

PRESSA.RU



Ләлә
САБИРОВА

БӘХЕТСЕЗ ИТӘСЕҢ БИТ...

(Хикәя)

Алдагы парта артында утырган җете зәңгәр күзле үсмергә карады да катты Ләйсирә. Класста бүтән берәү дә юк диярсең! Хәер, калганнарга карашын йөгертеп үткән иде инде, монысына җиткәч, төртелде. Йа Хода, охшаса да охшар икән!

...Идрис өйләнергә йөргәндә Ләйсирә шушы малай яшендә булгандыр, мөгаен. Әй, үрсәләнгән иде кызый, мендәренә капланып та үкседе, бакча артларындагы болынга төшеп тә елады. Бик ярата иде шул ул Идрисне! Чынлыкта егет аңа баласытып кына караган булган инде – Ләйсирә моны еллар узгач кына аңлады. Ә ул чакта урамда очраганда: «Нихәл, сеңел? Үсеп буламы?» – дип чәчләрен туздырып киткәндә дә, клубка чыккач, биергә чакырганда да әй рәхәт була торган иде. Колхоз басуына урып салынган борчак саламын әйләндерергә чыккан көнне дә онытасы юк. Баскан урыннары Идрис белән янәшә туры килде. Үзенекен эшләп бетерә дә: «Беләкләреӊ бик сыек, сеңел, яле, булышыйм әле үзеңә», – дип, Ләйсирәнекенә тотына. Аның беләкләре, дөрестән дә, егәрле, колачы киң. Их, эрепләр китәсе иде шуның кочагына кереп...

Булмады. Ләйсирә үсеп өлгерә алмады – Идрис өйләнеп куйды. Туй көнендә кыз ул яшәгән югары очны елый-елый өч тапкыр әйләнде.

Мәктәпне бетерүгә, Ләйсирә калага китеп барды – педагогика институтына укырга керде. Ял көннәренә кайтканда очраткалады Идрисне. Берсендә каршысына үзе елмаеп килде: «Карале, сеңел, хәйран чибәр кыз булгансың, нишләп иртәрәк күрмәдем икән мин сине?» – дигән булды. Ләйсирәнең беркатлы чаклары узган, шулай да әй үртәлгән иде шул сүзләргә, тәмам ышана язган иде.

Гомер уза торды, яратканын тәки очрата алмады кыз. Укып бетергәч, юллама белән ерак районга китеп барды. Артыннан ялынып йөрүчеләр дә булды үзе, тик берсенә дә күңеле ятмады шул. Инде утызның теге ягына чыкканына да шактый. Шулай карт кыз булып олыгаерга язгандыр, күрәсең...

Быел менә кабат туган авылына кайтып төште. Дөресрәге, әнисе дәшеп кайтарды. «Син дә ялгыз, мин дә монда берүзем тилмерәм», – диде. Ләйсирә тәвәккәлләде. Өстәвенә, мәктәпләренә нәкъ менә математика укытучысы кирәк булып чыкты.

Беренче көнне үк үсмер чагыма әйләнеп кайтырмын дип уйлады микән ул? Шушы зәңгәр күзле малай бөтен күңел дәрьясын актарды да ташлады. Нинди икән ул Идрис абыйсы хәзер?

Ата-аналар җыелышы буласы көн иде, мәктәп ишегалдында аны бер ир куып тотты. «Нихәл, сеңел, туган якларыңа кайтырга булдыңмыни?» – диде. Ләйсирәнең аягы камырга әйләнгән кук булды, артына әйләнеп карарга курыкты. Шундый да таныш тавыш! Тик... тавышы аныкы булса да, үзе бөтән булып чыкты. Һәрхәлдә, үзен күргәч, Ләйсирә аны танымады. Дөресрәге, танырга теләмәде. Юк, юк, теге чактагы Идрис түгел иде бу! Юанаеп киткән, буе да чүккән димме? Йөзе таушалган, әллә җыерчык та баскан инде... Җете зәңгәр күзләре генә үзенеке булып калган. Кырыгын гына узган ир бит югыйсә...

Ләйсирәнең күңелен моң басты, җаны өшегәндәй тоелды. Бер-ике сүз алышты да, тиз-тиз атлап, үз юлына китте.

Шуннан бирле Идрис белән очрашуны көтми инде ул. Дәресен аның зәңгәр күзле малаена карап сөйли. Класстагылар, аптырашып, чышын-пышын килә башлагач кына айнып киткәндәй була.

Беркөнне ул Ильясны такта янына чыгарды. Авыравыр сораулар биреп йөдәтте. Кайсын белде малай, кайсын – юк. Журналга зур итеп «өчле» куйды. Моны ишеткәч, класс «аһ» итте. Ильяс янәшәсендә утырган кыз чәчрәп үк чыкты:

– Апа, нишләвегез бу?! – диде. – Сез бит аңа сорауларны әле үтелмәгән темадан бирдегез! Ильяс отличник ул, беләсегез килсә!

Ильяс аның җиңеннән тартты – вакланма, янәсе. Ләйсирә кызарынып китте: кыюланган бу авыл балалары, укытучы белән әнә ничек сөйләшәләр! Шулай да үзен кулга алырга тырышты:

– Син алай әтәчләнмә, акыллым! – диде. – Отличник булганга бирдем дә инде мин аңа шундый сорауларны. Киләчәк өчен стимул булсын, дидем.

Икенче, өченче көнне дә шул хәл кабатланды. Класс гөж итеп ала да тына. Ләйсирәнең генә күңеле тынмый. Ни өчен шулай кылануын үзе дә аңламый ул. Идриснең аның каршында бер гаебе юклыгын да белә. Ильясны болай җәфаларга тиеш түгеллеген дә аңлый. Кемгә дип кизәнүе соң бу?

Беркөнне Ильясның үзенең сабыры төкәнде, иптәшләренең класстан чыгып китүен генә көтте дә укытучы янына үзе килде.

– Сез, мөгаен, кем өчендер миннән үч аласыз! – диде, Ләйсирәгә нәфрәтләнеп карап. – Сорашып карадым, ни өчен икәнен эти дә, әни дә белми. Әллә әйтергә теләмиләрме? – Ул аңа сөзәргә килгән үгез шикелле карады.

Ләйсирә тыенкы гына елмайды. Малайдан читкәрәк китеп басты. Ул нәкъ әтисенең яшь вакытындагы шикелле – озын буйлы, таза беләкле. Хәзерге үсмерләрнең башында ни барын белмәссең...

– Математикага сәләтең барлыгын белгәнгә шулай эшлим... Мондый җавап канәгатьләндерәме? Киләчәгеңне уйласаң, башкалар дәрәҗәсендә генә укып барырга тиеш түгел син!

Ильяс уйланып алгандай булды. Тик берни дә аңламады.

– Теләсәң, мин сиңа өстәмә дәрес бирә алам...

Малай мыскыллы елмайды:

– Акча эшлисегез киләме?..

Ләйсирә кабарынып китте:

– Нинди акча?! Минем укучым минем фәнемнән уңышка ирешә икән, бу үземә дә дәрәҗә дигән сүз, беләсеңме син шуны?!

Малайның җавабын көтмәде, үкчәсендә зырылдап әйләнде дә, каты-каты басып, класстан чыгып китте.

Икенче көнне Ильяс аны укытучылар бүлмәсеннән үзе дәшеп чыгарды.

– Әниләр белән сөйләштем... Акчасын түлибез, диделәр. Мин бит, чынлап та, укып бетергәч, физматка кермәкче булам...

– Тагын акча! Тәки аңлата алмадым бугай мин сиңа... – Ләйсирә аңа күзләре белән үтәли тишкәндәй итеп карады. – Ничә дәрес синең бүген? Биш? Алтынчысында математика кабинетына килерсең.

Партадашы хак әйткән – Ильяс чыннан да бик башлы малай булып чыкты. Укытучы әйткәнне шунда ук тотып ала, җавапларын шапылдатып кына тора. Ләйсирә аңа сокланып туя алмый. Берсендә, хисләренә чыдаша алмыйча, кочаклап ук алды. Ильяс аңа сәерсенеп карады.

– Гафу... Әйтәм бит, укучының уңышы – укытучы уңышы ул. Болай булса, керәбез без физматка...

...Баштарак математика кабинетында әзерләнделәр. Аннары Ләйсирә малайны өйләренә чакыра башлады. Әнисе уфылдый-ахылдый яннарына әллә ничә кереп чыга:

– Ник җәфалыйсың соң син аны кара төнгәчә? Мәктәптә укыганы җитмимени? – дип аптырый. Ләйсирә көлә:

– И-и, әни, ярый әле җәфалагансың дип, үзе үк рәхмәт әйтәчәк ул соңыннан! – ди.

Тик рәхмәтне иң әүвәл ул түгел, Ләйсирә үзе әйтте... Идристән көткән бәхет аның шушы зәңгәр күзле малае аша килде аңа... Кайчан, ничек ерып чыкты алар арасында баш югалтыр дәрәҗәдәге хисләр ташкыны? Аның кочагында ул үзен үсмер кыз итеп тоя, кайчакта, саташып, малайга «Идрис» дип тә дәшеп куя... Сөенеченнән айныгач, аңына килә алмыйча утыра. Үз-үзен каһәрли, газаплана, тик шуннан ары уза алмый. Кич җитү белән хәлләр тагын элекке тәртип белән дәвам итә...

Беркөнне, Ильясны озаткач, төне буе саташа-саташа уйланып чыкты Ләйсирә. Нишлисең син, кызый, бу баланы да үзең кебек бәхетсез итәсең бит... Җинаятьче булып чыгасың бит инде син... Туктал, яхшы чакта, акылыңа кил!..

Икенче көнне Ильясны мәктәп ишегалдында очратып сөйләште. Әйтәсе сүзен аска карап кына аңлатты:

– Физмат була инде сиңа... Башка йөрергә кирәк түгел...

Ильясның балкып торган йөзе шунда ук сүрәнләнеп китте. Укытучысының иңнәреннән кочып җилтерәтүдән ничек тыелып кала алгандыр?

PRESSA.RU

– Сез... Син алай эшләргә тиеш түгел... Дөрес булмый ул...

– Дөресе нәкъ менә шулай була инде, акыллым...

– Ә минем турыда уйладыңмы соң? Сине күрмичә бер көн дә яши алмыйм бит мин хәзер! – Егетнең җете зәңгәр күзләрендә усал очкыннар биеп алды.

– Тс-с... Минем төрмәгә эләгүемне теләмисеңдер бит... – Монысын ул пышылдап кына әйтте.

– Ярты елдан миңа унсигез тула... – Ильясның теле тотлыкты.

– Ярты елдан син инде институт студенты булачаксың... Сабыр итик. Имтиханнарыңа да әзерләнергә кирәк.

– Син... Сез...

Егет аны яшьле күзләре белән озатып калды.

Яши алмыйм дисә дә, яшәде, алай гына да түгел, имтиханнарын да бик әйбәт тапшырды. Институтка документлар илтә барганда исә Ләйсирәгә ияреп йөрде. Тегесе һәр имтихан көнендә аның тирәсендә булды: озатты, каршы алды. Яңа сабакташларына Ильяс аны «апам» дип таныштырды. Һәр «бишле»гә бергәләп куандылар. Факультет стенасына «бәхетлеләр» исемлеген чыгарып элгәч, Ильясның фамилиясен күреп, икесенең дә башлары күккә тиде. Институт бинасыннан җитәкләшеп чыгып очтылар.

Егетнең башкалар кебек тулай торак артыннан йөрисе булмады.

– Якында гына уңайлы фатир таптым, – диде Ләйсирә. Ул инде авыл белән исәп-хисабын өзгән, монда эшкә дә урнашып куйган иде.

Кешенең күзен-авызын томалап куеп булмый бит – авыл белән шәһәр арасында гайбәтләр күп йөрде. Ильяс әти-әнисенең читләтеп тә, турыдан-туры сораштыруыннан да туйган иде, берсендә аларның каршыларына утырып әйтте:

– Юк-бар белән үзегезнең дә, минем дә башны әйләндермәгез, – диде. – Почти әни булырлык яшьтә бит ул миңа... Ну, кайбер мәсьәләләрдә киңәшләшәм мин аның белән. Сораганда үзем дә ярдәм иткәлим...

Идрис сабыр гына тыңлап бетерә алмады, йодрыкларын уйната башлады:

– Нәрсә, бер әни генә җитмимени сиңа? – дип җикеренде. Әнисе шүрли калды:

– Чү-чү, чебеннән фил ясамыйк әле, – дип, аны малае яныннан читкә алып китү җаен карады. Тик үзенең күңеле тамчы да тынычланмады. Ильясның торышкилбәте әллә ничек, гаебе бар кеше шикелле иде шул. Башын аска иеп кенә сөйләште, бармаклары белән эскәтер читен бөтәрләп утырды.

Авылга соңгы кайтуы диплом алганның икенче көнендә үк булды. Куаныштылар, әнисе тыенкы гына үксеп тә алды. Тик... елыйсы сәгатьләре алда булган икән.

Кичке табын артында Ильяс сүзен ерактан башлады.

– Гел авыл да шәһәр, шәһәр дә авыл... Бераз дөнья күрергә дә кирәк инде...

Әнисе аңа сагаеп карады. Әтисе тураеп утырды, улының авызыннан тагын ни чыгасын көтте.

– Распределение булды... Миңа Курган өлкәсен тәкъдим иттеләр. Риза булырмындыр, ахры...

Соңгы җөмләсен ул болай гына әйтте. Инде мәсьәлә кичә үк хәл ителгән иде.

Идрис нәрсәдер әйтергә кирәклеген аңлый, тик нәрсә? Менә ул әкрен генә урыныннан куба башлады. Йөрәк тибеше ешайды, йөзе кызарынып китте. Хатыны аның беләкләренә ике куллап ябышты.

– Чү, әтисе... Киңәшкә дип кайткан бит ул... Тыңлап бетерик әле...

Идрис аның кулларын селтәп төшерде.

– Шулайдыр! Киңәшсен киңәшеп бетереп кайткан инде ул! Әйт дөресен: шуның белән китәсеңме? Шуңа еракны сайладыңмы?

Ильяс та торып басты. Әүвәлгедәгечә күзләрен яшермәде:

– Юк! – дип каты итеп әйтте. – Түлке кая китәсемне берәүгә дә әйтмәгез. Барып урнашкач, үзем хәбәргә чыгармын.

Идрис телсез калды. Бераз тынычланган кебек булды. Тик ирле-хатынлы икесе дә төне буе йоклый алмады.

Иртән әтисе каралты-кура тирәсенә чыгып киткәч, егет әнисе янына үзе килде. Нәкъ бала чагындагы кебек, иңнәренә башын төртте.

– Буталдым мин, әни!.. Үз-үземнән качып китәм бугай. Шулай дөресрәк булыр дим... Яңа җирләр, яңа кешеләр... җанымны ничек тә дәвалар әле дип өметләнәм...

Әнисе аны бераз аңлады, бераз – юк. Сораулар биреп азапламады. Ерак китә – озату авыр булыр инде; үзе генә китә – анысы хак, димәк, Ләйсирәдән качып китә. Анысын әйбәткә юрарга кирәк. Ходай теләсә, үз ишен табар дип өметләник...

Әнисенең теләге тиз генә кабул булмады – утыз бишен тутырып килгәндә генә үз ишен тапты Ильяс.

...Курганнан аны Сафакүл авылына җибәрделәр. Тырышлыгы, үҗәтлеге электән үк җитәрлек иде, башаяк белән эшкә чумды. Бөтен ихтыяр көчен җыеп, Ләйсирәне онытырга теләп яшәде.

...Теге вакытны аерылышу икесе өчен дә газаплы булды. Мәсьәләне Ләйсирә үзе хәл итте – Ильясның ике төрле тормыш белән яшәвен сизми түгел иде шул ул. Юк, юк, биш ел буе бер генә тапкыр да сүзгә килешмәде алар. Кеше арасына гына икәүләп чыкмадылар – авыл белән ике арадагы сүзләрнең Ильясның кәефен кыруын күреп тору Ләйсирәгә авыр иде. Кайчакта егет өйгә биеп-җырлап диярлек кайтып керә – студент «тусовкалары» аны шулай җилкендерә иде. Аннары кич буе шундагы хәлләр турында тәэсирләнә-тәэсирләнә Ләйсирәгә сөйли, аның йөзенә яткан күләгәне күрми дә, сизми дә... Иртән тагын аның кочагында уяна, ул әзерләгән тәмле аш белән сыйлана да кабат шау-шулы институт тормышына чума. Гомер буе шулай яшәрмен дип уйлады микән? Әллә бөтенләй уйлап тормадымы?

Ниһаять, акылы хисләрен җиңде Ләйсирәнең – аерылышу турындагы сүзне үзе кузгатты. Ул әйтмәсә,



Рәсем: Наталья Васильева

Ильяснең мәңге дә аны ташлап китү исәбе юк иде. Бу тормышына бик җайлашкан иде шул ул, биш ел буе бернинди проблема күрми, әзергә хәзер булып яшәде. Теге вакытта әтисенең әче итеп әйткән сүзләрендә хаклык юк түгел – бер әни җылысыннан икенчесенекенә барып кергән кебек булган иде.

– Китеп кара Курганыңа үзең генә. Яшәп кара ялгызың гына. Бәлки, бераздан мин сине үзем үк эзләп табармын әле, – диде Ләйсирә. Үзенең күзләре яшьле иде. Ильяс аңа аптырап, гаҗизләнеп карады, әйткәннәре һич кенә дә башына барып җитмәде. Нишләп аның белән китәргә уйламый соң ул? Нишләп? Бик рәхәт иде бит әле бергә булганда! Ул аны җилкәсеннән каты итеп кысып тотты:

– Берәр гаебем булдымы? Туйдырдыммы? Әйт!

– Киресенчә... Утырам да уйлыйм, утырам да уйлыйм... Бер-ике елдан миңа кырык тула... кем дип таныштырырсың син мине яңа урыныңда? Сиңа гаилә корырга, балалар үстерергә кирәк булачак... Ә мин...

Ильяс аны тыңлап бетермәде, лапылдап диванга килеп утырды да учлары белән йөзен каплады. Хисләрен яшермичә, рәхәтләнеп, үксеп елады. Ул Ләйсирәне аңларлык хәлдә түгел иде. Ничек?! Ул бит Курганны Ләйсирәне күздә тотып сайлаган иде. Авылдашларыннан, туганнарыннан ераккарак китеп, өр-яңа тормыш башларбыз дип уйлады бит ул.

Ләйсирә үз сүзеннән кире чигенмәде. Ильяска юл биштәрләрен әзерләргә булышты, юлына дип кайнар ризык хәстәрләде. Тик вокзалга озатырга төшмәде.

– Йә кеше көлдереп торырбыз тагын... Икебез өчен дә шулай яхшырак булыр, – диде. Соңыннан бүлмә уртасында ялгызы нәүмиз генә басып калды. Йөзе агарынган, күзләре шешенгән иде. Ильяс күңелендә ул еллар буе шул кыяфәтендә сакланды.

...Ильяска Сафакүлдә озак тоткарланырга туры килмәде – берничә ел башта гади укытучы, аннары мәктәп директоры булып эшләде дә, озакламый аңа шәһәрнең мәгариф идарәсендә эш тәкъдим иттеләр. Кандидатлык диссертациясенә дә шунда тотынды; аны яклагач, шатлыгын иң беренче Ләйсирә белән уртаклашасы килде – моның нинди зур уңыш икәнен ул гына аңлар кебек иде. Хәер, хәзер генә түгел, аны уйламый калган бер генә көне булдымы икән Ильясның? Тормышында берәр үзгәреш килеп чыкса, әй үрсәләнә иде күңеленнән аның белән сөйләшмәкче булып! Ник янымда түгел соң син минем, ник болай ятим иттең, дип бәргәләнә, эчтән генә аның белән чын-чынлап әрепләшә иде. Туган якларына ничә кайтып, ничә китте. Кайткан саен Ләйсирәне эзләде. Таба алмады. «Үзем эзләп табармын», – дигән иде, сүзендә тормады гына түгел, эзен Ильяс таба алмаслык итеп чуалтып бетергән булып чыкты.

Дөрес анысы, Ильясның юлында хатын-кызлар очрамады түгел, тик берсен дә йөрәгә чын-чынлап кабул итә алмады шул. Алар һич тә Ләйсирәгә охшамаган – һәркайсына Ильястан нәрсәдер кирәк, ни өчендер ул туктаусыз аларның капризларын үтәргә, алар теләгәнчә

PRESSA.RU

яшәргә тиеш (киресенчә түгел!) – Ильяс моны һич кенә дә аңларга теләмәде.

Галия белән танышканчы шулай булды. Ул гади тегүче булып эшли иде, шуңамы, үзен бик тыйнак тота, башкалар шикелле күктән йолдыз чүпләми. Аның белән бер-ике очрашудан соң ук Ильяс буйдак тормышына нокта куярга булды – аның ялгызлыгына әнисенең бик эче поша иде. Яраттымы ул Галияне? Мөгаен, яраткандыр. Юкса, тормышын аның белән бәйләргә җыеныр идеме? Һәрхәлдә, ул үзе шулай уйлады.

Галия, чыннан да, тормыш көтәр өчен бик җайлы хатын булып чыкты. Йортта хуҗабикә ни эшләргә тиеш, бөтенесен дә белә. Ильясны кирәкле-кирәксез сүзләр белән йөдәтми, булмаганны таптырмый, көнләшеп үзәгенә үтми. Тагын ни кирәк? Шулай тыныч кына яшәп, бер-бер артлы ике ул да табып куйды. Алар белән дә ирен артык борчымаска тырышты, күп авырлыкны үз өстенә алды.

...Беркөнне Галия кичләтеп кенә Ильяснең эш бүлмәсенә керде, каршыдагы кәнәфигә килеп утырып, бераз тын торды. Үзе бик мөһим санаган сөйләшүне тиз генә башлап җибәрә алмаса, шулай көч җыя ул. Ильяс:

– Мин шундый куркыныч кешеме соң әллә? – дип шаяртып алгач кына таралып китә.

– Ни... Ательедан шалтыратканнар иде... Эшкә чыгуымны сорыйлар. Урын барында тәвәккәлләргә иде. Менә балалар...

– Соң... Миңа ясле белешергәме?

– Яслегә бирергә жәл... Няня ялласак димәкче идем...

Ильяс уйланып алды. Няня... чит кеше була бит инде ул. Тигез генә барган тормышны бозмас микән соң? Эшкә чыгасы килә дип... Ул эшләгән дә бик җитә дә соң... Галияне дә үпкәләтәсе килми.

– Уйлашыйк әле башта, яме, матурым. Няня дигәнне карап алырга кирәк бит аны. Аларның төрлесе була.

Галия дәшмәде. Ире яныннан башын иеп кенә чыгып китте.

Карыйсын карап бетергән иде инде ул.

Кичә балалары белән йорт каршыларындагы бакчада йөрергә чыкканнар иде, шунда мөлаем йөзле бер апа белән таныштылар. Балалар уйный торды, болар сөйләшеп киттеләр. Укытучы булып эшләгән икән, хәзер пенсиядә. «Берәрсенә бала караучы кирәкми микән, белмисезме? Өйдә эшсез яту бик авыр», – ди. Галия белешергә вәгъдә бирде, үзе башка нәрсә уйлады. Балалар белән утыручы булса, үзе дә бик рәхәтләнеп эшкә чыгар иде. Бәйдәге эт шикелле ничә ел ята бит. Туганнары да онытылганда бер килеп чыга, дуслар юк дәрәҗәсендә...

Эшкә чакырып та шалтыратмадылар аны, үзе барып белеште, урын бар, теләсәң, кил, диделәр. Менә шул уй белән кергән иде Ильяс янына.

Кичке аш вакытында Ильяс үз сүзен әйтте:

– Ну чакыр алайса ул апаңны. Сөйләшик. Документларын ала килсен түлке.

Галиягә канат чыккандай булды. Шунда ук телефонга барып ябышты.

Якшәмбе иртәсе иде – Ильяснең ял вакытын туры китереп чакырды Галия яңа танышын. Үзе бу вакыйганы дулкынланып көтте. Ире ошатса гына ярар иде, Ходаем... Юньле кеше булып чыкса ярар иде...

Ханым нәкъ сөйләшенгән вакытка килде. Ишекне Галия ачты. Ильяс газетасыннан аерыла алмый утыра иде, башын иренеп кенә күтәрде. Ханымның сәламен алды да... ачкан авызын ябарга онытып, аңа карап катты. Каршысында Ләйсирә басып тора иде! Аерылышканнарына ничә еллап узды соң әле? Унбиш кенә дә түгел бугай... Ә ул тамчы да үзгәрмәгән – һаман шулай якын, үз, кадерле...

Үзләре түгел, күзләре сөйләште. «Үзем табармын дигән идемме? Менә, таптым...» «Ә мин сине күпме эзләдем, эзләдем... Ә син...»

– Галия, матурым. Син балалар янында булып тор, яме. Апаң белән икәү генә сөйләшеп алыйк әле.

Ләйсирә тураеп басты. Ишеккә таба елышты.

– Галия ханымнан башка сөйләшү барып чыкмастыр. Әни кеше әйбәтрәк белә бит инде. Мине болай да көн дә күреп торачаксыз. Ничек эшләгәнемне дип әйтүем...

...Ул дөресен әйтте – Ильяс аны көн дә күреп торды. Әмма икәүдән-икәү генә калганнары булмады – Ләйсирә беркайчан да тиешле чикне узмады. Шулай да ирнең колагына гына пышылдап алу җаен тапты: «Гаиләгезне бозарга дип килмәдем. Мин кем дә, син кем инде хәзер... Сине, балаларыңны көн дә күреп торам – шуның белән бәхетлемен...»

Әмма бу бәхете дә аңа бик исәпләп кенә бирелгән булып чыкты. Монда килеп төпләнүенә бер ел да булмагандыр – сәламәтлеге какшый башлады, хастаханә юлын таптарга туры килде. Табиблар авыруының житди икәнен, кичекмәстән операция өстәленә ятарга кирәклеген әйтте.

– Ышанычыгызны аклый алмадым, кичерегез, – диде Ләйсирә беркөнне, бөтен гаилә кичке аш өстәле янына җыйналгач. – Миңа үз ягыма кайтып китәргә кирәк. Анда туганнарым, дусларым...

Ильяс аның хәлен белә, ничә көннәрдән бирле үзе дә карадан коелып йөри иде. Ләйсирә әйтеп бетергәч, ирдән әллә нинди ыңгырашу авазы чыкты. Галия дә бу хакта хәбәрдар иде – ни дип тә җавап бирмәде, гадәтенчә башын аска иеп утырды.

Ильяс Ләйсирәне вокзалга үзе озата китте. Аның белән туган ягына кадәр бергә кайтырга иде исәбе – Ләйсирә каршы килмәслек итеп ныгытып әйтте:

– Шушында хушлашабыз. Моңа кадәргесе өчен дә рәхмәт сиңа. Гомеремнең соңгы көннәрендә сине янәшәмдә тоеп яшәвем белән бәхетле булдым, – диде. Аның күкрәгенә башын куеп басып торды. Ильяс аны иңнәреннән кочты – Ләйсирә аның кулларының калтыравын тойды. Күтәрелеп карамаса да, күзләре яшьле икәнен дә сизде. Аннары кисәктән генә каерылып, җирдәге сумкасын иелеп алды да, артына да борылып карамыйча, тиз-тиз атлап китеп барды.

Ләйсирә халык арасында эреп югалганчы Ильяс баскан урыныннан кузгалмады...

ИҢ ЯХШЫСЫ — БАЛАЛАРГА



Күп язучылар, шагыйрьләр, журналистлар аны бүген аерым бер хөрмәт, рәхмәт хисләре белән искә аладыр. Чөнки матбугатка, әдәбиятка аның киңәшләре, аның хәер-фатихасы аша килгәннәр. Редакцияләрдә аның эш стилен үрнәк итеп алганнар. Сүзем – балалар шагыйре, укыту-тәрбия өлкәсенә караган басмаларда мөхәррир булып эшләгән, хезмәт юлын мәктәптә балаларга белем бирүдән башлап, тәҗрибәле педагог һәм журналист булып җитешкән Хәкимҗан абый Халиков турында.

Без балачакта «Ялкын» журналын, «Яшь ленинчы» газетасын укып үстек. Мәктәп, пионер тормышыннан үзебез дә мәкаләләр язып салабыз, шигырьләребезне редакциягә юллыйбыз. Баш редактор үзе җибәргән «Яшь хәбәрче» таныклыгыбыз да бар инде. «Яшь ленинчы» конвертлы хатлар гел килеп тора. Әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Хәкимҗан абый Халиковның матур почерк белән язган, сөенечле хәбәрләр сыйдырган хатлары әле дә саклана миндә. Унынчы класста чыгарылыш имтиханнары тапшырып йөргәндә килгән бер хатында ул минем нәсеремне мактаган, «укып чыгып, секретариатка тапшырдым, газетаның алдагы саннарында басылып чыгар», дигән. Ахырдан: «Иҗатында уңышлар теләп, Хәкимҗан абыең Халиков» дип тә куйган әле. Монысы инде бөтенләй якын, үз итеп эндәшү! Кулга аттестат тотып, университетка укырга керергә килгәч, әлбәттә инде, башта «Яшь ленинчы»га сугылып чыгабыз, безгә хатлар язып җибәрә торган абыйапалар белән якыннанрак танышабыз. Арада Хәкимҗан абый да бар. Аксыл чәчле, күзлекле, үзе бик җайлы итеп сөйләшә... Кайсын сайларга белмичә, журналистика белән филология арасында икеләнеп калуымны сизеп, киңәшләр бирә...

Редакциягә шигырь-хикәя, мәкаләхәбәр җибәргән һәр укучыга кулдан җавап хатлары язып утыра торган Хәкимҗан абый бит ул!.. Балаларның психологиясен тирәнтен аңлап, күңел күтәрә торган сүзләрен дә таба, үсендереп тә җибәрә, этиләрчә киңәшләр дә бирә. Балаларның фантазияләрен баета, танып белү офыкларын киңәйтә, фикер йөртергә өйрәтә торган лирик-шаян шигырьләре, шигъри башваткычлары, табышмаклары, сөйләм телен үстерүгә булыша торган тел шомарткычлары аша Хәкимҗан абыйны бик тиз танып ала идек. Сакчы күркәләр, оча торган тәлинкәләр, сакаллы малайлар, шук бабайлар, биюче казлар, аксак кәҗәләр, канатлы мәчеләр... аңарда гына! Геройлары – Тәнзилә, Илгиз, Зилә, Алсу, Айрат, Гөлсем исемле кызлар-малайлар... Тагын әллә кемнәр...

«Бездә балалар китаплары күп, ләкин күбесе 5-6 яшьлекләр өчен. Безнең 2-3 яшьлек нәниләр дә бар бит әле. Шуларга Агния Барто кебек шигырь язучыларыбыз юк», – дип әйткәне хәтердә калган. Кечкенәләр өчен язганнары әнә шул бушлыкны тутырыр өчен дә булгандыр ул.

«Яшь ленинчы» мәктәбен узып, Хәкимҗан Халиков белән бер редакциядә, бер кабинетларда янәшә утырып эшләгән шагыйрьләр өчен ул остаз да, якын дус та булган.

«Без Хәкимҗан абый белән шактый еллар бер бүлмәдә кара-каршы утырып эшләдек. Ул – «Яшь ленинчы»ның әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире. Мин – корреспондент... Язучылар дөньясына килеп керүем дә, олы язучылар белән танышып, алар белән аралашып китүемдә Хәкимҗан абыйның да тәэсире булмый калмагандыр. Безнең бүлмәдән язучылар бервакытта да өзелмәде. Белмим, үзе шундый булгангамы, әдәбият бүлегенә һәрвакыт талантлы һәм әйбәт кешеләр күбрәк килә иде», – дип искә ала Роберт Миңнуллин.

Шагыйрь Зөлфәт тә: «Кулымнан килсә, «Татарстанның балалар язучысы» дигән орденны гамәлгә кертеп, шуны балаларның тугры дусты Хәкимҗан Халиковның түшенә тагар идем. Чөнки аның яшәеш мәгънәсе, гомер шигаре: «Иң яхшысы – балаларга!» – дип язган.

Шәүкәт Галиев тә редакциянең, димәк, Хәкимҗан Халиковның да дусты булган: «Китапларының беренче битен ачу белән, балалар бакчасы һәм класс ишеген ачкан кебек, шау-шулы, җанлы, кызыклы балалар дөньясына килеп керәсең», – дип искә төшергән.


«Хәкимҗан абый балаларның үзе булып көйли, үзе булып сөйли. Шуларның барысын да укыганда бер рәхәтлек туа: ул да булса – «Кояшлы көн!» – Монысы Мөдәррис Әгъләмовныкы.

...«Иң яхшысы – балаларга!» – дип җан атып йөргән Хәкимҗан абый Халиковның тууына бу көннәрдә 85 ел була. Аның шигырьләрен инде XXI гасырда туган кызлар-малайлар укый. Һәм рәхәтлек кичерә. Чөнки ул шигырьләрдәге үлән-чәчәкләр дә, җәнлек, кош-кортлар да нәкъ шул балаларча уйный, көлә, сөйләшә...

Эльмира ЗАКИРОВА

PRESSA.RU

Камал театры фойесында, мәрмәр баскыч икенче катка алып менеп киткән төштә ыгы-зыгы. Матур киенгән, бизәнгән артист җәмәгате композицион төркемгә бер укмаша, бер тарала. Әмма һәр юлы театрның йөрәге булган режиссер янәшәсендәге урынны буш калдырып тезеләләр, үзләре һаман башларын ишеккә таба боралар: кая соң инде үзе?! Ура! Ниһаять, ишектә күренделәр – гадәттәгечә икәүләшеп. Россиянең – атказанган, Татарстанның ХАЛЫК артисты Рауза ХӘЙРЕТДИНОВА икән көткәннәре. Чү! Ганиева дип тә өстәмәдем – Нури агай борылып чыгып китә күрмәсен тагын. Моннан 66 ел элек Загстан борылып чыгып китәргә җыенгандагы кебек... Загс кәгазенә Раузасы «Ганиева» дип теркәлгәч кенә тынычланган, диләр аны. Хәер, бу кадәресе мәзәкләр рәтеннән генә сөйләнә торган сүзләр.



«...МӘХӘББӘТ – УЛ ҮЗЕ ИСКЕ НӘРСӘ...»



Асия ЮНЫСОВА

Әмоннан 75 ел элек хәлләрнең бәет итеп сөйләнә торганнары булып яткан. Югыйсә барысы да матур, имин булыр кебек. Котдус абый арбалы атын җигеп, янына сөекле хатыны Бибисараны, ике кызын, бер улын утыртып җәен болынга печәнгә, көзен урманга чикләвеккә йөрер, кышларын җәмәгате белән мәктәптә балаларга белем биреп, өй эчләрен җыр-гармун авазларына күмеп, авыл сәхнәсендә спектакльләр куеп, гел шулай шат, бәхетле яшәрләр кебек. Укытучы балалары – Рауза, Ренат, Диләрә, иркә гөлләрдәй үсеп, бер-бер артлы институтларга кереп, белемле, абруйлы кешеләр булып бетәрләр кебек... Тик шул заманда «иркә гөлләр» тамырын чабасы балталар инде кайралган булган икән шул.

Сугыш! Әти фронтта, әни... Их, шушы урында – 40 яше дә тулып өлгермәгән ананың җан бирүләре хакында язулары авыр да соң! Ә теге өч ятимгә ничек яшисе дә, ач, ялангач килеш, сынык күңел белән сугыш елларын ничекләр кичәсе?! Ятим икәннәр шул. Олы Солтан мәктәбеннән атнага бер кайтканында Рауза җилкапкадан болдырга таба үткән әни эзләрен күрми. Аһ! Төшендә ишек төбендәге башмакларның урланганын күргән иде шул. Башмак югалтуны юньлегә юрамыйлар. Әллә рас килгәнме төше? Йөгереп өйгә керсә, әнисе сәнде-

рәдә кызышып ята. Сәндерәдән бүтән төшми инде ул. Өч ятимгә өй тәрәзәсеннән күренеп торган зиратка карап юаныргa гына кала. 14 яшьлек Раузаның, юанып, елап утырырга да вакыты юк. Эне-сеңелгә ул апа гына түгел, туендыручы да. Укуын да ташламый, урагын да ура, сыерларын да сатмый, алабута кушып ипи басарга да өйрәнә. Өйдәге әтидән калган гармунны сайратырга да, клубка барып, спектакльләрдә катнашырга да өлгерә. Иң мөһиме: артист булам дигән хыялыннан бизми. Үсмер кызның рухи ныклыгына, чыдамлыгына Түбән Ырга авылы шакката.

Читен инде хәле баланың. Күрше-тирә авыр эштән бу бала бөкрәеп кала күрмәсен дип тә куркып тора. «Авыр күтәрмә! Үсми калырсың!» Рәхмәт инде киңәшләренә. Киңәш биргәнче бер кыерчык икмәк куеп чыксалар соң. Ә бит үсми калу кадәресе хак булып чыга. Артистка Рауза Хәйретдинова гомер буе кечкенәлегеннән кимсенгән икән. «Рольләремне – зифа буйлы чибәр кызларны уникешәр сантиметр үкчәле читекләр киеп уйный торган идем», – ди. И-и, әле аңа кадәр!

Кыз суга Нури чишмәсенә йөри. Ерак булса ни, аның каруы, суы тәмле. Аннары чишмә юлында өйдәге яшьле күзләрдән ял итеп тора ул, хыяллар дөньясында яшәп ала. Чишмә юлында теләгән теләкләр кабул була, диләр. Рауза да сукмактан кыштыр-кыштыр атлаганда үзенә гел бәхет тели, кат-кат тели. Сугыш та мәңге бармас, әтиләре дә кайтыр... Озаклап йөргәндә көянтә дугасы җилкә тамырын баса инде басуын. Бу көянтә дә бер төшәр бит җилкәдән...

Кызның иңнәреннән көянтәне алыр егет әле яу кырында. Төньяк флот матросы, түше хәрби орден-медальләр белән бизәлгән Нури Ганиев белән Рауза инде хезмәт кенәгәсенә «Г. Камал исемендәге Татар дәүләт театрының кече артисткасы» дигән язма теркәлгәч очрашыр. Егетне очратканчы кыз беренче рольләрен уйнап өлгерер. Кечкенә генә, әмма җырлы рольләр алар. Балык Бистәсе кызындагы терелек үзе бер гаҗәбият. Камал театры каршындагы студияне ике елда тәмамлап чыгуы гына аз аңа. Театр училищесына йөгереп барып, анда дәресләр ала. Җыр сәләтен чарлар өчен Зөләйха Хисмәтуллина янында бөтерелә. Тырышлыкның әҗере – тиздән аны «Галиябану» спектакленә баш рольгә кертәләр. Яшь артистка танылып килә. Әнә креп-сатиннан кара итәк, ак поплиннан блузка да тектереп кигән. Урамда таный калсалар, оялырлык булмасын! Аннары бит әле ул исемнәре театр тарихында алтын хәрефләр белән язылып калырлык кешеләр арасында – бер сәхнәдә уйнау белән бергә, алар белән бер ишегалдында да яши. Дөрес, алар – өстәрәк, Рауза – подвалдагы тәрәзәсез комрык почмакта, күселәр белән күрше булып. Әйе, торагы да, яраткан эше дә бар, сеңлесе Диләрә дә янына килеп сыенды. Егетләр дә күренә. Кияүгә алабыз дип торганнары да бар. Тик алар әле аякка басудан ерак.

24 яшьлек кызлар – ике Роза шулай берчакны Молотов райкомолына йомыш белән кереп чыгалар. Театрда комсомол җыелышы уздырасылары бар икән. Алар кергән кабинетта бер шәп кенә егет утыра. Кызларның затын тиз абайлап ала ул. Эш көне дә төгәлләнеп килә икән: мәнле егет киного чакыра кызларны. Розалар аны, үз нәүбәтләрендә, иртәгә кичен буласы спектакльгә дәшәләр. Иптәш кыз Роза ялгызы каршы алгач, егет бераз күңелсезләнеп тә кала. Теге – бит очларында мәхәббәт чокырлары уелып торганында иде бит күңеле. Сабыр, егет, сабыр! Пәрдә ачылуга каршыңа басар ул синең. Галиябану булып! Яңагындагы мәхәббәт чокыры өчен җанын ярып бирердәй егет, Раузаның чылтыр чишмәдәй моңлы тавышын тыңлаганнан соң, тәмам хыялыйлар була. Җәннәт багы Рауза икән бит аның эстәгәне. 16 яшеннән фронтка китеп, йөз үлем белән очрашып, нәкъ менә аның өчен, шушы нечкәбил өчен исән калган икән ләбаса ул.

80 яшьлек юбилеена Мәйсәрә-Рауза иңнәренә үз зәңгәр шәлен «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза Туфитуллова сала.

Фронтовик Нури Ганиев сүзгә бик оста булса да, бу юлы озак остарып тормый. Кызны, култыклап, ике дустының ике туена алып барып кайта да өченче туйны үзләренеке итә. Мондый блиц-реванш өчен сәбәп җитди: кызны озата кергәч, ул Рауза яшәгән подвалны күрде, монда гөлчәчәген бер генә кичкә дә калдырырга ярамый! Туйны ике көн уйныйлар. Ә бит илдә 1952 ел, ягъни муллык заманы түгел. Ә Нури шундый кеше ул: ярата икән – королеваны, бәйрәм итә икән – дөнья белән! Раузасы Балтач егетенең бу мул колач белән яшәү рәвешенең рәхәтен дә, михнәтен дә татыр әле.

Нури Ганиев – кичәге диңгезче офицер үз-үзенә вәгъдә биргән икән: Раузасын да күтәрәчәк әле ул, үзе дә төшеп калмаячак! Загстан чыгып, текә баскычлардан төшеп барганда, Нури Раузаның башына киң кырлы эшләпә кигереп куя – Голливуд йолдызлары эшләпәдән йөри! («Шул көннән бирле киң кырлы эшләпә кияргә яратам», – ди Рауза Хәйретдинова.) Кияү кәләшен «патша сараена» – ниндидер сыраханәдән бушаган барак бүлмәсенә алып кайтып утырта. Аның каруы, тәрәзәле, әмма театрга йөрергә бик ерак. 11 квадрат метрлы шушы бүлмәдә аларның, эне-сеңелләрне җыеп, унберәр кеше яшәгән чаклары да була. Дүрт пәрдәле, өч антрактлы спектакльдән соң караңгы урамнарны ерып, елый-елый өйгә кайтканда Раузаның ник кияүгә чыкканына үкенгән, хәтта подвалын сагынган чаклары да була. Күрә инде моны Нури, күрә. Ә бит Раузасы тәмам танылып бара.

PRESSA.RU

Бөтен җырлы рольләр аныкы. Мәйсәрәсе, Галиябануы, Мөршидәсе... Җылама, бәгырь, яшь урынына түкмә кан! Берәр чарасын табар Нуриең.

Бер төнне Рауза, спектакльне тәмамлап, театр ишеген ачып чыкса, театр каршында «Москвич» машинасы тора. Машинага авызы ерык Нури сөялгән: «Моннан ары җәяү йөрмәссең!» 1957 ел була бу. Шәхси машиналар кешеләрнең төшенә дә кермәгән заман. Акча каян алганмы? Тапкан инде!

Әллә Нури абый Булатлардан калышып торсынмы? Ул инде бәгырькәенә Самарадан күпереп торган мамык шәл алып кайта – өшемәсен генә!

Акча табу нәрсә ул егет кешегә! Менә монда бүтән ягы бар әле мәсьәләнең. Рауза алыштыргысыз Галиябану иде, хәзер инде алыштыргысыз Мәйсәрә. Хәлиле берәү генә булды аның. Дәллюс Ильясов кына. Ә менә Булатлар дүрткә тулды. Берсеннән-берсе гаярь, берсеннән-берсе талантлы, берсеннән-берсе чибәр егетләр: Азат Аббасов, Айрат Арсланов, Мәсгут Имашев, Наил Дунаев. 16 ел сәхнәдә Мәйсәрә булды Рауза Хәйретдинова. 16 ел йөрәге янды Нури Ганиевнең. Ярый әле 70 елга якын дәвердә сәхнәдә уйналган 150 ләп рольнең барысы да ул дәрәҗәдә йөрәк яндыра торганнар булмады. «Булат бәгърем, мин синнән калмыйм», – дип, Раузасы Булат (Азат, Айрат, Мәсгут, Наил) куенына сеңеп беткәндә, фәкать йөрәгендә олы мәхәббәт йөрткән олы җанлы ир кеше генә сабыр итеп кала белә. Ярый ла, барыбер аның куенына кайта ла ул! Сатирик, комик рольләр уйналган көннәрдә Нури Гани улы да өенә тамашачы белән бергә ял итеп кайта торган иде. Тора-бара яши торган фатирлары да театрга һаман якынрак урыннан алына барды. Һәр кич саен кереп утырсаң да, берние дә юк. Театр труппасы белән гастрольләргә йөрүне дә Нури абзагыз отпуск үткәрүнең, ягъни җәйге ялның бер ысулына әйләндерде. Раузасын сабый бала урынына кайгыртуны үзенә бурыч итеп куйган ир бүтәнчә булдыра алмый да иде. Әле монда гел карап, кайгыртып торып та Раузасына алты операция ясалды, шуның дүртесе – онкология җәһәтеннән. Менә шул чакларда ни чара табарга? Ул бит әле дә – 90 яше тулган көннәрдә дә: «Раузамны яшәтү өчен яшим мин», – дип тора. Ә ул чагында – 50 генә яшьлек чагында...

Операциянең иң беренчесе – иң куркыткан истә калган. Хатын-кыз өчен күкрәк йөрәктән артык. Раузасы гасабилана, ярсый, борчыла. Нинди допинг бар соң шундый чакта? Нури абзыйның эше гел командировкалар белән бәйле булган икән. Арча районы кибетендә җәүһәр ташлы зиннәтле зәркән әйберләр күреп ала. Бәяләре – машина бәясе. Авыл халкы андыйны алмый. Нури ала – уч тутырып һәм... бушка. Чөнки түләп алырлык акча белән килмәгән. Аннары Раузага нәрсә ошарын да белми, әллә алка кирәк аңа, әллә йөзек, әллә икесе дә... Алып кайта да палатада хәл эчендә яткан Раузаның учына сала: «Болар – синеке!» Рауза да бриллиант танымый. «Куй, Нури, терелеп чыккач, бергә барып, икәү сайлап алырбыз». Шушы очрактан соң, Нури Ганиевне белешләре, ике башлы, дип йөртә башлыйлар. Бер алтының югалса да, түләп бетерешле түгел, ә монда – бер кесә бриллиант! «Теләгән булса, барысын да аладыр идем. Болай 20 кашлы алка белән, бер йөзек кенә алдык. Әнә әле дә колагында. Иң арзанын сайлады».

Нури агайның 66 еллык мәхәббәте күптән инде яратуның кайгырту формасын сайлаган. Әле кайчан гына ул, җитеш, хәтта ки мул тормыш тәэмин итү өчен, студентлар белән Пермь, Норильск, Игарка кала-портларында биналар коруда катнаша, удар төзелешләргә киткән студентлар җитәкчесе сыйфатында хезмәт куя торган иде. Ә бит шул елларда институт белеме дә алынган, диссертация дә якланган, озак еллар дәвамында медицина институтында фәлсәфә фәнен укытырлык галим булып та җитешкән. Ничек һәммәсенә дә өлгерде икән ул, дип уйлыйм да җавабын да табам: Мәхәббәт – Кешелекнең үзе кебек «иске» Мәхәббәт тылсымы бу. Югыйсә аның да «сынауларга» тарыган чаклары булган. Бер генә күренеш: театр премьерага әзерләнә. Бөтен Камал театры җәверенең атасына әверелгән хәстәрчән Нури Ганиев кунаклар каршылап йөри. Дәрәҗәле кешеләрдер инде бу кунаклар. Нури Ганиевнең шампан шәрабы әзер. Спектакль башланганчы шешәләрнең берсен ачып, кунакларны сыйлый тору фарыз. Ниндидер мәрәкә чыгып, бөке контрольдән ычкына һәм, җенгә әверелеп, Нури абыйның сул күзенә ата. Үзен «Ашыгыч ярдәм» алып киткәндә, яралы рыцарь бер генә җөмлә әйтә: «Раузага әйтәсе булмагыз!» Сул күзе күрми торган булып кала. Әмма гашыйк күзе һаман уяу. Нури абый хәзер Раузасының даруын вакытында капканмы, тамагына ашаганмысы белән көнен тыгызлап яши. Юк, алай гына түгел икән шул. Раузасының кәефе яхшымы, берәр җайсызлыгы юкмы дигәне дә – аның игътибарында.

Октябрь аенда Васильево санаториенда бергә туры килгән идек. Бер көнне Нури абый төшке ашка соңарды. «Бистәгә чыгып, педикюр-маникюр ясаучы кызларны белешеп кайттым. Рауза апагызның күңеле күтәрелеп китәр, чакырдым әле. Гел биек үкчәдән йөреп, аяк бармаклары җайсызланып калган аның. Ул бит үзе барып йөри алмый». Без, бер өстәл янында тәгам җыючы өч хатын-кыз, телсез калдык. Ирләрнең мондыйлары да була икән! Ә бит бик күпләр әнә шундый – ярата, акча таба, кайгырта белә торган тормыш юлдашы турында хыяллана. Нури чишмәсе һәр авылда да юк шул ул. Шуңа күрә теләкләр теләнми, теләнсә дә, тормышка ашмый кала.

ГАИЛӘ КОРУГА, «МИН БУЛДЫРАМ» ДИП, ТОРМЫШНЫҢ БАР ЙӨГЕН ҮЗ ӨСТЕНӘ АЛМАСКА ХАТЫН-КЫЗНЫ НИЧЕК ӨЙРӘТЕРГӘ СОҢ?

Гөлнур САФИУЛЛИНА

БУЛДЫРАБЫЗ, ӘММА...

– Алиягә мин маникюр ясатырга йөрим. Аның кебек ачык кешеләр белән рәхәт: шунда ук әллә кайчангы танышлар кебек аралаша башлыйсың. Бу сөйкемле кызның әнисе белән яшьтәш булсам да, сөйләшер сүзләребез ничектер барыбер күп безнең...

Йөри торган егете барлыгын Алия миңа беренче танышуыбызда ук әйтте. Өч ел очрашалар икән инде. Бер институтта укыганнар. Юк, икесе дә алган һөнәрләре буенча эшләргә җыенмыйлар.

– Диплом буенча урнашсам, 6-7 меңгә эшләп йөрер идем. Аңа ничек яшәргә?! Мин инде кулымда гел акча булганга өйрәнгән... Кайчак уйлыйм да, исем китә: үземнең эшем бар бит! Эшмәкәрлек безнең канда бугай, әти дә кибетләр тота.

Мактануы түгел Алиянең – ихластан сөенүе. Эчендәге – тышында... Чынлап торып уйлап карасаң, мактанырлыгы да бар анысы: аның яшендә бөтен кеше үз эшен ача аламыни әле? Бу матурлык салонында ул бит үзе хуҗабикә. Бер ел була икән инде башка чыгып эшли башлавына. Ремонт ясарга әтисе булышкан. Аренда өчен түләү, салымнар – барысы да кызның үзе өстендә. Салонның икенче почмагында бер танышы чәч кисә, тагын бер дус кызы каш ясый: аренда хакы шулай өчкә бүленә.

Ул сүзне кинәт кенә башкага бора:

– Ә без икәү тиздән Төркиягә ялга барабыз! Путевканы инде әллә кайчан алып куйдык. Үзебезнең акчага! Аннары көзен ул армиягә китәчәк... Ничек уйлыйсыз, солдатны көтү авырмы икән?

Бу сорауны беренче генә бирүе түгел бугай, чөнки җавабы инде әзер: «Түзәргә тырышырмын... Бер ел озак гомер түгел бит ул, әйеме?»

Инде безнең һәр очрашу: «Озаттыңмы әле? Киттеме?» – дип башлана торган булды. Егетен армиягә аласы көнне гел чигерделәр дә чигерделәр. Инде хәзер армиядән соң гына каядыр икәүләп бара


Фото: www.pixabay.com

алабыз, дип торганнар иде, районда – егетенең туганының туганында туйда да булып килделәр. Мәҗлестә кияргә яңа кием алышырга Венера апасы бу юлы да аны чакырган...

Ике җөмләнең берсендә исеме ишетелә торган «Венера апа»сының кем икәнен, әлбәттә, күптән беләм. Егетенең әнисе ул. Алар Алия белән көн саен телефоннан бер хәбәрләшеп алалар икән.

– Сез Венера апаның нинди әйбәт икәнен белмисез! – ди миңа Алия. – Булачак кайнанамнан уңачакмын! Шулай дип хәзер үк әйтә алам.

Шикләнмим! Алия кебек кызны да яратмасаң, аңа да әйбәт булмасаң...

Соңгы баруымда, егетен солдатка озаткан иде инде ул. Сүз гел шул тирәдә бөтерелде.

– Беренче көннәрдә бик авыр булды... Аннан үземне кулга алдым, «Гел елап утырсаң, көчең башка бернәрсәгә дә җитмәячәк, Алия», – дидем үз-үземә. Мин хәзер кичке уннан да калмый йокларга ятам – аларның да «отбой» шушы вакытта бит. Севастопольгә үк җибәргәч, башта ерак дип борчылган идем. Кемгә сөйләсәм дә: «О-о, диңгездә, корабта! Шәп!» – диләр. Хәзер аның белән горурланам – бөтен кешене дә анда алмыйлар икән... Ул кайтканчы минем дә уңышларым шактый булырга тиеш – үземә шундый максат куйдым. Тагын бер эшкә урнаштым. Ике көн үземдә эшлим, ике көн – анда.

Карагыз әле, белмисезме, миңа ипотека бирерләрме икән? Бер бүлмәле фатир алырга кирәк миңа. Шунда матурлык салоны ачар идем. Аренда өчен монда бер елга дүрт йөз меңгә якын акча түләгәнмен. Җилгә очырганмын! Ә ипотекага фатир алсам, берничә елдан ул инде үземнеке була. Моннан күчсәм, клиентларны югалтмаммы икән? Метродан аз гына ераграк булса, минем сез килер идегезме?

«Әлбәттә!» – дигән җавабымны ишеткәч, тынычланып дәвам итә:

– Әтидән акча сорый алмыйм – аның үзенең кредитлары бар. Беләм, бабайның да акчасы бар. Тик ул бирмәс шул... Юк, мин аңа үпкәләмим. Безнең бабай әбидән ун яшькә өлкәнрәк. «Миннән калгач, аңа яшәргә авыр булмасын», – дип җыя ул акчаны. Шуны белә торып, ничек сорыйм, ди, бабайдан?!

Ә акчаны барыбер табам мин! Егетемә армиягә шалтыратып: «Мин фатир сатып алдым!» – дисәм, шаккатыр иде.

Аны тыңлаган саен кәефем төшә бара... Кайсы сүзе сискәндерде мине: «Ул кайтуга без өйләнешәбез. Аңарчы мин туйга акча җыеп куярга тиеш», – диюеме? Әллә: «Ипотеканы үзем түли алам. Ике эштә эшлим бит хәзер!» – дигән тәвәккәллегеме? Алияне туктатасым, «Балакаем, булдыклылыгыңны беләм, ә ул – егетең – бу тормышта нәрсәгә ирешергә җыена?» – дип сорыйсым килә. Тик... күңелен төшерүдән куркам.

Әллә уйларымны укыды инде Алия!

– Ә ул әллә кайчан инде йорт төзергә дип хыяллана! Төзер, кулы эш белә!

Елмаям! (Ярый әле аска иелгән Алия йөземне күрми!) Булдыклы ата, үзеннән соң каласы карчыгына (кем алдан китәсен, кем каласын Ходай гына белә югыйсә) авырлык килмәсен, дип уйлаучы дәү әти янында үскән кыз тормышның бар авырлыгын хатын-кыз иңенә салып гомер итәргә җыенган егетне сайлый димени?! Булмаганны!

PRESSA.RU





Зөһрә
СӘХӘБИЕВА

ҖЫР БҮЛӘК ИТӘМ

Җәйге кич. Авыл клубы. Бүген анда Казан артистлары концерты!..

Без, артист халкы, көн саен, авыл саен күңелләрне алгысыта торган менә шундый дулкынландыргыч минутлар кичерәбез. Гастрольләребез икешәрөчәр айга сузыла. Җыр-моң яраткан халкыбыз каршында ялындырып та тормыйбыз – күңелләре булганчы җырлыйбыз. Мин концертта егерменләп җыр башкарам. Татар халык көйләре, композиторларыбыз әсәрләре... Арада Гөлшат апа Зәйнашева сүзләренә язылганнары да шактый. Кайберләрен Гөлшат апа махсус миңа дип атап язды. Андый җырлар байтак. Искә төшереп утырам да менә хәзер, һәрберсенең кызыклы тарихы бар икән бит.

Юлга чыксам, җырлап барам,
Моң уяна йөрәкләрдә...

Гөлшат апа сүзләренә Луиза Батыр-Болгари иҗат иткән «Бәхет юллары» дигән җырдан бу юллар.

Хушлашмый китәм

*Тагын күрешергә булсын,
Хушлашмый китәм.
Искә алып бер җырларсыз –
Җыр бүләк итәм.*

*Җырларым бар,
моңнарым бар
Йөрәк түремдә.
Җыр белән чын
дуслар таптым
Туган җиремдә.*

*Чын дусларым икәнсез сез,
Шатландым күреп.
Йөзләрегез шундый нурлы,
Тулган ай кебек.*

*Тагын күрешергә булсын,
Хушлашмый китәм.
Сезнең белән бер күрешү –
Бер гомер икән.*

Әле Луизаның, Батыркаева булып, исеме ишетелә генә башлаган чагы. Безнең өйгә килеп, «Җидегән чишмә» кебек популяр җыр язасым килә, дип, Хәйдәр белән миңа бер яңа җырын тыңлаткан иде.

Таңнар атса, таңнарым,
Кичләр җитсә, кичем сагышлы...

Көе дә, сүзләре дә – искиткеч! Җыр текстын бит Гөлшат апа язган! «Бөтен нәрсә сине хәтерләтә» дигән ул җыр минем репертуарга да кереп китте. Тамашачылар аеруча яратып кабул итте аны.

Күрсәң айның яңа туган,
Сызылып киткән чакларын...

Монысы – «Тәрәзәңә ай килер» (Зөфәр Хәйретдинов көе).

Син икәнсең, син икәнсең,
Гомерем буе эзләгән...

Монысы – «Син икәнсең» (Ганс Сәйфуллин көе).

Бик яратып кия торган зәңгәр концерт күлмәгем бар иде. Бар да мактый, килешә, диләр. Гөлшат апа: «Күбәләк кебек очыртып җибәрә торган җыр кирәк бу күлмәгеңә!» – ди. Озак та үтми, җыр текстын тоттыра миңа:

Гөлбакчагыз бигрәк матур,
Карыйм сокланып кына.
Мин дә очып төшәр идем,
Күбәләк булып кына.

Мин инде очып китәргә әзер! Кара, баянчыбыз Рамил Курамшинның баян өчен язган бию көенә җырлап була бит, дим! 1986 елда Нурлат районында гастрольләрдә йөргәндә «Өй артыгыз гөлбакча» җыры әнә шулай туды.

...80 нче еллар. Минем концерт бригадам Чистай районы авылларында йөри. Халык чыгышларыбызны ярата, кайбер җырларыбызны кат-кат сорый. Еш кына концертларымны «Кая гына китеп, кайларга бармадым, / Сагынып кайттым Иделем таңнарын», – дип җырлап, Гөлшат Зәйнашеваның Александр Ключарев белән бергә иҗат иткән «Туган җирем Татарстан»ы белән тәмамлый идем. Репертуарны яңартасым килде. Алкышларга күмеп, сәхнәдән җибәрми утырган тамашачыларыма, саубуллашканда, тагын киләбез, тагын күрешәбез дигән мәгънә салып җырлыйсым килде. Баянчыбыз Рамил Курамшинга: «Миңа бер яңа җыр кирәк!» – дим. Ул бер көй язып тыңлатты, ә сүзләре юк. Туктале, дим, Гөлшат апа бар бит безнең, язса – ул язар! Чаптым «переговорный пункт»ка. Шәһәрара телефоннан Гөлшат апаны эзлим. Өйдә генә булса ярар иде, дим. Ул арада, «Казан, 2 нче кабина!» дип чакырдылар! Ут капкандай, кабалана-кабалана, Гөлшат апага гозеремне аңлатам:

– Гөлшат апа! Концерт ахырында җырлар өчен бер җыр кирәк! Тиз генә яз әле! – дип, көйнең үлчәмен аңлата башлыйм.

– Ничә көннән кирәк? – ди Гөлшат апа.

– Тиз кирәк, бик тиз! – дим, сулуым кабып.

– Иртәгә көндез шалтырат! – дигән тавышы ишетелә.

Рәхмәт, Гөләни! Без Гөлшат апаны, яратып, үзара шулай йөртә идек. Чөнки ул бик җайлы, тирә-юньдәгеләр турында шулкадәр кайгыртучан, ярдәмчел кеше иде. Җитмәсә, минем якташым да әле! Ул күрше Теләнче авылында туган, мин – Салих-Тукайда, Илһам абый Шакиров – Яңа Бүләктә. Җыенábыз Сарманныкылар. Гөлшат апа белән бергә гастрольләрдә күп йөрергә туры килде. Ул конферансье булып концертлар алып бара иде. 90 нчы елларда кибетләрдә ашау-эчү әйберләре кысанланган иде. Ә кунакханәләрдә чәй кайнатырга, кием үтүкләргә генә рөхсәт ителә. Гөлшат апаның зирәк акылы безгә мондый очракларда да кыенлыктан чыгарга ярдәм итте. Берсендә шулай Әлмәт кунакханәсендә ул безгә электр чәйнегендә бик тәмле итеп өй ашы пешереп ашатты. Аннан соң (хәтерем ялгышмаса, Апаста бугай), электр үтүген әйләндереп куеп, кечкенә генә табада (ул аны үзе белән йөртә иде) коймак та пешереп сыйлады әле ул безне.

Икенче көнне тагын «переговорный пункт»ка йөгерәм, сөйләшергә заказ бирәм. Гөлшат апа өйдә! Язган! Бер кулда – телефон трубкасы, икенчесендә – ручка. Сүзләп, хәрефләп әйтеп торып, Гөлшат апа миңа «Хушлашмый китәм» дигән шигырен яздыра. Безнең әзер көйгә керә дә утыра гына. Сара апа Садыйкова берчак Сибгат Хәкимгә: «Пыяла өлгесе тәрәзә уемына кереп кенә утырган кебек, шигырең көйгә керде дә утырды», – дип язган бит әле. Безнең «Хушлашмый китәм» белән дә нәкъ шулай килеп чыкты. Бик тирән мәгънәле җыр булды ул. Аның әле дә минем репертуардан төшкәне юк. Хәйдәр дә ошатты ул җырны. Радиога Хәйдәр яздырды. Хәйдәр Бигичев дискларында ул җыр да бар.

Гөлшат Зәйнашеваның юбилее көннәрендә бу хатирәләрем аның рухына дога булып ирешсен иде.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.

Фото: Гөлшат Зәйнашева кызы Асия белән.

PRESSA.RU



Фото: Газинур Хафизов

**– Мине монда каршы алдылар...
Мине... Монда... Каршы... Алдылар... Алты ел эчендә бу җөмлә, аның эчендәге шушы дүрт кисәк сүз Миләүшә күңелендә ничәмә-ничә тапкырлар кабатланды икән?! Саны-исәбе юктыр... Үртәлеп, үкенеп, өзгәләнеп, ялварып, сагынып... Кайда, кемнәр, нигә? Болары – җаваплары табылмаган сораулар. Тик ул аларга инде җавап эзләми, кайчан да булса табачагына өметләнми дә. Хәзер эзләми... Монысы – язмыш белән килешүедер.**

Гөлнур
САФИУЛЛИНА

«ЯРАТЫП ТУЯЛМАГАН...»

Алдан ук әйтеп куям – бу язма Ярату хакында. Тагын... Хәер, ашыктырмыйм әле, сөйләгәч, барысын да аңларсыз.

Соңгы кыңгырау чыңлама, / Йөрәк бар тыялмаган. / Үз укучысын яратып – / Яратып туялмаган...

Габделфәт Сафинның «Соңгы кыңгырау» дигән бу җырын да, аңа төшерелгән клипны да хәтерлисездер. Алар да уйный алган булыр иде бу клипта: Миләүшә укучы кыз булып, Алмазы – укытучы.

– Ул безнең мәктәпкә физкультура укытучысы булып эшкә килгәндә, мин 7 нче сыйныфта гына укый идем... Алмаз үзе дә шул елны гына мәктәпне тәмамлаган иде әле. Барысы да беренче күрүдән үк башланды...

Юк, юк, очрашулар, күрешүләр берсе дә булмый, әлбәттә. Хәтта сүз кату, эндәшүләр дә. Кая ул! Күзләрдән түгелергә торган хисләрне читләрдән түгел, үзүзләреннән дә яшерергә тырышып, бер, ике, хәтта өч ел үтә әле. Алмазны армиягә алалар. Аңардан хат килгән көннәр – иң бәхетле көннәргә әйләнә. Ул хатлар энесенә язылган булса соң – кыз бит аларны барыбер үзенә дип кабул итә. (Алмаз – энесенең класс җитәкчесе, укытучының укучысына хат язуы берәүне дә шикләндерми.)

Укытучы егет солдат киеменнән мәктәп бусагасын кабат атлап кергәндә дә Миләүшә 9 нчы сыйныфта гына укый торган була әле. Аннан 10 нчы классның ахыры җитә. Дәресрәге, 14 май. Хәтерле, әйе, көненә кадәр хәтерле! Алмаз беренче тапкыр аның янына килгән, күзләр белән генә сөйләшеп йөрүдән туктаган көн бит

бу... Егетнең авылы Миләүшәләрдән сигез чакрымда – нәкъ шулай тиеш булган кебек, мотоциклы белән ул кечне кыз яшәгән капка төбенә килә дә туктый Алмаз. Нигә каушасын, күңеле белән һәр кичне шушы капка төбен әллә ничә әйләнеп иялләшкән бит инде ул! Авыл янындагы болынлыкта ике көнгә бер очраша башлыйлар. («Кайткан саен ул болынлыкка хәзер дә төшмичә калганым юк, – ди Миләүшә. – «Нәрсә табасыңдыр инде анда?» – дип, әнкәй гел гаҗәпләнә».)

Саф, чиста хисләр, ихлас мөнәсәбәтләр... Кызның чыгарылыш кичәсе көнне егет аңа чәчәкләр бүләк итә. Авыл җирендә – чәчәкләр! Шәһәргә махсус барып алып кайткан! И-и, ул пионнарның исе...

Кулына өлгергәнлек аттестаты алган Миләүшә, укырга дип, Казанга китеп бара. Аның артыннан ук шәһәргә Алмазы да килеп төшә: авыл белән Казан арасы якын җир түгел – кызның әллә нигә бер кайтуларын көтеп торсынмыни?! Милициягә эшкә урнаша. Алар өйләнешкәндә Миләүшәгә унтугызы яңа тулган була әле...

Нәкъ бер елдан кызлары Алсу туа. Аның беренче туган көненә кеше почмагыннан үз бүлмәләренә күченәләр. Икенче кызлары Лилияне инде үз фатирларына алып кайталар. Бер бүлмәле ул фатирга бөтен дөнья сыйган чаклар! Авылдан кем килсә дә – аларда туктала. Күңелләр киң: бары – бергә, югы – уртак. Бәхетле еллар! Тормышны түгәрәкләп, Алмазга өч бүлмәле фатир биреп куялар.

– Монысы күңеллесе булды... Тик тормыш бертөсле генә бармый икән шул ул...

Бу хәлләр булырга ике ел алдан Алмазы кинәт үзгәрә. Үзе, гәүдәсе монда, ә уйлары әллә кайда кебек. «Миңа инде яшәргә күп калмады», – дип, хатынын куркуга сала, үзе исә сәбәбен әйтми. Гомер булмаганны: «Фатир өчен үзең түлә», – дип шаккаттыра. (Соңыннан, кайтып-кайтып уйлагач, аңлый Миләүшә – ул аны инде берьялгызы дөнья көтәргә шул вакытта ук өйрәтә башлаган икән ләбаса.) Нигәдер гел ашыга, кабалана. Алар бер-берсен аңламый башлыйлар... Ничек аңлыйсың: гомергә аңа тавыш күтәреп бер сүз дә әйтмәгән Алмазы сәбәпсезгә кычкыра башласын әле?! Дус-иш, туган-тумача арасында моңарчы гел үрнәк гаилә була бит алар. Әйе, үпкәләшкән чаклар булгалый, тик бер-берсенә кычкырып сүз әйтү?! Ирне, әйтерсең, алыштырып куялар. Ярсып, кабынып китә дә, аннан тынычланып, Миләүшәсен килеп кочып ала. Ни уйларга белмәгән хатын, сораулар биреп, аны тагын да ярсытудан тыела: барыбер әйтмәячәк. Тешләк аның Алмазы – сөйләргә теләмәгәнен авызыннан берничек тартып ала алмыйсың. Кирәк дип тапса, күптән аңлаткан булыр иде... Алмаз: «Бурычларым бар. Фатирны сатарга туры килә», – дигәч, Миләүшә шуңа да берсүзсез ризалаша. «Кирәк» ди икән, димәк, чыннан да кирәк.

Саталар фатирны. Шәһәрдән шактый читтә, бистәдән икенчене алалар. Басу уртасындагы ике йортның берсенә күченәләр. Юллар, транспорт, кибет, мәктәп – берсе дә юк. Хәер, болар башта ул кадәр әһәмиятле булып тоелмый да. Ире: «Минем бурычым бетте», – ди бит!

Алар көзен күченәләр. Һәм шул ук көзне Алмаз югала. 28 ноябрь көнне була бу хәл.

– Ул эшкә иртәнге алтыда ук чыгып китә иде. Мин аны һәр көнне ишектән озатам. Аннан тәрәзәдән карап калам. Ул көнне карамадым шул. Күңел берни дә сизмәде, дисәм... Алмаз артыннан ишек япкач, йөрәгем ике тапкыр бик авырттырып кысып алды.

Алмаз ул көнне эшенә барып җитмәгән. Олы кызы Алсуның иренә – кияве Тимурга шалтыраткан: «Мине монда каршы алдылар... Шәһәрдән китеп торырга куштылар...» (Нигә егерме алты ел гомер иткән хатынына яки өзелеп яраткан кызларына түгел, ә киявенә шалтыраткан? «Син – ир кеше, барысы өчен дә җаваплы булып каласың», – дип әйтергә теләве булгандыр инде, мөгаен.)

Балалар бу хәбәрне әниләренә кич, ул эштән кайткач кына җиткерәләр. Тыныч көннәре берничә сәгатькә булса да озынайсын дигәннәрдер инде.

Киявебез, безнең белән танышкач: «Идеал гаилә күрдем», – дигән.

Юк, дөнья шул көнне үк ишелеп төшми әле. Бер, ике көннән дә, бер атнадан, хәтта бер айдан соң да. Көннәр бары тоташ көтүгә генә әйләнә. Алмаз бит: «Китеп торырга куштылар», – дигән, димәк, кайтачак!

– Кайтмас дигән уй хәтта башыма да килмәде! Тормыш, читтән караганда, элеккегечә дәвам итте: иртән эшкә чыгып китәм, кич кайтам. Хезмәттәшләрем белән ул көннәрдә сүзсез генә сөйләшергә өйрәндек: мин ишектән килеп керүгә: «Берәр хәбәр юкмы?» – дип, күземә карыйлар. Мин, бер сүз әйтми генә: «Юк...» – дип, башымны чайкыйм. Балалар бакчасында татар теле укытам: көндез сабыйлар янында азрак онытылып торам... Алмазның телефоны һәрвакыт «не доступен» булды. Берсендә Мәскәү базарында йөргәндә кабат аның номерын җыйым шулай. Чакыра! Әмма алмады, басып куйды. Сөйләшергә ярамагандыр инде...
И-и, сөенгәннәрем шулчак! Исән! Димәк, кайта!

Алмазсыз, чыршысыз, бәйрәм табынсыз Яңа ел да узып китә. Тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп: берсендә булмаса, икенчесендә таныш шәүлә күренер кебек тоелып...

Казанда милиционер булып эшләүче бер авылдашлары 10 гыйнвар көнне әтиләренә шалтырата: «Югалган теге Алмаз абыйны таптык бугай...» Аның әти-әниләре шунда ук Миләүшәнең туганнарына хәбәр итәләр. Авылларны урап, күтәрә алмаслык авыр хәбәр Казанга кире әйләнеп кайта: «Тапканнар... Кунакханәдә... Паспорты кесәсендә...» Бәлки ул түгелдер, дигән өмет киселә.

– Без аны 12 гыйнвар көнне җирләдек... Моргтан туры авылга алып кайтып киттек. Бик тиз бирделәр, әйтерсең, тизрәк күмеп куюыбызны телиләр. Шундый тәэсир калды... 44 көн күрмәгән бит, күрәсем килә... Сагынганмын... Йөзе бер дә үзгәрмәгән иде. Таушалмаган, чиста, пөхтә. Юынган, кырынган. Шул гомер кайда булган, кайда яшәгән, ниләр ашап торган – берни белмим... Иң авыры: ничә ел яшәп, аның миңа берни аң-

PRESSA.RU

латмыйча, саубуллашмыйча, бәхилләшмичә дә китүе булды. Бөтен серне үзе белән алып китүе... Соңыннан гына әйттеләр, югалган көнне үк эшенә шалтыратып: «Мин башка эшемә чыкмыйм, урыныма кеше эзләгез», – дигән булган. Бу вакыт милициядән китеп, бер оешманың сак хезмәтенә урнашкан иде ул. Кызым Лилиягә дә югалганнан соң, берничә көн узгач, «смс» җибәргән булган икән. Аның: «Әти, кайт!» – дигәненә инде җавап бирмәгән. Миңа бер хәбәре дә булмады шул, «смс»лар барыбер яза алмый, дигәндер инде... Ул чакта яза белми идем әле.

Кайгы-хәсрәт ялгыз йөрми, диләр. Аяктан егарлык бу хәбәр артыннан ук икенчесе килеп ирешә. Аннан – өченчесе. Башта, Алмазның җидесе узгач: «Мин иреген дусты. Аның миңа бурычы бар», – дип, бер ир-ат шалтырата. «Мин бит сезне белмим. Аннан, ул бит «бурычын кайтардым» диде. Сезгә күпме тиеш иде?» – ди эченә салкын йөгергән Миләүшә. Җавап аны кабат аяктан ега: «Ике йөз мең». Күрәчәгең булмасын икән дә бит... Суд юлында да йөрергә туры килә шул. «Мин аның дусты», дип таныштырган ул кешедә Алмазның бурычка акча алып торуы турында үз куллары белән язган язу калган – суд «түләргә» дигән карар чыгара.

Без аңларлык җеп очы юк...

Алмазның эш урынында калган әйберләрен алырга киткән энесе яңа хәбәр белән кайта: абыйсының банкларга да бурычы булган икән. Берничә йөз мең... Фатирны сатарга, кечерәккә күчәргә туры килә – әҗәтләрдән шулай котылалар.

– Инде Алмазсыз яшәргә өйрәнергә кирәк иде, – ди Миләүшә. – Мин бит аның өченче – иркә кызы булганмын. Кибеткә дә йөртмәде ул мине, кирәк-яракның барысын да үзе алып кайта иде. Кием-салымга кадәр. Аны югалтканчы, бөтен кеше дә шулай яши дип белә идем...

Җан авыртуын бер дару да басмый икән: кысып ала да, үзәгеңне өзәрлек итеп авырта ул. Әрни, сыкрый... И-и, ул илереп-илереп елаулар... Язмыш дип карадым, сынау дип тә, каргыш дип тә. Лилия үз янымда иде бит әле: кызым белән икәү утырабыз да уйлыйбыз. Әмма: «Нигә болай килеп чыкты соң?» – дигән сорауга җавап тапмадык – йомгакны сүтә алмадык. Балалар бакчасындагы психолог янына йөрдем. «Өч елга кадәр авыр булыр әле», – диде ул. Дөрес әйткән булып чыкты. Ә сагынуы – анысы инде аның гүргәчә озата барыр... Мине ул чакта эш коткарды. Ходай ярдәмне шулай җибәрде бугай. Алмазны җирләп килгәч, кан басымым күтәрелеп, авырып киттем дә, бер атна өйдә тордым. Шимбә көнне бакча мөдире шалтырата: «Безгә министрлыктан тикшерү килә», – ди. Шәһәрнең 75 балалар бакчасыннан килделәр ачык дәресемә. «Ул бит әле яңа гына ирен югалтты, дип, бөтен район белән җәлләдек үзеңне», – диде кызлар. Эшкә күмелүем файдага гына булды – азмы-күпме онытылырга ярдәм итте.

«Барысы да Алмазны хәтерләтә», – дип, күчкәндә өй эчендәге җиһазларның берсен дә фатирына кертмәскә тырыша ул. Караватның ире йоклый торган ягына ярты ел буе борылып та карый алмый, аннан сатып ук җибәрә. Тик хатирәләрдән шулай гына котылып булса икән?!

– Хатын-кызның бәхете гаиләдә аның. Бергә чакта моны аңлап кына бетермисең. Гел шулай дәвам итәр кебек бит... Бер ел буе күземнән яшь кипмәде. Тик елап та җиңеллек табып булмый андый чакта, ул да җандагы әрнүне басмый. Эчтә давыл кузгала башлавын сизсәм, шунда ук кулыма дога китаплары ала идем. Укыйм, укыйм, укыйм... Догалар булыша!

Мондый чакта киңәш бирүчеләр күп була. Әмма ул киңәшләргә колак салу гына авыр. Ә салырга кирәк! Күпләр үз башыннан кичкәнне әйтә сиңа. Яхшылык теләп әйтә. Без Алмазны җирләп китеп баруга, әнкәй янына авылдашыбыз Суфия апа кергән. «Әйт балама, фотосурәтләр карый күрмәсен», – дигән. Ирен, аннан улын җир куенына салган апа ул, хәсрәтнең ни икәнен белә. Минем дә беренче көннәрдә кулымда гел Алмаз фотолары булган: әйләндерә-әйләндерә гел шуларны карап утырганмын. Балалар алып яшергәнче...

Китап укып булмый, телевизор карый алмыйсың. Җыр тыңларга ярамый. Андый чакта җандагы борчуларны таратырга кул эшләре булыша икән, алар тынычландыра: бәйләү, чигү, тегү кебек нindидер бер шөгыль табарга тырышырга кирәк.

Без психологка барырга да өйрәнмәгән. Ә барырга кирәк! Якын кешесен югалту кебек хәсрәт кичергән кеше бу кайгы эченнән чыгу юлын эзләп бәргәләнә. Һәм ул аны үзе генә бик озак тапмаска мөмкин. Психологлар исә шул юлны күрсәтүчеләр алар.

Татарның шулай бит инде: кулы сынса – җиң эчендә. Кеше алдында күз яшьләремне күрсәтмәскә тырыштым. Моның өчен күп көч кирәк, әлбәттә. Түзәсең-түзәсең дә аннан ялгыз гына калгач, бушанасың...

Алмазга гына сөйлисе күпме яңалык җыелган күңелдә! Бабасыннан әле кечкенә генә булып калган оныгы Камилә инде зур үсте. Ул хәзер үзе апа! Алмаз исән булса, Алсуның улы Нариман аның өчен дөньяның иң зур куанычы булыр иде... Икенче кызлары Лилиянең дә тормышлы булуын, аның ирен дә улы кебек якын күрүен сөйлисе килә. «Кияүләрдән дә, кода-кодагыйлардан да бик-бик уңдык без, әтисе!» – диясе...

– Язмыштыр бу... Ә тәкъдирдән качып булмый. Мин шундый сынау үтәргә тиеш булганмындыр... Инде теге дөньяда бергә булырга язсын иде. Мин һәр көнне, һәр иртәне Ходайдан: «Алмазымның гөнаһларын ярлыка!» – дип сорыйм. Алты ел буе! Юк, Алмазга карата күңелемдә бернинди үпкә, рәнҗү юк. Бары сагыну гына...

P. S. Кызганыч, бу икәүнең нинди матур пар булганын сезгә күрсәтә алмыйм – бергә төшкән фотосурәтләрен журналда чыгарудан Миләүшә баш тартты. «Кабат яраларга кагылу булачак... Ә мин аңа әле әзер түгел икәнмен...» – диде ул. Әйе, шулайдыр... Әңгәмәдәшемнең үтенече буенча, язмада исемнәр дә үзгәртелде.



МИҢНУЛЛИНА-ЮНЫСОВА Әлфия

Казан дәүләт университеты

Кияүдә, ике баласы, бер оныгы бар

Карьера: Бөтендөнья татар конгрессы сайтының мөхәррир-модераторы

Тормыш шигаре: «Кеше һәрвакытта, һәркайда үзен уңайлы хис итәргә тиеш. Бу уңайлылык күңелдә дә, тәндә дә, көндәлек тормышта да булсын».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Юбилейларга әзерләнәбез

Узган елга әтием Туфан Миңнуллин белән әнием Нәҗибә Ихсановага багышлап планлаштырган эшләремнең барысы да диярлек эшләнде.
Әти сүзләренә язылган җырлар җыентыгы дөнья күрде.
2018 ел – әнинең юбилей елы. Шуңа багышлап, Санкт-Петербург рәссамы Рәшит Гыйләҗев әнинең портретын язды. Әнинең бик матур буклеты басылып чыкты. Камал театрында юбилей кичәсе узачак.
Әле шуңа әзерлек бара.
Озакламый үземнең дә юбилеем җитә.

Төшмәде дә, күтәрелмәде дә

Россиялеләр кебек кризисларга чыдам халык бармы икән дөньяда? Бер адым атлыйбыз да артка борылып карыйбыз дигәндәй, бераз акча күрсәк, кайчан кризис булыр икән, дип көтә башлыйбыз. Көтәбез дип... көтмибез инде, ул безнең чынбарлыкны тудыра.
Быел менә рубльнең бәясе артык төшмәде. Россия Үзәк банкы рәисе Эльвира Нәбиуллина, рәсми инфляцияне Европа күрсәткечләренә тигезләште дә, ул быел 2,5 процент булыр, диде. Ниһаять, без дә тотрыклылыкка ирешәбезме әллә?

Хатын-кызлар үзләрен үзләре яклый

Соңгы вакытта мәгълүмат чаралары аша хатын-кызларга сексуаль бәйләнүләр хакында күп ишетергә туры килде.
Бу турыда хатын-кызлар үзләре әйтә башлады. Элек бу әйберне яшерәләр иде, чөнки оят саналды, еш кына хатын-кызның үзен гаепле итеп тә калдыралар иде. Акча янчыгын урлаткан кешене «үзе белән йөртмәсен иде», дип гаепләп булмаган кебек, бөтен гаепне хатын-кызларга гына ягып калдыру дөрес түгел. Хәзер хатын-кызлар үзләрен яклый башлады. Әлбәттә, пычракта казыну матур күренеш тә түгелдер, ләкин кычкырып әйтмичә, аннан котылып булмаячак.

сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

Дус дигәнең дошман булса...

Миңа һәм безнең гаиләгә якын булган яки дустанә якынлыкка дәгъва иткән кайбер кешеләрнең чынлыкта андый түгеллеген ачыклау бик авыр булды. Кешеләргә ышанычым нык кимеде.
Бу хәл аяктан ега язды дисәм дә, арттырмам. Ләкин, шөкер, егылмадым, бирешмәдем. Алга таба да бирешмәскә исәп.

Тәнемдә җаным барда, ана теле өчен борчылам

Җаны булган һәр татарны борчый бу сорау: ана телебезнең хәле ничек булыр? Бүген Казан урамнарында кешеләрнең татарча сөйләшкәннәрен ишетеп йөрибез. Киләчәктә дә татарча бер сүз ишетергә тилмермәсәк ярар иде. Дога кылганда, балаларымны, якыннарымны рәхмәтеңнән ташлама, дигән теләкләремә халкыбыз, телебез яшәсен дип тә өстәп куям.

Ярымутрауларда һаман сугыш

Адәм баласы җиде кат күккә менә, су төбендә йөри, ә менә үзара тынычлык таба алмый. Быел Төньяк Корея белән АКШ арасында низаг кискенләште.
Янә бөтен дөньяны атом-төш сугышы белән куркыта башладылар. Әйтерсең лә атом-төш коралы – уенчык. Сугыш чыга калса, нәтиҗәләре бөтен кешелек дөньясына зыян салачак бит. Гап-гади кебек тоелган мәсьәләләрне хәл итү еш кына бик катлаулы булып чыга.

PRESSA.RU



КАШ БЕЛӘН КҮЗ АРАСЫ



Лилия
ГӘРӘЕВА

БЕЗ БУ ҖИРДӘ ЮЛАУЧЫЛАР ГЫНА. ЮЛНЫҢ АХЫРЫ ДА БИЛГЕЛЕ. ӘММА СӘЛАМӘТ ЧАГЫБЫЗДА, ҖИР ҖИМЕРТЕП ЯШӘП ЯТКАНДА БУ ХАКТА УЙЛАМЫЙБЫЗ ӘЛЕ.

Безне иң куркытканы билгесезлектер, мөгаен. Теге дөньяда ни барын беркем белми, аннан әйләнеп кайткан кеше юк, диләр бит. Әмма үлем белән күзгә-күз очрашып, кылдан нечкә яшәү җебен кабат ялгап җибәрүчеләр бар.

Ләйсән Шәвәлиева (үзенең үтенече буенча исемнәр үзгәртелде – *авт.*) 16 яшендә юл һәлакәтенә очрап, дүрт айдан артык комада була.

Ул көнне гомерендә дә онытмас ул. 2012 елның 20 гыйнвары – кышкы сессиядән соң студентларның беренче көн укырга барулары. Иртәдән үк никтер ашыкты Ләйсән. Күңеле каядыр әйди, ниндидер эшне эшләп өлгерәсе бар сыман. Үзен олы юлга кадәр озата чыккан әнисенә дә ниндидер бер мөһим сүз әйтелми калды кебек. Телгә ияреп калган бәйләнчек җыр сыман, күңелендә гел бер сүзләр әйләнде кызның: «Өлгерергә! Өлгерергә!» Кая өлгерергә? Дәрескәме? Соңга да калмый лабаса.

Күрәчәгенә ашыккан икән шул. Кузгалып маташкан автобусның ябылырга өлгермәгән ишегеннән апасы белән сикереп менеп утырмаган булсалар... Автобусның икенчесен көткән булсалар... Үзәге өзелгән саен әниләре Сәвия апа да мең кат кабатлар әле ул «булса»ны. Көне дә зәмһәрир салкын иде бит. Җибәрмәгән генә булса

кызын. Сеңлесенең җансыз гәүдәсенә капланып, тынсыз иреннәренә үз сулышын сулатырдай булып өзгәләнгән Алсуның да күңелен гел бер уй битәрләр: «Кулыннан гына кысып тоткан булсам!» Тормыш шарт фигыльгә буйсынмый. Бар да булган инде аның өчен. Күптән уйланылган, кешенең күрәчәге Җир яралганда ук язып куелган.

Автобус үз артыннан пар болыты бөркеп китеп барган мәлдә, юлга таба тик бер адым атларга өлгерә Ләйсән. Куе пар аша өстенә үкереп килгән йөк машинасын күрми дә кала ул. Сеңлесеннән кул сузымында гына булган Алсу да күрми аны. Соңыннан, гомеренең шушы бер минутын секундларга бүлә-бүлә, мең кат сүтеп, мең кат ялгаганда ул бер минут өч мизгелгә сыячак та бетәчәк. Газабы елларга сузылачак бер минут. Бәлки, бер генә минут та булмагандыр. Машина бит сеңлесен 32 метр сөйрәп барган булган.

Авыл белән район арасы әллә ни ерак та түгел, күп булса, ярты сәгатьтә үтеләсе юл. Ул көнне бу юлны үткән ара йөз елга сузылгандыр кебек тоела Сәвия апага. Күңеленә бер уй сүрән генә җылылык сирпи: «Үлде, димәделәр бит». Алар килгәндә Ләйсән инде реанимациядә була. Аппарат белән генә суласа да, йөрәге тибә. Димәк, өмет бар. Менә-менә күзләрен ачар да... «Ул комада. Көтегез!» – диләр. Күпме көтәсе? Бер көнме? Атнамы? Минутларга сәгатьләр ялгана. Сәгатькә – көннәр... атналар... айлар...

Ләйсәннең юл буенда ятып калган сумкасын алып кайтып биргәч, эченнән йомарланган бер бит кәгазь килеп чыга. Аның кулы белән русча язылган ике юл шигырь: «Я хочу летать, я хочу мечтать. Я хочу любить, я хочу ЖИТЬ!!!» «Әнием, без әле бирешмибез, без әле яшибез», – дип әйтеп калдыруымы бу аның?

Комадагы кешенең халәтен яшәү дип әйтеп була микән? Ул вакытта кызының комага китүен бүген Сәвия апа Аллаһының бер җиңеллеге булгандыр ди. Казналыгы сынып, тешләре кәкрәйгән, сул кулы чәрдәкләнгән, оча сөяге икегә аерылган, баш чүмече ярылган... Комага китмәсә, сызлануларга нихәл чыдар иде?

Бу хәлләрне тизрәк онытасы килә Сәвия апаның. Ул инде аларны, кабат искә төшермәслек итеп, күңел төпкеленә күмгән. Чарасыз, гасаби вакытлар... Кемдер: «Яшь организм бит, савыгырга да мөмкин», – дисә, кемдер: «Булмастайны өмет итәсез. Исән калса да, үсемлек булачак. Гомер буе кашыктан ашатачаксыз», – ди. Кайсы ананың бу сүзләр белән килешәсе килсен?!

Өч ай реанимациядә була Ләйсән. Аннары палатага чыгаралар. Күзләрен ачып, үзе сулый башласа да, аңына килгән дип әйтеп булмый әле аны – беркемне танымый да, бернигә ишарәләми дә – комадагы халәте дәвам итә. Бугазында – трахеостома, борынында – зонд... Ананың: «Акылы кайтачакмы?» – дигәне һавада эленеп кала. «Кызым, мине таныйсыңмы? Кулымны гына булса да кыс, керфегеңне генә булса да тибрәт!» Газизен бу дөньяга кайтарырга тырышып өзгәләнгән ананы юатудан табиблар да чарасыз: «Яраткан җырларын куегыз, күбрәк сөйләшегез».

– Әй ул вакытта безнең күргәннәр! – ди Сәвия апа, җанының сулкылдавын басарга тырышып. – Шунда инде мин дөньяда яхшы кешеләрнең күбрәк булуына инандым. Безгә табибларның да иң яхшылары очрады. Бер дә онытмыйм, Ләйсән утыра да алмый иде әле. Бер невролог керде дә Ләйсәнне күтәреп торгызды. Аның ярдәме белән нәкъ алты адым атлады кызым. «Болай булгач, була, өмет бар», – дигән сүзләре яшәү өчен көрәшергә көч бирде бугай инде безгә.

Палатага чыгу тормышларының яңа бер этабы гына була әле. Шулай ук катлаулы, газаплы этабы. Ләйсәннең, әүвәлгечә, бу дөнья белән бәйләнеше юк. Акылы – сабый баланыкы кебек. Кешенең бу халәте дә кома дип атала икән. Бер аягы белән бер кулы кәкрәеп катып калган, казналыгы чалшайган, борынындагы зонд аша гына туклана алган кызны, дәва вакыты чыкты, инде эшлисен эшләдек, дип, өйгә кайтарып җибәрәләр.

Клиник үлем – яшәү белән биологик үлем арасындагы кылдан нечкә чик.

– Өйгә кайтуның икенче көнендә яткан җиреннән торып утырды. Бу безнең өчен могҗизага тиң иде. Акрынлап аңы да кайта башлады. Беренче булып апасы Алсуны таныды. И шатланганнарыбыз! Әлбәттә, сәламәтләнү бер көндә генә булмады. «Бала»лыгы озак барды әле. Яшәү өчен көрәш сигез еллап дәвам итте безнең. Бирешергә исәп юк. Алда тагын авыр сынаулар көтә иде әле – Ләйсәннең сынган казналыгын ялгап, тешләрен урыннарына утыртырга кирәк иде. Казналыкны тимерчыбыклар белән тарттырып, кабат җыйдылар. Алты сәгать барды бу операция. Кабинеттан чыкканда, авызы кып-кызыл кан иде. Өч ай буена авызын ачарга ярамады. Сыек шулпаны теш арасыннан салып, шулай гына ашата алдык. Анда да бер күз яше күрсәтмәде, бер сыкрау авазы чыгармады. 16 яшьлек баланың авырлыгы нибары 32 кг калган иде ул вакытта».

Өр-яңадан утырырга, йөрергә генә түгел, укырга, язарга да өйрәнергә туры килә аңа. Беренче сыйныфтан ук гел «бишле» билгеләренә генә укыган кызның, акрынлык белән булса да, онытылган белеме кире кайта. 10–11 нче сыйныфларны тәмамлый – укытучылар өйгә килеп укыталар. Коляскада утырган килеш, башкалар белән бергә ЕГЭ тапшыра, институтка керә.

Гомерләренең тагын бер мәңгегә истә калырлык көне – Ләйсәннең кабат аягына баскан көне.

– Көз көне иде. Бакчада бәрәңге алып ятабыз. Күземне күтәреп карасам, Ләйсән чыгып килә. «Әллә берүзең чыктыңмы?» – дип кычкырганымны сизми дә калдым», – ди Сәвия апа.

Бу аның өр-яңа тормышының өр-яңа адымнары була. Комадагы чагын бөтенләй дә хәтерләми ул. Бары тик һәлакәткә кадәрге көне генә истә. Дәрескә бару уе белән комага китә, шул ук уй белән уяна да. Әйтерсең арадагы дүрт ай бөтенләй дә булмаган...

Фото: www.pixabay.com

PRESSA.RU




МОГҖИЗА ТУГАН ҖИРДӘ



Фәнзилә МОСТАФИНА

ШОТЛАНДИЯ ДИГӘЧ, МИНЕМ КҮҢЕЛДӘ АШКЫНУ ҺӘМ... КУРКУ ХИСЕ ЯРАЛА ИДЕ. ӘБИЕМ ӘЙТМЕШЛИ, КУРЫККАН ЭШ ХӘЕРЛЕ БУЛА ИКӘН.



Автор фотолары

Теләкләр чынга аша

Лондонда яшәүче дус кызыма кунакка килгәнемә дә бер атна булды. Тагын берничә көннән Шотландиягә юл тотасы. Берүзем генә! Бөекбританиягә кадәр баргач, әллә кайчаннан бирле ымсындырып торган Шотландиягә дә сугылып китми булмас, дип, алдан ук хәстәрен күреп, билетлар да алып куелган, яшәү урыны да табылган инде югыйсә. Ә күңелдә – курку. Моңарчы чит илгә япа-ялгызым чыгып киткәнем юк бит әле. «Мин якында, Англиядә генә бит», – дип тынычландырган була дус кызым. Ул инде Шотландияне күреп кайткан, минем белән бармый. Куркуымны да аңлап бетерми. Ә мин йокларга яткан саен теләк телим: «Аллаһы Тәгаләкәем, Шотландия сәфәрендә миңа берәр маяк бирсәң иде!»

Һәм Ул бирде. Берничә көннән Шотландиягә кузгаласы дип уйлап, ә әлегә Лондон урамнарын гизеп йөргән көнне телефоныма смс килеп төште. Таныш түгел номер: «Сәлам! Сез Лондонда икән. Мин дә Лондонда. Бәлки күрешербез? Чит-ят җирдә ике татар очрашып сөйләшеп утырсак, күңелле булыр иде», – дип язган. «Сез кем соң?» – дип язам. Җавап килә: «Мин – Татарстаннан, гап-гади бер татар егете. Сезнең номерны уртак танышыбыз бирде» (ул уртак танышның «Сөембикә»дә бергә эшләүче хезмәттәшем икәнен белгән юк әле! – *Ф. М.*). Очрашырга килешәбез.

Икенче көнне билгеләнгән вакытта дус кызым белән очрашуга киттек. Ренат безне Шерлок музей-йорты каршында көтеп тора. Ул да дусты белән килгән. Дүртәүләп паркка барып утырабыз да чөкердәшеп чәй эчәбез. Сүз иярә сүз китеп, берничә көннән Шотландиягә барасымны әйтәм. «Ә мин Шотландия башкаласы Эдинбургта укыйм», – дип куймасынмы Ренат! Бактың исә, Казанда укытучы булып эшләүче Ренат Эдинбургка ике атналык курсларга килгән икән. Ә мин берничә көннән Эдинбургка кузгалам! «Әйдә, мин сине Эдинбургта каршы алам? Мин анда бер атна яшәдем бит инде, хәйран гына чамалый башладым», – ди Ренат. Шушы мизгелдә мин, һәр төнне теләп яткан догаларымның кабул булуын тоеп, балкып елмаям. Мин көткән ярдәмне Татарстаннан килгән татар егете кыяфәтендә бирсен әле! Болай булгач, Шотландия сәфәре һичшиксез могҗизаи булырга тиеш!

Саумы, итәкле ирләр иле!

Иртәнге сәгать алты. Автобус инде Шотландиягә керде. Минем башта беренче сораулар да туа башлады. Тау битләрендә утлап йөргән бу бәрәннәр әллә бер дә йокламыймы, төнгә дә өйләренә кайтмыймы икән? Аларның, гомумән, өйләре бар микән? Тукта-тукта! Ренат минем киләсемне онытмады микән?!

Британия өчен вакыт бик иртә әле. Шәһәр уяна гына башлаган. Төне буе елап чыккан, күрәсең: юллар юеш, агачлар, чәчәкләр юеш, бөтен Эдинбург юпь-юеш. Куртка якама муенымны батыра төшеп, тәрәзә кыегыннан тамган тамчыларны санап басып торам. Инде 15 минут шулай торам. Урамда эт тә юк. Ренат та юк. И-и, үзем дә юләр инде. Хәзерге заманда егетләргә ышанып буламы соң инде, йә?..

– Сәлам! Гафу, бераз соңардым. Аның каруы, мин сиңа чып-чын татарча сөтле чәй ясап алып килдем.


Тамчылар тамудан туктый. Каршыдагы соры йорт кыегыннан кояшның беренче нурлары күренә. Күңелдә бөреләнә башлаган курку катыш ачу да шиңә. Без, ике татар, Эдинбургның үзәк урамыннан яңа көнгә таба атлап китәбез. Ренат, кулларын болгый-болгый, Эдинбург турында үзе белеп өлгергән кадәресен сөйли, араларына Тукай шигырьләрен дә кыстырып ала. Мин, ул алып килгән сөтле чәйне эчә-эчә, йөгерә-атлый аның артыннан иярәм. Бераздан Ренат уку йортына китеп бара. Ул дәрестә вакытта мин Эдинбургны үзем генә өйрәнә торасы.

Итәк дисәң, үпкәлиләр тагын, «килт бу!» дип төзәтәләр.

Озак та үтмәде, итәк киеп акча эшләргә чыккан ирләр күзгә чалына башлады. Төркем-төркем туристларны йөртүче ак сакаллы абзыйлар да үзләренең милли киеме – килтны кигән. Әнә итәк кигән икенчесе урам читендә басып тора. Каршында – эшләпәсе. Акча салу өчен. Чын шотландны кочаклап фотога төшәргә теләсәң, рәхим ит, бер фунт булса да сал. Салмыйча гына да төшәргә булыр иде, билгеле, тик иртә таңнан шулай киенеп, «эшкә» чыгып бас-

PRESSA.RU





■ «Артур ияре» тавы башыннан бөтен Эдинбург уч төбендәге кебек. Тирә-якта сары мәтрүшкәләр (монда да үсә икән алар, әй!), Әмирхан абый Еники сурәтләгән кылганнар тирбәлә. Офыкта күк белән диңгез тоташа. Шушы тау башында чалкан ятып, күзләрне йомып, диңгезгә кадәр булган араны очып кына үтәсе килә...



кан бит инде, миннән калмасын – акчамны салам. Фотога төшкән арада, итәкле абзыйдан бу милли киемне гадәти тормышта киюкимәүләре хакында сорашырга өлгерәм. «Гадәти тормышта кимибез, ә менә бәйрәмнәрдә, туйларда киябез. Үзен хөрмәт итә торган һәр шотландның килты булырга тиеш», – ди. Ә без аларның итәгеннән көлгән булабыз...

Шотландия – волынкада уйный торган итәкле ирләр иле.

Үзәк урамның бер башында – Эдинбург ныгытмасы. Эчкә керү түләүле – 15 фунт (безнең акча белән 1200 сум тирәсе). Әле тагын барасы җирләр күп булуын исемә төшереп, Лондонда күргән крепостьлар да нәкъ шундый ук инде ул, дип, эчкә кермәскә булам. Ә менә янәшәдә генә урнашкан туку һәм тегү фабрикасына сугылып чыкмый кала алмыйм. Дүрт катлы бинаның беренче катында кибет урнашкан. Ул Шотландия сувенирлары белән шыплап тутырылган. Карале, мин иртән күргән бәрәннәр гади генә бәрән түгел, милли горурлык икән бит. Аларның сурәте открыткаларга да, кружкаларга да, футболкаларга да төшерелгән. Ә иң күп урынны, әлбәттә инде, Шотландиянең шакмак бизәкле киемнәре алып тора. Эчке киемнәрдән башлап, ир-атлар кия торган итәкләргә, хатын-кыз күлмәкләренә, пәлтәбашлыкларга кадәр бар монда. Туку станоклары да шунда гына – подвалда урнашкан. Тукучының ничек итеп эшләгәнен рәхәтләнеп карап торып була. Моның өчен акча да сорамыйлар, куып та чыгармыйлар.

Бөекбритания – бик кыйммәтле ил. Шуңа күрә монда барганда бушлай күңел ачу чараларын, бушлай карарга мөмкин булган җирләрне барлап барырга кирәк. Бәхеткә, алары җитәрлек. Төш вакытында Эдинбургта чып-чын концерт башланды. Урам концерты. Менә берәү фокуслар күрсәтә. 20 минут үтүгә, эшләпәсен тотып, халыкны әйләнеп чыга да, матур гына итеп китеп бара. Аның урынын икенче артист ала. Монысы җырлый, әтәч тавышлары да чыга үзеннән, хатын-кыз тавышы да, Иосиф Кобзонныкы да. 20 минут үтүгә, монысы да чыгышын тәмамлый. Һәр чыгышка вакыт исәпләнгән икән – 20 минут. Ә халык фонтан кырыйларында, тротуарда, асфальтта утыра. Үзе ошаткан артистның эшләпәсенә вак-төяк акчасын да сала. Рухи азык алу өчен зиннәтле кәнәфиләр дә, бәрхет пәрдә белән каймалап алынган сәхнә дә кирәкми икән. Артист кирәк, һәм тамашачы кирәк. Шул җитә.

«Әпипә»ле сәфәр

Укуын тәмамлап, яныма Ренат килеп җитә. Тамак ялгарга дип икебезгә дә банан алган. Ул бананны болай гына ашасак, бик җиңел булыр иде. Шуңа күрә болай килешәбез: хәзер «Артур ияре» дип аталган тауга менәбез, бананны шуның башына менеп җиткәч ашыйбыз.

Артур ияре гади тау гына түгел. Моннан 350 миллион ел элек сүнгән вулкан ул. Астан караганда әллә ни биек кебек тә түгел – 250 метр гына. Тик бик текә. Беренче 50 метрны җырлап кына үтәбез. Алтмышынчы метрда җырлау теләге сүнә. Еш-еш сулыйбыз, туктап торгалыйбыз. Артка карангалыйбыз. «Монда хәтле менгәч тә бик җиткән, әйдә, борылыйк булмаса», – дигән сүзне беренче булып мин әйттемме соң, әллә улмы? Ничә метр менгәч әйтелде ул? Әле ярый банан булды. Банан – тау башына менеп җитәргә стимул. Әгәр ул булмаса, кем белә, бәлки, борылып та төшеп киткән булыр идек.

Борылмадык. Үпкә әстерхан чикләвеге хәтле генә булып кечерәйгән, андагы һава да чигенә җитеп кысылган мәлдә, ниһаять, тауның башына менеп җиттек. Монда бездән кала да кеше бик күп икән. Ренат ул арада әллә каян үзебезнекеләрне табып ала: Дагстаннан килгән ике егет белән таныша. Ә мин тирәюньне күзәтәм. Җил шулкадәр



Эдинбургта күргән диңгезнең чикләре бар иде кебек, ә бу күлләрнең иге-чиге юк. Өстәвенә, томан да төшкән, тирә-як тоташ ак пәрдә эчендә кебек. Шул пәрдәне ертып, вакыт-вакыт ямь-яшел таулар, тау битендә утлап йөргән бәрәннәр килеп чыга. Кеше кулы кагылырга өлгермәгән (әллә кыймаганмы?) гүзәллек!

көчле ки, аның иркенә әз генә бирешсәң, Эдинбург өстенә кош булып күтәрелерсең сыман. Җил тавышын ярып, волынка тавышы ишетелә (бераз соңрак Ренат, уйнаучы янына килеп, «Әпипә»не уйнавын сораячак, көйләп тә күрсәтәчәк, тик музыкант, көйне бик катлаулы дип, уйный алмаячагын белдерәчәк, һәм Ренат аны музыкасыз гына башкарачак, аны тыңлап торган французлар «Браво» дип сокланачак).

– Безнең әле диңгезгә дә барып җитешәсе бар, – ди Ренат һәм мине хыялдан җиргә төшерә. Диңгезгә очып кына барып җитеп булмый: тауны төшеп, җәяүләп барырга кирәк. Тиз-тиз генә стимулны, әйлә, бананны ашыйбыз да таудан түбән юнәләбез.

Карта безне әллә ни гомер алдап йөртте. Диңгезгә дип, әллә нинди урау юллар аша алып китте, килеп терәлгән тыкрыкларга алып керде. Ә кичке 8 дә мин икенче шәһәргә – Глазгога кузгаласы. Автобуска билет та алынган. Әллә кире борылыйкмы, соңга калам бит, дим Ренатка. Барабыз, ди. Бу юлы стимул булырга банан да юк. Бу юлы Ренат үзе каты тора. Һәм – менә ул Төньяк диңгез. Әллә нәрсәсе дә юк кебек инде үзенең – су да су. Тик аның диңгез икәнен белү, үзебезнең Шотландиядә – дөньяның бөтенләй башка бер кыйтгасында икәнлекне искә төшерү әйтеп аңлатып булмаслык рәхәтлек бирә. Яр буендагы утыргычларга чүмәшеп, әллә күпме вакыт диңгезгә текәлеп утырабыз.

Шулай да, вакытында айнып, тиз-тиз генә диңгез белән хушлашабыз, вокзалга йөгерәбез. Мин менеп утыруга, автобус кузгала – вакыты җиткән. Хәзер инде мин Ренатсыз гына икенче бер шәһәргә барам. Ләкин күңелдә инде курку юк. Күңелдә ышаныч, барысы да яхшы булачагына ышаныч.

Албасты кочагында

Глазгога килеп кергәндә караңгы төн иде. Әле куна торган җиргә дә барып җитәсе бар. Карта автобус номерын дөрес күрсәтми. Юл сорарга дип, беренче очраган кешегә мөрәҗәгать итәм һәм теге югалып торган курку хисе яңадан баш калкыта. Мин боларның телен аңламыйм икән! Бездә дә тиз-тиз сөйләшүче кайбер мишәрләрнең сөйләме беренче тапкырдан ук аңлашылмый бит, бу да шулай икән: без белгән инглиз теленә көчле шотланд акценты кушылып, бөтенләй үзгә бер тел барлыкка килә.

Ничек кирәк – алай, үземә кирәкле автобусны табып, менеп утырдым. Олы яшьтәге абый белән апа, хәлемне аңлап, миңа юл күрсәтергә алындылар. Нидер сөйлиләр, елмаялар, Россиядән икәнемне белгәч, әлеге ил турында белгәннәрен сөйлиләр... бугай. Мин аларның ярты сүзен аңламыйм. Сораулар бирмәгәннәренә куанып, елмаеп бара бирәм. Бер белмәгән, телләрен дә юньләп аңламый торган бу кешеләргә ышанам. Хушлашканда: «Синең инглизчәң бик әйбәт!» – дип канат та куялар.

Икенче көнне Шотландия буйлап экскурсиягә кузгалабыз. Кечкенә автобуста 15 кеше. Йөртүчебез – килт кигән чып-чын шотланд. Үзе йөртә, үзе сөйли. Бүген инде шотланд акценты да алай ук куркыныч кебек тоелмый. Глазгоны чыгып, Шотландия күлләренә юнәләбез. Лох-Несс албастысын күрергә теләп (Шотландия күлләрендә албасты яши дигән легенда бар бит!), автобус тәрәзәсеннән үрелеп-үрелеп карыйм – күренми. Иксез-чиксез күлнең төбендә албасты йоклап ята, ә син аның борын төбеннән генә шушылай үтеп китәсең дип уйлап, автобуста агылган талгын шотланд көенә изрәп бару рәхәт.

> *Инглизчә сөйли кебек бит инде үзе, ник аңлашылмый соң?*

Бераздан бер шәһәрчеккә туктыйбыз. «Шәһәрне карагыз, мин бер сәгатьтән киләм», – ди дә, йөртүчебез китеп бара. Бер сәгатьтә күпме җирне генә карап була инде! Шулай дип уйлыйм да йөгерә-атлый шәһәр карарга китәм – тизрәк-тизрәк танышып калырга. 20 минут та үтми... бөтен шәһәрне әйләнеп чыгам. Шундый кечкенә генә шәһәр икән бу! Ике рестораны, бер кибете, бер Мәдәният сарае бар. Бер ресторанга кереп, каһвә алам да күл буена килеп утырам. Каһвә пешерү законнары буенча, дөрес пешерелмәгән ул, белгечләр аны тәмсез дип бәяләр иде. Анысы мөһим түгел. Каһвә урынны түгел, урын каһвәне бизи. Ә бу минем үз гомеремдә татып караган иң тәмле каһвәм.

Бер сәгатьтән автобус кире әйләнеп килә, һәм без кайтырга кузгалабыз. Шотландия албастысын күреп булмаса да, бу сәфәр иң могҗизалы сәфәр булып истә калачак.

PRESSA.RU

16+

ЕРАКТАН ЭЗЛӘГӘНЕҢ – ЯКЫНДА

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.



Фәнис КӘЛИМУЛЛИН, Г. Кариев исемендәге яшь тамашачы театры артисты. Татарстанның атказанган артисты;
гаилә стажы – 21 ел;
балалары – кызы Миләүшә (20 яшь), улы Ильяс (7 яшь).

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Күзгә күренгән нәрсәләргә төшәдер ул башта караш: киеменә, буй-сынына... Ә сөйләшә башлагач, барысы да ачыклана... Була бит шундый күз явын алырдай чибәрләр – шаккатасың. Тик авызын ачып бер сүз әйтсә, кызыксынуың шунда ук сүнә. Дәшмәсә, хәерлерәк булыр иде дип уйлыйсың. Ә кайчак шундыйлар очрый: башкалардан бер ягы белән дә аерылып тормый, игътибарны артык җәлеп итми. Аралаша башлагач исә сокланып туймыйсың – күңеле шулкадәр бай, шулкадәр матур! Менә ни өчен дә беренче тәэсиргә артык ышанып бетәргә ярамыйдыр... Тагын күзләр бар әле. Укый белсәң, аларда кешенең җаны чагыла, диләр. Бер партнерым: «Сәхнәдә уйнаганда, роль эчендә яшәгән күзләрне күрү кирәк. Ул яктан, синең белән миңа рәхәт, Фәнис абый», – ди.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Хатын-кызлар шактый көйсез зат бит алар – бу аларның күбесенә хас сыйфат. Вакыт-вакыт көйсез... Шуңа да гафу итәсең. Тагын, тиз генә кабынып китеп, уйламыйча нидер әйтергә мөмкиннәр. Хәер, ничек тиз кабынсалар, шулай тиз басылалар да анысы...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтне. Ләкин хәтта бу очракта да бөтенләй кырт кисәргә ярамыйдыр. Без барыбыз да адәм балалары – ялгышлардан хали түгел. Гөнаһсыз булсак, фәрештә сыман очып кына йөрер идек. Кеше кайчак бер минутлык хистән дә кабынып китәргә мөмкин. Һәм, ялгышын аңлап, шунда ук үкенергә, гомергә бу эшне эшләмәм, дип, үз-үзенә антлар эчәргә дә мөмкин. Нигә аны кичермәскә? Әйе, гафу итәргә дә кирәк кайчак. Бер секундта бөтен нәрсәне җимереп ташлау дөрес тә түгелдер. Балалар бар бит... Хатын-кызны гафу итмәслек хәлләрдә калырга, гомумән, бер ир-атка да язмасын.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Илһамландырып торучыдыр дип уйлыйм. Безгә, сәнгать кешеләренә, бу бигрәк тә кирәк. Илһамландырып җибәрсәләр, ир-ат, җиң сызганып, өйдә комфортны үзе дә ясый. Ясарга булыша... Күңелен күтәрергә генә кирәк аның. Җилкендерергә!

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Без Алия белән өч ел ярым театр училищесында бергә укыдык. Унау идек төркемдә: биш егет, биш кыз. Әмма укыган вакытта ул – мине, мин аны «күрмәдек». Барысы да театрда бер сезон эшләгәч башланды... Кызык ул безнең тарих. Мин Алиянең иң якын дусты, аның белән бер бүлмәдә яшәгән кыз белән дуслашып йөрим. Күпләр безнең арада мәхәббәт дип уйлый. Әмма без аның белән абый-сеңел кебек идек, үзенең абыйсына охшата иде ул мине. Шул кыз берсендә Алиянең мине якын итүен сиздерде. «Синең хакта болай дип әйтә», – ди... Кинәт кенә Алиягә башка күз белән карадым бит шуннан соң! Югыйсә озатып йөргән кызларым да бар иде. Берәү генә дә түгел иде. Яшь чакта егетләр – кызсыз, кызлар егетсез булмый инде. Кем кемне озатмаган?! Әмма барысы да вакытлы мавыгу гына булган, күрәсең. Ә Алияне мин моңарчы бөтенләй белмәгәнмен икән: эчке дөньясын, күңелен... Сукыр булганмын!

Ул елны Фәнәвил Галиев белән җәйге ялыбыз вакытында Пермь якларына гастрольгә чыгарга уйладык. Телеграмма сугып, Алияне дә чакыртып алдым. «Ял вакытында нинди гастроль ул?» – дип, әнисе ачуланып калса да, Алия авылдан очып килеп җитте. Дүртәү юлга кузгалдык. Көндез балаларга Нәби Дәүлинең «Тозакка төшкән аучы» дигән әкиятен куярга булдык, ә кичләрен – концерт. Шул гастрольләр вакытында якынаеп киттек инде без. «Өйләнешәбез, бер театрда эшлибез, бер-беребезне аңларга да җиңел булыр», – дип, Барда

районында йөргәндә үк хәл иттек. Күктә, күрәсең, никахыбыз инде укылган булгандыр.

Гастрольдән соң, Алия үзенә – Кукмарага кайтып китте, мин – Әлкиемә. Инде бу хәбәрне өйдәгеләргә җиткерергә кирәк бит. Әти мин икенче курста укыганда ук мәрхүм булган иде инде. Әнигә яңалыгымны әйтергә һаман җай тапмыйм. Бакчага суган чүбе утарга чыктык шулай. Инде түтәлләр дә бетеп килә. Әйтеп булмый гына! Ниһаять, тәвәккәлләдем. «Әни, мин өйләнермен... Бәлки», – дим. Мин төпчеге, абый-апалар бар да башлыкүзле иде инде. Ул чакта машиналар юк әле: Алияне сорарга барырга әни абыйсының хатыны белән Казанга поездда килде. Монда кунып, электричка белән дүртәү Кукмарага, Төркәшкә кайтып киттек. Капканы ачып керсәк, Алиянең әтисе ишегалдында йөри. «Исәнме, бабай!» – дип кул суздым. «Әле бабай түгел, никахтан соң әйтерсең», – дип туктатты ул мине.

Безнең никах укытып килүебез җәйге ялдан җыелган артистлар өчен зур вакыйгага әйләнде. Күпләр моңа ышанмады. «Фәнис белән Алия өйләнешкән икән», дигәч, «Дөрес түгелдер, Алиянең дус кызы белән кавышканнардыр», – дип каршы төшкәннәр. Әйтәм бит, аның белән йөри дип уйлыйлар иде мине.

Ә туебыз 20 сентябрь көнне безнең авылда булды. Театр «УАЗ»ик бирде – шуңа төялешеп кайттык. Пычрак, карлы яңгыр ява... Кулчатырлар тотып, авыл Советына җәяү бардык. Аякта – резин итек. Кулда – бакча чәчәкләре. Алиянең бер дус кызы «Мендельсон» маршын а капелла җырлап торды. Шулай язылыштык...

6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Таба икән, димәк, булдыра! Әйбәт хатын эләккән! Мал табучы кешенең гаиләгә вакыты күп калмый гадәттә. Димәк, иргә күбрәк вазыйфа йөкләнә бу очракта: балаларны тәрбияләргә, өйне тәртиптә тотарга, хатыны кайтышка, бәлки, ашарга да пешерергә... Әмма хатын байлык таба, дип, ир кеше түбәнлеккә төшәргә, буйсынып торырга тиеш түгелдер. Хәер, монда күбесе хатын-кыздан да торадыр дип уйлыйм. «Мин акча табам!» – дип, авыз да ачтырмаса, бу сүзләр ирне түбәнсетәчәк инде.

7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Ә ни өчен белгертмәскә, сузып йөрергә, көтәргә? Соңга калсаң?! Алия мисалындагы кебек, үзең ярып әйтмичә, читләр аша сиздерергә дә мөмкин ләбаса.

8 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Өй җиһазларын бер урыннан икенче урынга күчерергә ярата Алия. Әле менә тагын өстәлне башкача итеп борып куйган. «Болай җайсыз бит, сыймыйбыз», – дим. «Юк, ул шулай торырга тиеш!» – ди. Фатирда ярар, хәтта тулай торак бүлмәсендә дә шулай мәш килә иде Алия. «Тагын нишләттең инде?» – дип аптырый идем. «Бертөрлелектән туям, өйдә аз гына үзгәреш булса да, миңа рәхәт, үземне әйбәт хис итәм», – ди ул.

9 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Башта бәхәсләшәсең. Үзеңнекен исбатларга тырышып карыйсың. Алиянең мондый вакытта кызып китә торган гадәте бар. Мине сабыр кеше дип әйтәләр болай, ләкин ул сабырлыгыңны сындырырга да мөмкин. Үзеңне тыеп торырга тырышасың, билгеле. Аннан кул селтисең. Үпкәләгән сыман буласың. Озак та үтми, ул үзе яныңа килеп җитә... Әй, бәхәсе дә юк-бардан, вак-төяктән чыккан бәхәс була инде аның!

10 Шундый очракны күзаллыйк әле: Сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Юк, мин кафега чыгып китә яки нәрсәгәдер заказ бирә торган кеше түгел. Йомырка кыздырып ашый алам. Аш куям. Малай токмач ярата – аны пешерүнең дә бер авырлыгы юк. Алия мин томалап пешергән кәбестәне бик ярата. «Синеке тәмлерәк килеп чыга», – ди.

11 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Алия бик җитез ул – күз ачып йомганчы әзер була. «Нәрсә кияргә?» дигән сорауны да җәлт хәл итәбез. «Әнә шул күлмәгең бар бит, ки», – дисәм, ул шунда ук ризалаша. «Әйе, менә дигән! Каян башыңа килә синең?!» – дип, мине мактап та ала әле. Үзен гел чибәрләп, матурлап торырга аның, бәлки, вакыты да җитмидер. Аннан ул рәхәт, иркен, җайлы кием кияргә ярата. Аларның өйләре авыл читендә – табигать кочагында утыра. Авылга кайтса, мин Алияне танымыйм: гади генә күлмәкләр киеп куя, чөеп кенә яулык бәйли. «Убырлы карчыкның яшь чагы булгансың», – дип көләм мин аннан. Тәнемә рәхәт, мин шулай ял итәм, ди. Сүз дә юк, ул да матур күлмәкләр кияргә ярата. Кызыга да торгандыр. Әмма: «Шундый күлмәк, шундый тун киясем килә», – дип, беркайчан әйткәне юк. Мин: «Әйдә, сиңа менә шуны алыйк», – дигәч тә, «кирәкми» дияргә мөмкин.

12 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Миңа ошамастай бүләк биргәнен хәтерләмим Алиянең. Ә беренче бүләге истә менә! Сөйлимме икән соң... Без әле очрашмый да идек. Беркөнне ул торган тулай торактан, бер кыз яныннан чыгып барам шулай. Алия мине күрде дә: «Карале, сиңа бер бүләгем бар иде», – ди. «Ярый, кире борылмыйм инде, мин урамга чыккач, тәрәзәдән ыргытырсың», – дим. Пакет белән ташлады бу. Ачсам – трусик! Сәдәфле трусикларның чыккан гына вакытлары. «До, ре, ми» дип язылган. Заманасы өчен шактый затлы иде ул. Үлчәме дә туры килде. Кадерле бүләк булды ул миңа, озак кидем, хәзер дә саклыйм. Алия кыю ул, мондый бүләк бирергә дә йөрәге җитә...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



Кыш көне безгә күзне иркәләүче яшеллек җитми. Яшеллек – җәй төсе, яшәү төсе. Шуңа да бүлмә гөлләрен яратабыз без. Җәйне юксынганда шуларга карап юанабыз. Әмма бүлмә гөлләре гел игътибар сорый. Вакытында суын сибеп, вакытында туфрагын алмаштырып торсаң гына матур алар. Бәлки, шуңадыр, бүген күпләрнең тәрәзә төбен суккулентлар бизи. Үзләре матур, үзләре талымсыз. Шуның өчен дә бу осталык дәресен суккулентларга багышларга булдык.
Наталья ТРИШИНА флорариум сәнгате белән күптәннән шөгыльләнә. Үсемлекләрен дә үзе үстерә, пыяла савытларын да үзе ясый. Бу хоббиның сәбәпчесе – дуслары бүләк иткән орхидея гөле. Аны матуррак савытка күчереп утыртасы килеп, пирамида формасындагы пыяла ваза сатып ала ул. Искиткеч матур килеп чыккан бу композициясен дуслары да ошата, безгә дә ясап бир, диләр. Әнә шулай, акрынлап кына осталык килә, үсемлекләр буенча да шактый белем туплана. Флорариумны күбрәк бүләк буларак ясаталар икән, чөнки ул еллар буе үзенең матурлыгын югалтмый. Теләгегез булса, сез дә безгә кушыла аласыз.



Мастер-классны Наталья ТРИШИНА үткәрә.

ФЛОРАРИУМ – БҮЛМӘДӘГЕ БАКЧА

Кирәк:

• флорариум (аны теләсә нинди пыяла савыт алыштыра ала);



• суккулент үсемлекләр. Без декоратив алоэ һәм ике төрле эхеверия кулландык. Суккулентларның башка төрләрен дә куллана аласыз, мәсәлән: хавортия, кактус, халык арасында акча гөле дип аталучы гөл (толстянка);

• суккулентлар өчен махсус туфрак. Аны үзегезгә дә ясарга була, ул бер өлеш туфрак, бер өлеш ком, бер өлеш вак таштан гыйбарәт;

• бизәү өчен вак ташлар, кабырчыклар, төрле төстәге мүк (махсус интернет кибетләрдә бар), кечкенә өй, җәнлек сыннары.

Эш барышы:

■ флорариум төбенә 2 см чамасы туфрак салабыз. Аны кул белән түгәрәк этеп, урта бер җирен чокырлыйбыз, җиңелчә генә тыгызлыйбыз.

■ Иң түргә алоэ гөлен урнаштырабыз. Әгәр дә тамырларга ияргән балчык кантары зур булса, балчыгын коясы булыр. Гөлнең тамырларын капларлык итеп яңа туфрак салабыз. Аны кул белән баскалап, тыгызлыйбыз: гөлләр туфракта нык утырырга тиеш.



Алоэ гөленнән бераз читкәрәк китеп, эхевериялар утыртабыз. Флорариум корганда бер кагыйдә бар: үсемлекләрне тыгыз итеп утыртырга ярамый, кимендә 2 см булса да ара калырга тиеш. Аларга үсәр өчен урын кирәк.

■ Безнең флорариум зур түгел, шуңа да өч үсемлек бик җиткән. Гөлләрне утыртып бетергәч, тамырларын тулысынча туфрак белән күмдерәбез. Берәр озынрак әйбер белән баскалап, туфракны нығытып тыгызлыйбыз.

■ Буш калган урыннарга төсле мүк утыртабыз. Мүкне туфракка күмдерү кирәкми, балчыкка ул кирәгенчә генә үзе берегәчәк. Тагын бер кагыйдәне онытмагыз: никадәр генә ымсындыргыч булмасын, композицияне артык чуарламаска кирәк. Чама хисен онытып җибәрмәгез.

■ Үсемлек төпләренә, туфракның ачык калган урыннарына вак таш салып чыгабыз. Моны кашык белән эшләү уңай. Таш, бердән, композицияне бизәү өчен кирәк булса, икенчедән, ул туфрактагы дымны да саклый. Теләсәгез, флорариумны бәләкәй өй, кечкенә сыннар белән дә бизи аласыз.

■ Флорариум күзне озаграк иркәләсен өчен, берничә кагыйдәне онытмаска кирәк. Суккулентлар артык дымны яратмый, дым – аларның беренче дошманы. Шуңа да аларга суны атна-ун көнгә бер генә сибәләр. Анда да шприц ярдәмендә үсемлек янындагы туфракны гына чылаталар. Яфракларга су тияргә тиеш түгел.

■ Җылы як үсемлеге булган суккулентлар яктылык ярата. Караңгы урында декоративлыгын югалталар. Алар озак үсә, ә инде кирәгеннән артык үсә башласалар, үсемлекнең ботак очын өзеп алырга кирәк.

■ Әгәр дә шушы гади генә кагыйдәләрне үтәсәгез, тәрәзә төбендәге кечкенә бакчагыз әле

Коры флорариум талымсызлыгы һәм игътибар таләп итмәве белән кыйммәтле. Корыга чыдам үсемлекләр – суккулентлар – атналар буе су сипмәсәң дә бирешми, матурлыгын җуймый. Андыйлар артык күп булмасалар да, арасында сайлап алырдайлары юк түгел.



Кактус (опунция, ребуция, эхинопсис, нотокактус төрләре) – дөрес итеп сайланган декор фонында кактуслар да бик матур күренә.



Агава – карап торышка хавортиягә дә охшаш кебек. Флорариумга аның үзен генә утыртканда да искиткеч композициягә ирешеп була. Озынча тар яфраклары чәнечкеләр һәм энәләр белән бизәлгән. Күп очракта зәңгәрсу яшел төстә була. Яфраклары каймалы булган төрләре дә бар.



Молодило – икенче төрле аны таш чәчәк дип тә атыйлар. Иң талымсыз үсемлекләрнең берсе. Кан төсенә манылган яфрак очлары белән гаҗәеп.



Крестовник – яфраклары яшел борчакны хәтерләтә, ботак буйлап әйтерсең лә вак-вак сәйләннәр тезелешеп киткән. Озын нечкә ботаклары флорариумны бизәгәндә киң кулланыла. Тармакларын савыттан читкә ташлап та әллә нинди әкәмәт рәвешләргә кереп үсәргә сәләтле.



Каланхоэ – яфрак тирәли бәбчекләре тезелгән декоратив төрләре флорариумда искиткеч матур күренә. Башка суккулентлардан аермалы буларак, ул буйчан үсемлек, матур гына куак булып үсә.



Адромискус – мөгаен, хаклы рәвештә иң сәер үсемлекләр рәтенә керәдер. Аның юан, йомры яфраклары әле ташны хәтерләтә, әле кабырчыкны, әле ачылырга торган бөрене... Туфрактан чыгып торучы кызыл тамырлары тагын!

www.botanichka.ru сайты материаллары буенча әзерләнде.

PRESSA.RU

Бишбармак барлык төрки халыкларның да яратып әзерли торган ризыгыдыр. Аны кыргызлар да үзләренең милли ризыгы дип саный, казакълар да. Татарлар пешерә аны. Бүгенге осталык дәресебезнең хуҗабикәсе Ширинә СӘЛИМШИНА-ШАҺИМӘРДАНОВА аны үзе дә Казакъстанда яшәүче дусты Кифая ханымнан өйрәнгән. Хәзер инде ул һәр кадерле кунагын «Бишбармак» белән сыйламый калмый. Үзенә генә хас серләре булса да, әзерләве артык катлаулы түгел икән. «Сөембикә» укучыларына инде алдагы саннарыбыздан да яхшы таныш Ширинә ханым ул серләрне безнең белән дә бик рәхәтләнеп уртаклашты.





Кирәк:

(4-5 кешелек гаилә өчен)
- 1-1,5 кг сыер ите (бик сөякле булмасын);
- 1-1,5 кг сарык ите;
- 5-6 баш эре суган;
- 0,5 кг вак суган;
- 1-2 кишер;
- 2 йомырка;
- он;
- су.

БИШБАРМАК



Эш барышы:

■ Сыер итен – аерым, сарык итен аерым савытка пешерергә куябыз (кемдер сарык итеннән әзерләгән шулпаны өнәмәскә мөмкин). Кайнап чыгып, күбекләрен җыеп алгач, бер-ике баш эре суган һәм эре итеп туралган кишер (бөтен килеш кенә дә ярый) салабыз. Тәменчә тоз өстибез.

■ Шулпа ике сәгать тирәсе акрын гына кайнасын. Итне изелгәнче пешерергә ярамый. Шулпаны сүндереп, итне табакка алабыз. Шулпаны исә аерым савытка сөзәбез.

■ Итнең чак кына суынганын көтеп, җепселләренә аркылы итеп турыйбыз. Менә монда инде бераз осталык кирәк булачак! Ит кисәкләре шырпы кабыннан чак кына кечерәк һәм юкарак булса яхшы.

■ Туралган итне төбе калын кәстрүлгә салып, өскә эре итеп туралган суган боҗралары, тоз, борыч, төбе күмелерлек итеп шулпа өстәп, сүрән генә утта бер сәгать чамасы томалап пешерәбез.

■ Ит пешкән арада токмач басып алыйк. Моның өчен тирән эчле савытка йомырка сытып, бер йомыркага кечкенә генә бер касә исәбеннән су салып, токмачка баскан кебек итеп камыр басабыз.

■ Камырны бик юка итеп тәгәрәтеп җәябез. Ул үтә күренмәле дип әйтерлек булырга тиеш. Аз гына кипшергән камырны 6 см тасмаларга теләбез. Һәр тасманы кыек шакмаклап кисәбез.

■ Ике кешегә берәрне исәбеннән бәрәңге пешереп алабыз.

■ Әрчелгән вак суганны ярым боҗра итеп турыйбыз. Моның өчен нәкъ менә вак суган яхшы. Туралган суганны бер савытка бушатып, тәменчә тоз-борыч сибәбез һәм табынга бирер алдыннан гына өстенә шаулап торган кайнар шулпа коябыз. Суган чак кына йомшап китәргә тиеш.

■ Токмач шакмакларын кайнап утырган шулпага салып, әзер булганчы пешерәбез. Бер-берсенә ябышмасын өчен, аның барысын да берьюлы түгел, берәм-берәмләп кенә салырга кирәк.

■ Шулпадагы токмачны тишекле чүмеч белән җыеп, берәр тәлинкәгә сөзеп алып торабыз. Шулпадан арындыру өчен кирәк бу.

■ Бишбармак зур тәлинкә белән табын уртасына куела торган ризык. Тәлинкә төбенә иң элек токмач салына (токмачлар ябышмасын өчен, тәлинкәне селкеткәләп торырга кирәк). Аның өстенә туралган итне өябез. Ит тирәли бәрәңге яркалары тезелә. Иң өскә шулпасыннан сөзеп алынган суган салына. Кишердән киселгән ромашка чәчәкләре белән бизәргә мөмкин.

Бишбармак суынганчы дип, бу эшләр тиз-тиз эшләнә.

■ Бишбармакны кайнар килеш табынга бирәбез. Һәркемгә касәгә салынган шулпа чыгарабыз. Шулпага ваклап туралган укроп салырга була.

■ Ашларыгыз тәмле, тормышыгыз бәрәкәтле булсын!

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU



Фото: Камилә Димөхәммәтова

Соңгы вакытта «дөрес» туклану турында күп сөйлиләр, язалар. Без дә үткән саннарыбызның берсендә гранола әзерләргә өйрәткән идек инде. Бу юлы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА дөрес тукланучыларга конфет ясарга тәкъдим итә.

ФАЙДАЛЫ КОНФЕТЛАР







Кирәк:

- 100 г күрәгә;
- 100 г кара җимеш;
- 100 г хөрмә җимеше (финик);
- 100 г кипкән җимешкә 9 аш кашыгы нисбәтеннән какао;
- 1 плитка кырку шоколад;
- бәдам чикләвеге (миндаль);
- вакланган әстерхан чикләвеге.

Әш барышы:

■ Җимешләрне блендер белән ваклыйбыз. Өчесен дә аерым-аерым вакларга мөмкин, барысын бергә кушсаң да ярый. Иң тәмле конфетлар – хөрмәнеке. Тик алар калорияләргә дә иң бае.

■ Вакланган җимешләргә какао кушып, яхшылап туглыйбыз.

■ Уртага берәр бәдам чикләвеге тыгып, җимештән шарчыклар әвәлибез.

■ Шоколадны берәр савытка ваклап, төбенә аз гына су салабыз һәм микроволновкада эретәбез. Эрегән шоколад куерак булса, тагын бераз су өстәргә мөмкин.

■ Һәрбер шарчыкны эрегән шоколадка манып алабыз. Өстенә вакланган чикләвек сибәбез.

■ Әзер конфетларны суыткычта саклыйбыз.


Кучкар. Иркенәргә ирек булмас, әмма мәшәкатьләрегез күңелле мәшәкатьләр. Бу ай элеккеләреннән уңышлырак булыр, ниятләрегезне тормышка ашырырга җай чыгар. Акчаны юкка сарыф итмәгез, зур әйберләр алмый торыгыз.


Үгезбозау. Белемегезне, рухи дөньягызны баету өчен яхшы вакыт. Акчаны таба да, дөрес итеп тота да белерсез. Бу айда сатып алынган әйберләр озак хезмәт итәчәк. Ай ахырында бераз киеренкелек булуы мөмкин, кемгәдер ярдәмегез кирәк булыр.


Игезәкләр. Тормышыгыз күңелле вакыйгаларга бай булыр. Максатларыгызга ирешү тирә-юньдәгеләргә бәйле. Бу сезнең өчен яхшырак та, чөнки әлеге йолдызлыкта туганнарга тәвәккәллек җитеп бетми, якыннарыгыз сезгә көч биреп, алга этәреп торачак.


Кысла. Айның беренче яртысы мәшәкатьлерәк булыр. Күп нәрсә ачуыгызны китерер. Аның каруы, айның икенче яртысы сөендерер. Күптәнге әҗәтегезне кайтарып алырсыз яисә көтелмәгән керем булыр.


Арыслан. Тормышыгызны авырайткан нәрсәләрдән котылырсыз. Иңнәрегездә канатлар тойгандай булырсыз. Күңел күтәренкелеге эшегездә дә чагылмый калмас. Яңа мөмкинлекләр, яңа дуслар барлыкка килер.


Сөмбелә. Яхшы үзгәрешләр, уңай борылышлар ае. Бар көчегезне бер йодрыкка туплап, алга барыгыз. Язмыш сезгә күңелле сюрпризлар әзерли. Идеяләрегездән баш тартмагыз, алар сезгә уңыш китерер. Уңышка ирешү өчен үзегезгә дә тырышырга кирәк.


Бизмән. Киң офыклар ае. Ниятләр чынга аша торган ай. Идеяләр ташкыны бөтереп алыр. Беренче адымны гына ясавы авыррак, аннары бар да үзеннән-үзе тәгәрәячәк – сездән бары тәвәккәллек кенә сорала.


Чаян. Перспективалы башлангычлар, тормышны башка юнәлешкә борып җибәрердәй үзгәрешләр көтелә. Түземле булыгыз, үз җае белән бар да рәткә салыныр. Бу үзгәрешләрне язмышның бүләге дип кабул итегез, сез дөрес юлда.


Укчы. Яңалыкларга әзер торыгыз. Әгәр дә үз ярыгызны тапмаган булсагыз, менә хәзер табачаксыз. Тормышыгыздагы кара полоса тәмамланып, ак полоса башлана. Үзгәрешләр үз көчегезгә ышаныч, ныклык та алып киләчәк.


Кәҗәмөгез. Уңыш ае. Күп кенә хыялларыгыз нәкъ шушы айда чынга ашар. Тормышыгызда үзгәрешләр булыр. Барысын да үзләре хәл итүче Кәҗәмөгезләр үзгәрешләрне өнәмәсә дә, алар сезнең файдага.


Сукояр. Теләсә нинди мәсьәләне җиңел генә чишә алырсыз. Бу сәләтегезгә үзегез үк гаҗәпләнерсез хәтта. Сәләтегезне күрсәтү, абруй казану өчен җай чыгар. Өстәмә акча чыганагы барлыкка килер. Бу чыганакның иҗатка бәйле булуы ихтимал.


Балык. Тормышыгызны яхшыга үзгәртү өчен кулай чор. Мөмкинлекләре дә чыгарга тора. Эш алыштырырга, яңа эш башларга теләүчеләргә шушы айда активрак булырга киңәш итә йолдызлар.

Гыйнвар да кабынган йолдызлар

Татарстан *Россия* *Чит илләр*



Нәҗибә Ихсанова (25.01.1938) – **Татарстанның һәм Россиянең халык артисты.**

Азнакай районы, Яңа Ташлыяр авылында туып-үсә. Татар дөньясына ике мәшһүр артистны (берсе Әзһәр Шакиров) үстереп биргән ул авыл урынында хәзер истәлек стелласы гына тора, авыл үзе юк.

1961 елда Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесын тәмамлап, Г. Камал театрына эшкә кайта. Беренче рольләре: «Көзге ачы җилләрдә» – Гандәлиф (А. Гыйләҗев), «Чаткылар»да – Маһисәрвәр (Т. Гыйззәт), «Тормыш җыры»нда – Фатыйма (М. Әмир) – гади авыл кызлары. 1966 елда театрга баш режиссер булып Марсель Сәлимҗанов килгәннән соң, күбесенчә текә, буйсынмас ханымнарны уйный. 1998 елда «Хушыгыз» спектаклендәге (Т. Миңнуллин) Миләүшә роле өчен ул Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек була.



Ольга Кабо (28.01.1968) – **җырчы, Россиянең атказанган артисты.**

Мәскәүдә туа. Балачагы Уралда уза. Инглиз телле махсус мәктәпне тәмамлый, кечкенәдән музыка, бал биюләре, нәфис гимнастика белән шөгыльләнә. Әле мәктәптә укыган чагында ук аны кинода уйнарга чакыралар. «Анна Павлова» фильмында асрау кыз булып уйный. 15 яшендә исә «И повторится все...» фильмында төп рольне башкара. 1989 елда ВГИКны тәмамлап, берара «Заманча опера» театрында эшли. Танылу аңа Сергей Тарасовның «Приключения Квентина Дорварда» фильмы аша килә. 1990 елда оста җайдак икәнлеген белеп, «Мушкетеры тридцать лет спустя» фильмында уйнарга чакыралар. 2007 елда җырчы буларак та танылa.




Жанна Моро (23.01.1928–31.06.2017) – **артист, җырчы, кинорежиссер.**

Франциядә туа. Биюче Кэтрин Баклинның кызы. Югары милли драматик сәнгать консерваториясен тәмамлый. Сәхнәгә 1947 елда чыга – Авиньон театр фестивалендә катнаша. Шуннан «Комеди Франсез» труппасына чакыру ала. 1957 елда режиссер Луи Маль аны үзенең «Лифт на эшафот», «Любовники» кебек атаклы фильмнарында уйнарга чакыра. 1960 елда ул инде заманның иң күренекле режиссерлары саналган Микеланджело Антониони һәм Луис Бунюэль фильмнарында уйнап, уңыш казана. Шушы ук елны Питер Брукның «Семь дней, семь ночей» картинасында башкарган роле өчен Канн кинофестивале премиясенә лаек була. Ә 1975, 1995 елларда ул – шушы кинофестивальнең жюри рәисе. Үз гомерендә 142 фильмда уйный.

Фото: pics-about-celebs.com, f3nws.com

PRESSA.RU





НӘФИС ХИСЛӘР БАЛКЫШЫ

Башта мин аны Алабуга сәнгать галереясына куелган картиналары аша ачтым. Картиналарыннан нәфислек, үзенә бер нәзакәт бөркелә. Рәссамның исеме дә җисеменә туры килеп тора – Нәфисә икән бит! Узган ел Ташкентта узган Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәрендә үзе белән дә таныштым. Татарстан һәм Үзбәкстан авторларының бүгенге көн татар сәнгатенә багышланган уртак күргәзмәсендә ул да катнашты.

Беренче карашка бик нәфис күренгән бу ханым үзенең бетмәс-төкәнмәс энергиясе һәм үҗәтлеге белән мине шаккаттырды.

Нәфисә Гыйльманова Ташкентта туган, Низами исемендәге Ташкент педагогика университетының сәнгать факультетын тәмамлаган. Кызларының сәләтен күреп, әти-әнисе аны һәрьяклап үстерергә омтылган.

Нәфисә 2002 елдан Ташкент Архитектура-төзелеш институтында «Архитектур мохит дизайны» кафедрасында эшли башлый. Иҗат белән дә шөгыльләнә, халыкара һәм республика күргәзмәләрендә актив катнаша. 2000 елдан бирле Нәфисә рәссамнарның Үзбәкстан Сәнгать академиясе каршындагы иҗат берләшмәсе әгъзасы.

Рәссам нигездә классик натюрморт жанрында эшли. Нидерланд сынлы сәнгать мәктәбенең «кечкенә голландлылар» жанрындагы натюрморт традицияләрен – аеруча Питер Клас, Виллем Класс Хеда, Виллем Кальф, Ян Вермеер иҗатын хөрмәт итә ул. Натюрморт жанрындагы иң яхшы әсәрләре Үзбәкстан сынлы сәнгате үсешендә лаеклы урын ала. Рәссам тасвирлаган предметлар бар да реаль тормыштан. Предметларның күләмен, яктылыкны һәм төсләрне тасвирлаганда аның бу жанрга шигъри мөнәсәбәте тоемлана. Иҗади эзләнүләр нәтиҗәсендә, гүзәл табигать бүләкләре рәссам киндерендә аеруча тәэсирле күренә. Кайбер әсәрләрендә нейтраль яки караңгырак салкын арткы фон исәбенә алгы пландагы җылы саргылт-кызыл төс бик ачык булып күзгә ташлана.

Натюрмортларында яктылык һәм күләгәләр чагылышын үтә нәзберек итеп бирә алуы рәссамның осталыгына ишарә. Ул Бохара, Хива кебек борынгы шәһәрләр пейзажын, җанына якын туган Ташкенты манзараларын, таулы Су-кока күренешләрен аеруча яратып яза. Күңеленә бик якын булган Татарстан табигатен дә зур җаваплылык тоеп тасвирлый Гыйльманова: милләттәшебезнең иҗаты бабалары ватанына мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре белән сугарылган. Көз фасылы, аның серле сурәтләре аеруча ошый аңа, һәм алар, яктылык һәм төсләр балкышы булып, картиналарында кат-кат кабатлана.


Нәфисә Гыйльманова Үзбәкстан сынлы сәнгате үсешенә зур өлеш керткән рәссамнарның берсе. Татарстан Рәссамнар берлегенең дә якын дусты: алар оештырган күргәзмәләрдә иң еш катнашучы.


Әсәрләрендә иҗат юлы ачык күренә: хатын-кызларга хас нәфислек, җылылык аша тасвирланган мотивларына үз мөнәсәбәтен сиздерә. Натюрмортларда яктылык һәм күләгәләрне оста уйнатып, ярым караңгылыктан сизелер-сизелмәс кенә саркып торган нечкә хис һәм эмоцияләрне бирә алу – Нәфисә Гыйльманова иҗатының төп үзенчәлеге дә шулдыр.


– Натюрморт жанрындагы тукталыш – ул эзләнү, безне чолгап алган әйләнә-тирәдән көн саен матурлык, гармония һәм мәхәббәт эзләү, – ди Нәфисә үзе.

Рәмзия КАШАПОВА









НӘФИСӘ ГЫЙЛЬМАНОВА

PRESSA.RU



ПОЧТА РОССИИ

Подписные издания

Официальный каталог Почты России



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ П2204

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар 73002

яртыеллыкка язылырга өлгерми калучылар һәр айның 15 нә кадәр язылып, журналны киләсе айдан алдыра ала



Сайтта: www.syuyumbike.ru

ВКонтактеда: vk.com/suumbike

Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike

Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+